ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№6 (330) – ИЮНЬ 2019

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Россиянең гадәти төбәген ничек алдынгы ясарга

Уяв Гырон быдтоннан ничек аерыла

Кыл өстендәге гомер: Гитлерның шәхси дошманы

САБАНТУЙ: ҖЫРЛАТА ДА, БИЕТӘ ДӘ...

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

ТАТАРСТАНДА РОССИЯ БӘЙРӘМЕ

Ватан нәрсәдән башлана? Бу сорауны ишетүгә, хәтфә үлән үскән болын-тугайлы туган авыл, әнинең җылы куллары, мәктәпкә йөгергән сукмаклар күз алдына килә. Цивилизация юлыннан цифрлы якты киләчәккә омтылса да, Россия кешесенә әнә шулар кадерле. Чөнки болар барысы да гаять таныш, күңелгә бик-бик якын. Илебезнең күпләгән кала-салаларында күптән «бәйрәм» сүзенең синонимына әверелгән татар Сабантуе кебек. Бергә җыелып, бик рәхәтләнеп катнаша торган башка халыкларның милли бәйрәмнәре кебек. Тукаебызны һәм аның Шүрәлесен бүләк иткән атаклы Кырлай авылы кебек. Туган ягына мәдхия җырлаган, халкының батырлыгына сокланып туя алмаган Казан ханлыгы шагыйрьләре кебек. Бөек Ватан сугышы тарихының буталчык төеннәрен чишү һәм якты киләчәк хакына гомерләрен биргән, хәбәрсез югалган солдатларның исемнәрен илгә кайтару кебек изге эшләр белән шөгыльләнүче эзтабарлар кебек.

Журналыбызның бүгенге санында урын алган якташларыбыз, якыннарыбыз – бөек шәхесләрнең иле булган Ватаныбыз әнә шулардан башлана да инде.

СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯ.

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Алёна Кутыркина, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Катерина Котова, Гадел Хәеров,
Фаяз Хуҗин, Луиза Шарова, Ольга Туманская
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта Сабантуй күренеше. Раил Вәлиев фотосы; ТР Арча муниципаль районының рәсми сайтыннан алынды

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Татар телендә тираж: 1150 данә,
рус телендә: 2350 данә

Гомуми тираж: 3500 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № О-1515
Басарга кул куелды: 21.06.2019
Басмадан чыкты: 26.06.19

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Коммерция директоры:
Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **930 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7076** – татар телендә
Индекс **П7077** – рус телендә

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ

Илнур Сиражиев

ИЮНЬ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

5. Йөк машиналары өчен евростиль. «КАМАЗ» кабиналары кайчан Mercedes-Benzныкы кебек булачак

12. Россия масштабларында Татарстан. Рейтинглар ни турыда сөйли

18. Киләчәк мәктәбе. Полилингваль комплекслар кайларда ачылачак

22. Белем һәм дуслыкка юл. Минтимер Шәймиев нинди идеяне гамәлгә ашыра

26. Көчле старт. «WorldSkills Russia» VII Милли чемпионатында кем җиңде

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

32. Республика казанышы. Татарстанлылар нинди халык бәйрәмнәрен үткәрәләр

36. Гасыр портретлары. Республика тарихын язучылар

40. Идел яры буендагы музей. Белоруссия Президенты Янка Купала музеенда нинди язу калдыра

44. Аш-су. Фарсил Зыятдинов нәрсәләр белән сыйлый

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

50. Тарих сәхифәләре. Казан ханлыгы шагыйрьләре

54. Гитлерның шәхси дошманы. Даян Мурзин өчен фюрер күпме рейхсмарка вәгъдә иткән

56. Изге эшләр. Солдатның исемен кире кайтарыйк

58. Эзтабарлык. Тынгы бирмәс хәтер уты

84. Татар авыллары. Яңа Кырлайда кунакта

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: www.protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

24.05

Максим Акимов, Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары, – «Иннополис» Университеты» Югары белем бирү Автономияле коммерциячел булмаган оешмасының Күзәтчелек советы утырышында:

– Безнең технологик үсеш барышында, аерым алганда, «Цифрлы икътисад» милли программасын тормышка ашыруда Иннополис Университетының ролен яңача рәвештә күзаллау мөһим. Вузның кадрлар һәм матди-техник потенциалын нәтиҗәле эшләтү һәм халыкара белем бирү киңлегендә аны якты йолдызга әверелдерү өчен, без сыйфатлы итеп хезмәт куярга тиеш.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

21.05



Татьяна Голикова, РФ Премьер-министры урынбасары, – Казанда:

– WorldSkills Russia чемпионаты – дөнья чемпионатының башлангычы. Без WorldSkillsның бөтен командаларын, җанатарларын һәм аны яратучыларны котлыйбез, чөнки Россия һәм Татарстан бездә булган иң яхшы якларны күрсәтергә әзер. Эшче профессияләр чемпионатының мәҗбүри өлешен эшлекле программа тәшкил итәчәк. Аның әһәмияте шунда: программа кысаларында бик мөһим сорауга җавап бирергә кирәк булачак – бүген безнең мәгариф, хезмәт базары алдында нинди таләп тора, без ничек үзгәрергә әзер һәм балаларыбызга нинди мөмкинлекләр тәкъдим итәргә җыенабыз. Дөнья бездән мәгариф процессларын үзгәртүне таләп итә.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

20.05

Чихиро Тагучи, Татар теле буенча Халыкара олимпиадада Бөекбритания исеменнән катнашкан Гран-при иясе, милләте буенча – япон:

– Миңа шулай тоела: сезгә татар телен саклап калыр өчен күбрәк көч куярга кирәктер. Татар теле яшәр, дип өметләнәм. Татар телен өйрәнә башлаган мизгелдән мин үземә бик күп яңа дуслар таптым, мин алар белән очрашам, аралашам. Татар теле ярдәмендә миңа яңа дөнья ишекләре ачылды. Шуңа күрә сез дә үзегезнең туган телегезне саклагыз, үз дөньягызны югалтмагыз!

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Авиация җитештерүе төзелешенә **КЕМ** старт бирде

Россиянең гадәти төбәген **НИЧЕК** алдынгы итәргә

Полилингваль мәктәпләр **НИГӘ** кирәк

Балаларга Россияне **КЕМ** ача

Яшь профессионаллар **НИГӘ** елый

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

2019 елның
II яртыеллыгына
«Татарстан»
журналына язылу
дәвам итә

«Татарстан» журналына ТР буенча язылу индекслары:

П 2381 **татар телендә** 930 сум 00 тиен

П 2378 **рус телендә** 930 сум 00 тиен

«Татарстан» журналына РФ буенча язылу индекслары:

П 7076 **татар телендә**

П 7077 **рус телендә**

Реклама 16+



ПРЕЗИДЕНТ МАРШРУТЛАРЫ БУЕНЧА

Татарстан Президентының эш графигы никадәр тыгыз булуын аңлар өчен, бернинди махсус хронометраж үткәрү таләп ителми. Аның сәфәрләре маршрутына күз салу да җитә. Республика, ил, дөнья буйлап туктаусыз йөри ул. Еш кына Рөстәм Миңнеханов иртән нинди дә булса Европа илендә потенциаль инвесторлар белән сөйләшүләр үткәрергә, көндез Россия башкаласындагы мөһим киңәшмәдә катнашырга өлгерә, берничә сәгатьтән соң исә Әлмәттә нефть тармагы үсеше перспективаларын тикшерә… Һәм көн саен диярлек шундый хәл күзәтелә.

Юлда үткән сәгатьләр һәм чакрымнар, мөһим очрашулар, җитди чыгышлар һәм җаваплы карарлар. ТР Президентының соңгы арадагы эш сәфәрләреннән «Татарстан» аеруча әһәмиятлеләрен сайлап алырга тырышты.

ИННОПОЛИС.
КҮКТӘГЕ «ФЕРМЕР». СТАРТ БИРЕЛДЕ!

НӘРСӘ:

Авиация җыю производствосын һәм эксперименталь авиация аэродромын төзүгә старт

КАЙДА:

Иннополис территориясендә

КАЙЧАН:

22 май

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты:
– Т-500 самолеты Татарстанда эшләнде. Ул авыл хуҗалыгы тармагы, сәнәгать, әйләнә-тирәне мониторинглау өчен кирәк, Себердә һәм Ерак Көнчыгышта да кулланыла ала. Республикада җыю производствосын һәм эксперименталь авиация аэродромын төзү турындагы карар авиация төзелеше тармагын алга таба үстерү юнәлешенә җитди этәргеч бирәчәк».

Фотолар ТР Президенты сайтыннан

ТУЛЫРАК:

Тантана башланыр алдыннан Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм «Ростех» Дәүләт корпорациясе генераль директоры Сергей Чемезов сәнәгать мәйданчыгында җыелачак самолётлар күргәзмәсе белән таныштылар. Т-500 – хәзерге заман Россия тарихында авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге сертификацияләнгән беренче һава судносы. Ул «МВЕН» Казан фирмасы тарафыннан эшләнде. Бүгенге көндә 10 Т-500 самолёты чыгарылды.

«Ростех» Дәүләт корпорациясе йөзендә үзебезгә стратегик партнер тапканчы, без әлеге бурычны чишү буенча төрлечә эшләп карадык», – дип басым ясады Рөстәм Миңнеханов. Аның сүзләренә караганда, «Иннополис» МИЗнда авиацион җыю производствосын һәм эксперименталь авиация аэродромын урнаштыру проектны гамәлгә ашыруны уңышлы үстерергә ярдәм итәчәк, чөнки биредә куәтле интеллектуаль үзәк эшли. Татарстан Президенты шулай ук яңа җыю производствосын урнаштыру өчен 313 гектар мәйданлы җир кишәрлеген бүлеп бирү турындагы күрсәтмәне имзалавын да хәбәр итте.

Сергей Чемезов биредә җитештереләчәк очкычларның Россиядә дә, чит илләрдә дә кулланылачагына ышанычын белдерде. Яңа мәйданчыкның җитештерү куәте елына 60 самолёттан алып 100 гә кадәр булачак. Киләчәктә ике урынлы самолёт һәм пилотсыз очкыч эшләү дә планлаштырыла.

Булачак комплекс территориясендә Т-500, аның модификацияләрен һәм башка типтагы һава судноларын тулысынча җыеп бетерү цехларын, комплектлаштыру өчен кирәк-яракларны саклау биналарын булдыру күздә тотыла. Эксперименталь авиация өчен аерым мәйдан биреләчәк, аның статусы җитештерү цехлары янәшәсендә техниканы һәм махсуслаштырылган җайланмаларны сынап карарга, очышлар үткәрергә яраклаштырылыр дип көтелә. Төзелешне тәгәлләү 2022 елга каралган.

БЕЛЕШМӘ:

Бер урынлы Т-500 самолеты композит материаллардан эшләнгән, климат шартлары катлаулы булган төбәкләрдә дә кулланыла ала. Машинага 3 мең очыш сәгатенә исәпләнгән ресурска ия Lycoming двигателе куелган. Самолетның крейсер тизлеге сәгатенә 160 км, очышның максималь ераклыгы – 1000 км Очкычның авырлыгы – 756 кг. Күтәрелгәндәге максималь авырлыгы – 1475 кг, химик катнашмалар өчен бакның күләме – 500 л. Самолет очучыны һәм самолетны коткару өчен каралган тиз ачылышлы парашют системасы белән җиһазландырылган. Махсус конструкцияләнгән шасси Т-500 очкычын аэродром булмаган урыннарда да куллануны тәэмин итә. Самолётка урнаштырылган сиптерүнең форсункалы системасы ультра кечкенә күләмдә бөркү технологиясен дә күздә тота, бу исә кырларны нәтиҗәле, шул ук вакытта экономияле итеп эшкәртергә мөмкинлек бирә.

Сергей Чемезов, «Ростех» Дәүләт корпорациясе генераль директоры:
– Заманча җитештерүләр ачу һәм көндәшлеккә сәләтле гражданлык продукцияләрен җитештерү – «Ростех» Дәүләт корпорациясенең иң мөһим бурычларының берсе. Күпфункцияле заманча Т-500 самолётларын чыгару өчен еллык куәте 100 һава судносын тәшкил иткән югары технологияле җитештерү ачылачак, ә инвестицияләрнең гомуми күләме 2,5 млрд сумга якын булачак. Т-500 очкычларын куллану сферасы бик киң: бу авиахимия эшләре дә, объектларны мониторинглау да, урманнарны саклау да. Әлеге машинага Россиядә генә түгел, чит илләрдә – Латин Америкасы, Африка, Европа һәм БДБ илләрендә дә ихтыяҗ зур булыр, дип ышанам.

КАЗАН.
ЯШЬ ПРОФЕССИОНАЛЛАР. КАЗАНДА КӨЧ СЫНАШУ

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты:
– Казанда узган «Яшь профессионаллар» Милли чемпионатына үзебезнең республикадан да, чит төбәкләрдән дә бик күп яшьләр килде. Бирегә илебез яшьләренең иң яхшылары җыелды.Сез – зур көч сынашуның финалистлары, бүген кемдер – беренче, кемдер – икенче, әмма сез барыбер – иң яхшылар. Без сезнең Татарстанда булуыгыз белән горурланабыз һәм август аенда WorldSkills дөнья чемпионатында көтеп калабыз. Әлбәттә, анда безнең илебез лаеклы чыгыш ясар, дип ышанабыз.

НӘРСӘ:

«Яшь профессионаллар (WorldSkills Russia)» VII Милли чемпионатының ябылу тантанасы

КАЙДА:

Казан, «Татнефть Арена»

КАЙЧАН:

24 май

Фотолар ТР Президенты сайтыннан алынды

ТУЛЫРАК:

Җырлы-биюле пролог, WorldSkills халыкара чемпионаты илчеләренең видеомөрәҗәгате, махсус компетенцияләрдә җиңүчеләрне котлау һәм Татарстанда узачак WorldSkills Kazan 2019 дөнья чемпионты флагы эстафетасына старт бирү – тантананың эчтәлекле һәм шул ук вакытта динамик программасы боларның барысын да үз эченә сыйдырды.

Россия Федерациясе мәгариф министры Ольга Васильева, катнашучыларга мөрәҗәгать итеп, VII Милли чемпионатның һәм булачак WorldSkills һөнәри осталык буенча 45нче дөнья чемпионатының һөнәри белем бирүне алга таба үстерү юнәлешендә олы бер баскыч булуына басым ясады. «Яшь профессионаллар» милли проекты кысаларында матди-техник җиһазланыш кына түгел, иң беренче чиратта, белем бирүнең эчтәлеге һәм сыйфаты көчле булачак», – диде министр.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, тантанада катнашучыларга мөрәҗәгать итеп, биредә, Татарстанның башкаласында, «бөтен Россиядән иң яхшылар» җыелды, дип белдерде. «Безгә бераз моңсу, чөнки шундый күркәм бәйрәм тәмамланды», – дип тә өстәде Президент.

Аннан соң Ольга Васильева белән Рөстәм Миңнеханов Татарстанда WorldSkills Kazan 2019 дөнья чемпионаты флагы эстафетасына старт бирделәр. Исегезгә төшерик, WorldSkills Kazan 2019 флагы эстафетасы Россиянең 24 төбәген, шулай ук дөньяның 20 илен һәм Халыкара космик станцияне колачлый. Эстафетаның соңгы ноктасы WorldSkills стандартлары буенча уздырылачак һөнәри осталыкның 45 нче дөнья чемпионатының ачылыш тантанасы булачак. Ул Татарстан башкаласында 22–27 август көннәрендә үткәреләчәк.

БЕЛЕШМӘ:

«Яшь профессионаллар (WorldSkills Russia)» VII Милли чемпионаты финалында мең ярымнан артык конкурсант көч сынашты, шулар арасында 363 юниор да бар иде. Өч көн дәвамында «Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәге мәйданчыгында 91 компетенция буенча иң яхшылар билгеләнде, шулай ук Future Skills блогына караган 23 компетенция буенча да җиңүчеләр ачыкланды. WorldSkills Russia Juniors ярышларында катнашучылар 48 компетенция буенча көч сынашты. Милли чемпионат ярышлары алты блокка тупланган һөнәрләр буенча үткәрелде: төзелеш өлкәсе, мәгълүмати һәм коммуникацион технологияләр, иҗат һәм дизайн, производство һәм инженерлык технологияләре, хезмәт күрсәтү тармагы, шулай ук транспорт һәм логистика. «Яшь профессионаллар (WorldSkills Russia)» Милли чемпионаты финалында командалар арасында Татарстанның җыелма командасы беренчелекне яулады. Шулай да максат – чемпионатларда катнашу һәм җиңү генә түгел. ТР Президенты билгеләп үткәнчә, беренче чиратта, дөнья күләмендә кулланылучы методикалар, технологияләр һәм стандартлар мөһим, ә аларны мәгариф системасына кертүдә Worldskills хәрәкәте зур роль уйный. Ярышлар яшьләргә бүгенге хезмәт базарында кирәкле, көндәшлеккә сәләтле булырга мөмкинлек тудыра.

Фото: Александр Ефремов

Ольга Васильева, РФ Мәгариф министры:
– WorldSkills Kazan 2019 дөнья чемпионатында җиңүебезне телим. Биредә оештыру эшләре бик югары дәрәҗәдә һәм без барлык дөнья стандартларына туры киләбез, дип уйлыйм.

ЯР ЧАЛЛЫ.
КАМАЗ: ВАКЫТ БЕЛӘН УЗЫШТА

Сергей Чемезов, «Ростех» Дәүләт корпорациясе генераль директоры, «КАМАЗ» ГАҖ Директорлар советы рәисе:
– Бәясе 14 млрд сумнан артык торган инвестпроектны тормышка ашыру КАМАЗга һәм Daimlerга Россиядә Индустрия 4.0 югары стандартларына туры килүче чыннан да заманча «цифрлы» фабрика төзергә мөмкинлек бирде. Аның куәте – елын 55 меңгә кадәр кабина ясау. Предприятиедә барлык процесслар да: идарә карарлары кабул итүдән алып станокларның техник торышына контрольлек итү һәм комплектлаштыру детальләрен китерүгә кадәр – барысы да автоматлаштырылган. Нәтиҗәдә биредә һәр эш урынының файдалылыгы башка гадәти производстволарга караганда биш мәртәбәгә югарырак.

НӘРСӘ:

«КАМАЗ» һәм Mercedes-Benz йөк машиналары өчен кабина каркаслары җитештерү буенча завод ачу

КАЙДА:

Яр Чаллы

КАЙЧАН:

27 май

Фотолар ТР Президентының рәсми сайтыннан алынды (Марсель Бадыйкшин)

ТУЛЫРАК:

КАМАЗ заводны 2016 елда Daimler компаниясе белән берлектә төзи башлады. Җитмеш мең квадрат метрга якын мәйданда дүрт цех урнаштырылды: буяу, эретеп ябыштыру, логистика һәм энергетика үзәге. Предприятиенең куәте: елына 55 мең кабина.

Яр Чаллыда йөк автомобильләре өчен кабина каркаслары җитештерү буенча яңа завод ачу Россия автогиганты белән иң эре халыкара автомобиль концерны – Daimler AG арасындагы хезмәттәшлек тарихында мөһим сәхифәләрнең берсе булып тора. Әлеге производствога ике компаниянең «Даймлер КАМАЗ Рус» уртак предприятиесе җитәкчелек итә. Кабина каркаслары КАМАЗның җыю конвейерына һәм Чаллыда Mercedes-Benz йөк автомобильләренең җыю производствосына китерелә. Яңа предприятиене кулланышка тапшыру 700 яңа эш урыны ачарга мөмкинлек бирә.

Завод автоматлаштыру дәрәҗәсенең югарылыгы буенча Россиядә иң беренче булачак. Премиаль сыйфатны тәэмин итәргә тиешле югары дәрәҗәдә автоматлаштырылган эретеп ябыштыру цехы, супер каты лак-буяу материаллары нигезендә инновацияле буяу технологияләрен куллану, җыю линияләренә транспортлау өчен махсус трейлерларга кабиналарны төяүнең автоматлаштырылган системасы – әлеге барлык яңа технологияләр Россиядә беренче тапкыр гамәлгә ашырыла. Кабина каркаслары заводын төзү өчен кертелгән гомуми инвестицияләренң күләме 14 миллиард сумнан артып китә.

БЕЛЕШМӘ:

Кабина каркаслары заводында иң яхшы дөньякүләм техник карарлар тупланган. Әйтик, мәйданчыкта 100 дән артык робот эшли. Модельләр рәте төрле озынлыктагы, биеклектәге һәм киңлектәге кабиналарның биш база моделеннән башлана. Модификацияләрнең гомуми саны 100 дән артык. Яңа заводта чыгарылачак кабина каркаслары К5 буынына караган «КАМАЗ» автомобильләре өчен тәгаенләнгән. Яңа продукция рәтенең беренче моделе – КАМАЗ-54901 магистраль тягачларын компания инде җитештерә башлады. Кабина каркаслары шулай ук Mercedes-Benz йөк машиналарының җыю производствосына да китереләчәк.

Андреас Дойшле, «Даймлер КАМАЗ Рус» предприятиесе генераль директоры:
– Кабиналар заводы проектын гамәлгә ашыру концернга «КАМАЗ» компаниясенә модельләр рәтен яңартырга һәм модернизацияләргә ярдәм итәчәк. Шуның белән Daimler AG Россия автомомбиль сәнәгатен үстерүгә үз өлешен кертә, җитештерү процессларын автоматлаштыруны һәм камилләштерүне иң югары дәрәҗәгә җиткерү максатында белеме, тәҗрибәсе һәм эшләнмәләре белән уртаклаша.

Сергей Когогин, «КАМАЗ» ГАҖ генераль директоры:
– Үз төрләре арасында иң яңа һәм иң заманча заводны эшләтеп җибәрү – КАМАЗны реинжиниринглау һәм яңа модельләр рәтен үстерү буенча олы проектның бер өлеше генә. Бүген без К5 буыны йөк машиналарын серияләп җитештерүне башлап җибәрәбез. Һәм мондый сандагы алдынгы дөньякүләм технологияләрне К5 автомобильләрен җитештерүгә җәлеп итү – КАМАЗ тарихында тиңдәше булмаган вакыйга.

Люблю Россию

РОССИЯДӘ ТОРМЫШ КАЙДА ЯХШЫРАК?

Русиядә кайда яшәү яхшырак? Кайчандыр Некрасов куйган бу сораудан тагын: киләчәктә ничек яшәрбез? Россиянең гади төбәген ничек иң шәпкә әйләндерергә? – дигәннәре дә туа. Әлеге сорауларга КФУның Идарә, икътисад һәм финанслар институты белгечләре – профессор, икътисад фәннәре докторы, җитештерү икътисады кафедрасы мөдире Ольга Демьянова белән икътисад фәннәре кандидаты, доцент, дәүләт һәм муниципаль идарә кафедрасы мөдире Ирина Глебова җавап бирә.

РОССИЯДӘ ТОРМЫШ КАЙДА ЯХШЫРАК?

Ольга Демьянова:

– Теләсә кайсы төбәк рейтингы – төбәк идарәсе карарларының дөреслеген чагыштыру индикаторы ул. Рейтинглар рәсми һәм матбугатта басылган мәгълүматка нигезләнә. Теләсә кайсы икътисадый рейтингның максаты – төбәкләрне чагыштыру һәм социаль-икътисадый картада һәркайсының позициясен билгеләү. Россия төбәкләренең икътисадый рейтингларына күз салсак, республикабызның тоткан урыны шактый нык һәм тотрыклы, аларның күбесе буенча Татарстан беренче урыннарда бара. Һәм хәзерге вакытта ирешелгәннәрне саклап калу актуальләшә.

ИННОВАЦИОН АКТИВЛЫК ЛИДЕРЛАРЫ

– Татарстан инновацион активлык буенча беренче урында бара. Ул шул позициясен кайчаннан бирле саклый?

– Инновацион системалар һәм инновацион активлыкның чагыштырмалы үсешен Россия инновацион төбәкләре ассоциациясенең РФ Икътисадый үсеш министрлыгы, төбәк администрацияләре вәкилләре һәм илнең әйдәп баручы экспертлары белән берлектә төзегән Россия инновацион төбәкләре рейтингы аша күреп була. Рейтингка төбәк инновацион системаларын мониторинглау һәм үстерүнең европача моделе нигез итеп алынган. Татарстан – лидерлар өчлегендә, Санкт-Петербург һәм Мәскәүдән генә калыша, рейтингның зурлыгы 0,67 гә тәңгәл (максималь зурлык – 1), үсеш 169,6% тәшкил итә. Татарстанның алда баруы биредәге инновацион активлыкның шактый югары дәрәҗәсе турында сөйли, аның нигезендә инновацион система белән нәтиҗәле идарә итү, инновацион инфраструктура булдыру гына түгел, бәлки төбәктә югары технологияле һәм фән белән бәйле җитештерүләр булу, актив гавами эшчәнлек (инновацион ярминкәләр, форумнар, конференцияләр, конкурслар) алып бару да ята. Студентларның инновацион идеяләрен, проектларын, инициативаларын стимуллаштыру, яшьләр арасында инновацион эшкуарлыкны популярлаштыру хисабына белем бирү системасын инновацион системага интеграцияләү мөһимгә әйләнә. Сүз дә юк, югары белемнең әһәмияте зур, чөнки киләчәктәге инновацион үсеш, инновацион эшкуарлыкны җәелдерү, эшкуар шәхесе тәрбияләнүгә нәкъ менә югары белем алган чакта нигез салына. Казан федераль университеты гыйльми мохитенең мобильлеге һәм активлыгы Web of Science, SCOPUS та индексацияләнгән журналларда бастырылу хисабына инновацион эшкәртмә һәм тикшеренүләрне югары көндәшлекле халыкара мәйданга чыгаруга үз өлешен кертә, һәм биредә киләчәктәге үсеш өчен потенциал бар. Боларның барысы да Татарстанга уңай синергетик нәтиҗә алу мөмкинлеген бирә.

РОССИЯДӘ ТУРИСТЛЫК ЛИДЕРЛАРЫ

– Татарстан тагын кайсы позицияләрдә алдынгы?

– Татарстан, гадәттәгечә Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан гына калышып, Россиядә туристлык лидерларыннан берсе санала. Рейтинг шактый ачык күрсәткечләрдән җыела: туристлык инфраструктурасының халәте, кунакларны урнаштыру чаралары булу, инвестицион проектларны гамәлгә кертү, транспорт инфраструктурасын үстерү, төбәктәге туристлык продуктларын рекламалау, туристлык мәгълүмат үзәкләре булу, төбәкнең Россиядәге һәм халыкара күргәзмәләрдә катнашуы, туристлык брендларын һәм туристлык продуктларын эшләү һәм рекламалау. «ТурСтат» аналитика агентлыгы мәкълүматларыннан күренгәнчә, 2018 ел нәтиҗәләре буенча Казанга 3,2 миллион турист килгән. Әлеге рейтингта алга куелу – интернеттагы хайп кебек эчке уңыш түгел, бәлки төбәкнең уңай имиджын формалаштыру буенча озакка сузылган максатчан

Автор:
Алсу Дәүләтшина

Фото: Ната Смирнова

эш нәтиҗәсе ул. Бу – Казанның 1000 еллыгына багышланган масштаблы чаралардан башлап, федераль һәм халыкара проектларда катнашу нәтиҗәләре. Универсиада, дөнья чемпионаты… Бу – республиканың яңа имиджын формалаштыру буенча төгәл стратегия нәтиҗәсе.

ҖӘЛЕП ИТҮ ЛИДЕРЛАРЫ

– Ягъни, ничек кенә әйтсәң дә, безнең төбәк шактый кызыктыргыч…

– Гомумән, төбәкнең кызыктыргыч булуы – шактый киң төшенчә, һәм һәр төбәк өчен ул аерым. Аңа кешене җәлеп итәрлек булуы да, тормыш уңайлыгы, балаларга белем бирү, сәламәтлек саклау сыйфаты, эшкуарлык белән шөгыльләнү яки эре компанияләрдә эшләү мөмкинлеге булу, карьера ясау перспективалары булу, мәдәни мирас, буыннан буынга күчә барган тарих та керә. Икенче яктан, төбәкнең бизнесны кызыктырырлык булуы, шул исәптән халыкара бизнесны да, башлангыч ташламалар алу мөмкинлеге, уңайлы транспорт логистикасы һәм инфраструктурасы, эшче көчләрнең билгеле бер сыйфаты зарур. Әлеге күрсәткечләр мөһим, һәм иң кызыгы шунда ки, алар, бер-берсенә йогынты ясап, гомуми нәтиҗәне көчәйтә яки зәгыйфьләндерә. Мисалга, бизнес өчен уңайлы шартлар яңа эш урыннары булдыру, җитештерүчәнлекне һәм моңа бәйле рәвештә эш хакын арттыруны стимуллаштыра.

«РИА Рейтинг» агентлыгы ел саен Россия төбәкләрендәге тормыш сыйфаты рейтингын тәкъдим итә. Анда тормыш шартларының төрле аспектлары һәм социаль сферадагы ситуацияләр исәпкә алына.

Рейтингта Росстат, Россия Сәламәтлек саклау һәм Финанс министрлыклары, РФ Үзәк Банкы, башка ачык чыганакларның мәгълүматы файдаланыла. Татарстан Республикасы барлык төбәкләр арасында 4 нче урында, Мәскәү, Санкт-Петербургтан һәм Мәскәү өлкәсеннән генә калыша. Рейтинг күрсәткече 66,1. Чагыштыру өчен: рейтингның иң югары күрсәткече (77,4) – Мәскәүнеке, иң түбәне (16,2) – Тыва Республикасыныкы. Һәм менә, республиканың икътисадый курсына кагылышлы тәнкыйть ишеткәндә, аларның үзләренә, әйдәгез әле, исемлек азагындагы төбәкләргә карап чагыштырыйк, дип әйтәсе килә. Тәнкыйть бит чагыштырмача нигезләнгән булырга тиеш.

Шуны аңлау мөһим: тормыш сыйфаты буенча рейтингтагы югары позицияләр кызыктыргыч бизнес-шартлар белән дә, инвестицион инициативалар белән дә тәэмин ителә. Әйтик, инвестицион җәлеп итүчәнлек рейтингы буенча, абсолют лидерлар – ике зур мегаполис: Мәскәү һәм Санкт-Петербург; Татарстан, Мәскәү өлкәсе, Ямал-Ненец автономияле округы, Сахалин, Ленинград, Белгород һәм Төмән өлкәләре исә алардан азга гына калыша. Мондый позиция төбәктәге институциональ мохитнең уңайлылыгы һәм башка төбәкләр белән чагыштырганда бизнес өчен шартларның яхшырак булуы турында сөйли.

Икенче яктан караганда, инвестицияләр базарында көндәшлеккә сәләтлелек югары, конкуренция тышкы гына түгел, эчке инвестицияләр өчен дә бара. Россиядәге 85 төбәкнең 64е үз позицияләрен элекке дәрәҗәдә саклап калган, нибары 5 төбәк кенә үзенең рейтингын яхшырткан һәм 16сы на-

РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫНЫҢ ТУРИСТЛЫКНЫ ҮСТЕРҮ БУЕНЧА БӨТЕНРОССИЯ РЕЙТИНГЫ

Рейтинг	Күрсәткеч	РФ субъектлары
Лидер төбәкләр		
1	93,8	Мәскәү ш.
2–3	93,0	Санкт-Петербург ш., Татарстан Республикасы

РОССИЯНЕҢ ГАДӘТИ ТӨБӘГЕ НИЧЕК АЛДЫНГЫГА ӘЙЛӘНГӘН

чарайткан шартларда әлеге юнәлештә эш тагын да куәтләнәчәк һәм тагын киеренкерәккә әйләнәчәк. Мәгълүм булганча, инвестицияләр һәм икътисадый, һәм социаль үсешнең нигезе бит.

ҺӘР АВЫЛГА БАРЫП ҖИТКӘН СТРАТЕГИЯ

Ирина Глебова:

– Эш төбәкне дөрес стратегияләүдә. Казан өчен беренче социаль-икътисадый үсеш стратегиясе 2003 елда ук язылды. Бу безнең өчен тәүге тәҗрибә булды. Әлеге документта тәкъдим ителгән проектлар шәһәрне тәзекләндерү өчен Бөтендөнья үсеш банкы акчасын җәлеп итү мөмкинлеген бирде. Стратегия тышкы экспертларның югары бәясенә лаек булды. Күп кенә үсеш күрсәткечләренә инде 2013 елда ук ирешелде.

Аннары глобальрәк процесс башланды, «Татарстан Республикасының 2030 елга кадәр стратегиясе» эшләнде. Ул 2,5 елга сузылды һәм 2015 елда стратегиянең кабул ителүе белән тәмамланды. Әмма төбәк моның белән генә чикләнмәде. Тагын бер адым ясалды. ТР Президенты һәр муниципаль районның стратегиясен эшләү бурычын куйды.

2016 ел КФУ өчен бигрәк тә актив булды. Безнең укытучылар районнарда стратегик сессияләр уздыру һәм стратегияләрнең үзләрен язуда киңәш бирүдә турыдан-туры катнашты. Мин районнарда үз төбәге өчен янып йөрүчеләр белән очрашкан бу чакны аеруча бер җылылык белән искә төшерәм.

Район стратегияләрен эшләү биргән иң мөһим нәрсә исә – диалог өчен этәргеч! Соңгы елларда муниципаль районнар үзара катгый көндәшлектә иде. Алар без алдарак сөйләгән рейтинглар өчен көрәшә. Һәм кинәт аларга бөтенләй башка бурыч куела – районара проектлар эшләү һәм муниципалитетара хезмәттәшлекне үстерү мөмкинлекләрен табу. Бүген бу безнең Татарстан агломерацияләрен үстерү өчен зарур. Район вәкилләре, башлык һәм урынбасарлар башта сүзсез калды. Яңа тәртипне кабул итүгә ярты көн сарыф ителде. Төркемнәрдә эшләүчеләрнең кәефе ничек үзгәрүен, районнар чигендә уртак яшелчә базасы яки калдык эшкәртү заводы төзү буенча яңа идеяләр эзләгәндә күзләренең яна башлавын күзәтү бик кызык иде. Берләшү мөмкинлеге һәм зарурлыгы бик шәп ич!

Бик зур эш эшләнде. Һәр район үзенең үсеш стратегиясен язды һәм аны ТР Икътисад министрлыгында барлык тармак министрлыклары каршында яклады. Минемчә, бу диалог урнаштыру өчен куәтле этәргеч кенә түгел, бәлки турыдан-туры карар кабул итүче кешеләрнең стратегик фикерләү тәҗрибәсен арттыру өчен дә яхшы мәктәп булды.

Хәзерге вакытта агломерацион үсеш стратегияләрен язу бара, анда муниципалитетара хезмәттәшлек бәйләнешләре тагын да тирәнәергә тиеш.

Бүген шуны аңлау мөһим: Татарстанның лидерлык позицияләрен саклау өчен, төбәк эчендә нәтиҗәле үзара хезмәттәшлек, үзара ярдәм кирәк. Без шул вакытта гына Россия төбәкләре рейтингларындагы беренче урыннарыбызны саклап кала алачакбыз.

Татарстанның стратегияләр төзү тәҗрибәсе инде мәгълүм. Аның турында сөйлиләр, безнең университетка укырга җитәкчеләр генә түгел, Россиянең башка төбәкләре, якын чит илләр вәкилләре дә килә.

Күп кенә инновацион идеяләрнең нәкъ менә безнең Татарстанда тууы сөендерә. Безнең креатив идарәче кадрларыбыз даими укый, үз квалификациясен күтәрә. Һәм бу үзенең җимешләрен дә бирә. Күп яңа проектлар гамәлгә ашырыла, алар безнең республикадагы тормыш сыйфатын яхшырту мөмкинлеген бирә.

ЯРЫШЫРГА ТҮГЕЛ, БЕРЛӘШЕРГӘ

Ольга Демьянова:

– Хәзер кооперация хисабына отарга, яңа сыйфат һәм үзлекләр алырга мөмкин. Тарихка күз салыгыз: кооперацияне көндәшлек алыштыра, бераз вакыт үткәч, процесс кабатлана. Без ниндидер уникаль технологияләр уйлап таба алмыйбыз икән, аларны башкалардан сатып алу отышлырак. Берләшү һәм эреләнү дәүләтләр үсешендә дә, корпорацияләр үсешендә дә даими күзәтелә.

Конкуренция идарә ителә торган процесска әйләнә икән, бу инде аның юкка чыгуын аңлата. Шунлыктан ниндидер бер мизгелдә конкуренция кооперациягә

ТӨБӘКЛӘРНЕҢ ТОРМЫШ СЫЙФАТЫ БУЕНЧА РЕЙТИНГЫ ЛИДЕРЛАРЫ – 2018



ТӨБӘКЛӘРНЕҢ ТОРМЫШ СЫЙФАТЫ БУЕНЧА РЕЙТИНГЫНДА ТӨБӘКЛӘРНЕҢ РЕЙТИНГ БАЛЛЫ



ТӨБӘКЛӘРНЕҢ ТОРМЫШ СЫЙФАТЫ БУЕНЧА РЕЙТИНГЫНДА ИДЕЛ БУЕ ФЕДЕРАЛЬ ОКРУГЫ ТӨБӘКЛӘРЕНЕҢ РЕЙТИНГ БАЛЛЫ



Чыганак: www.riarating.ru

КИЛӘЧӘКТӘ НИЧЕК ЯШӘЯЧӘКБЕЗ

кучәргә тиеш. Әгәр без нормаль көрәшә алмыйбыз икән, димәк, без бергәләп нәрсә булса да төзергә тиеш.

КИЛӘЧӘККӘ ТӨЗӘТМӘЛӘР КЕРТҮ ЗАРУР

Ирина Глебова:

– Сез Татарстанны киләчәктә ничек күзаллыйсыз?

– Гәрчә бүген киләчәкне сурәтләгән мәкалә һәм китаплар күп булса да, аны күзаллау шактый катлаулы. Әмма нәтиҗәдә ничек булыр – тормыш үзе күрсәтәчәк һәм үз төзәтмәләрен кертәчәк. Мисал китерәм. 2003 елда Казанның стратегиясен эшләгәндә, алдагы 15 елда тормышыбызның шулкадәр үзгәрәсен күз алдына да китерү кыен иде. Без амбицияле максатлар куйдык, ул чакта ук тормыш сыйфатын яхшыртуның мөһимлеге, шулай ук грамоталы һәм нәтиҗәле идарә итү турында сөйләдек. Нәтиҗәдә төрле исәпләүләр үткәрелде һәм көтелгән күрсәткечләр фаразланды, аларның күпчелеге 10 ел эчендә гамәлгә ашырылды. Кайбер әйберләрне фаразлау бик катлаулы булды. Мәсәлән, һәр йортта телефон булсын, дигән күрсәткеч бар иде. Ә хәзер исә безнең һәр йортта гына түгел, гаиләдәге һәр кешедә кесә телефоны бар. Ул чакта без моны күз алдына да китерә алмый идек әле.

Глобаль тенденцияләр бар. Аларга игътибар итми булмый. Теләсәң-теләмәсәң дә, алар барлык икътисадый процессларга йогынты ясый. Планлаштыру процессы барганда, глобаль тенденцияләр һичшиксез исәпкә алынырга тиеш. Татарстан стратегиясе белән дә шул ук хәл. Дөнья шулкадәр мобиль һәм үзгәрүчән ки, куелган эчке таләпләргә җавап бирү һаман кыенлаша бара. Вакыт уза, документлар үз актуальлеген тиз югалта. Әйтик, 2018 елда ТР стратегиясенә үзгәрешләр кертү буенча актив эш алып барылды инде. Бу нәкъ менә заманча цифрлы тенденцияләргә бәйле иде. Көндәшлеккә сәләтле булыр өчен, инновацион санлы технологияләрне җитештерү һәм идарә процессларына актив кертү зарур.

БАШТА – ВАТАНЫҢ, АННАРЫ ГЫНА ПЛАН ҺӘМ ФАРАЗЛАУЛАР ТУРЫНДА УЙЛА

– Фараз һәм планнар гамәлгә ашсын өчен, сезнеңчә нәрсә эшләргә кирәк?

– Мөгаен, бөтен фаразлар да чынга ашырга тиеш түгелдер. Менә, мәсәлән, ясалма интеллект, геннар инженериясен алыйк. Әлеге экспериментлар һәм яңа ачышларның нәтиҗәсе әле билгеле түгел. Бер яктан караганда, фәнни тикшеренүләр безгә куркыныч авырулардан котылу мөмкинлеге һәм өметен бирә, икенче яктан караганда, без моның кемнәрнеңдер кулында куркыныч коралга әйләнү ихтималлылыгын да яхшы аңлыйбыз. Атом бомбасы төзү белән аналогия китерергә була. Аны ачу яңаны тудыргыч та, җимергеч тә нәтиҗәләргә китерде бит. Цифрлаштыру һәм роботлаштыру процессларыннан киләчәктә нәрсә көтәргә – әлегә билгесез.

Ольга Демьянова:

– Фаразлар турында сөйләгәндә, аларның нигә кирәклеген, асылын, кем төзүен аңларга кирәк. Без студентлар белән төрле аналитика агентлыклары, ведомство, министрлыклар, әйдәп баручы белгечләрнең 2008 елдан башлап икътисадый фаразларын өйрәндек һәм мондый нәтиҗәгә килдек: бер генә фараз да тормышка ашмый. Һәм иң кызыгы да шунда – бу нормаль хәл санала. Фараз – вакыт ягыннан да, ерак киләчәк ягыннан да масштаблы төшенчә. Ә менә планнар – бөтенләй башка: аларда конкрет чаралар һәм адымнар тәгаенләнә. Монда инде башкарылуны контрольдә тотарга, төзәтмәләр кертергә мөмкин. Мин студентларыма һаман әйтә килəм: әгәр үз тормышыгызны планлаштыра алмыйсыз икән, сез предприятие, тармак һәм төбәк үсешен дә планлаштыра алмаячаксыз. Һәрвакытта да үзеңнән башларга кирәк. Фаразлар тормышка ашмый, без аларга ирешәбез!

– Без – ул Татарстан, Россияме?

Ирина Глебова:

– Әйе, әлбәттә. 1990 нчы елларда Россия төбәкләренең актив суверенлашу процессы барды. Бу җәһәттән безне дә битәрләүчеләр табылды. Әмма хәзер Татарстан турында тату һәм кунакчыл төбәк сыйфатында гына сөйлиләр. Туристлык инфраструктурасын үстерү, шулай ук вакыйгаи һәм эшлекле туризмны үстерү хисабына без туристлык рейтингларында кинәт күтәрелдек. Безгә истәлекле урыннарны карарга дип кенә түгел, өйрәнергә дип тә киләләр. КФУда Африка, Һиндстан, Мексика, Кытайдан, якын чит илләрдән килгән студентлар укый. Чит илләрдән килгән студентлар безнең җәмгыятьнең толерантлылыгын, куркынычсызлыгын һәм уңайлылыгын югары бәяли. Бу бик мөһим.

Һәм тагын бер фишка: Казан да барлык федераль һәм дөньякүләм чараларның актив катнашучысына әйләнде. Без федераль мәйданчыкларны яулау өчен Мәскәү, Питер һәм башка шәһәрләр белән ярышабыз.

– Бу шәһәрдә, төбәктә ничек чагыла?

– Универсиада, барлык спорт чараларын уздыру шәһәрне төзекләндерү һәм инфраструктурасын үстерүдә гаять зур әһәмияткә ия булды. Казанны башка миллионер-калалар белән чагыштырганда, миңа ул башкалардан күпкә кызыклырак тоела. Безнең шәһәрнең үзеге үзенчәлекле, архитектурасы бик матур. Хәтта Европадан килгән кунаклар да аны мактый, үз шәһәрләренә охшата.

Уңайлылык ягыннан да без алдынгы урыннарда. Кабат рейтингларга мөрәҗәгать итсәк, шәһәрләрдәге тормыш сыйфатын бәяләүче «Стрелка» консалтинг агентлыгы 2018 елда, Мәскәү белән Санкт-Петербургтан гына калыштырып, безнең Казанны һәм Түбән Новгородны өченче урынга куйды.

– Без шәһәр турында сөйлибез, ә авылда уңайлы шартлар бармы соң?

– Уңайлылык җәһәтеннән бездә бик күп эшләнде, бигрәк тә авылны төзекләндерү программасы буенча. Кая гына барма – бөтен җирдә төзекләндерелгән

парклар, ремонтланган мәктәпләр. Медицина ФАПлары, яр буйлары, спорт объектлары төзелгән. Соңгы биш елда вазгыять яхшы якка бик үзгәрде.

Ольга Демьянова:
– Авылдагы уңайлылыкны шәһәрдәге белән чагыштырып булмый, алар бер-берсен тулыландыра кебек. Шәһәрдәге уңайлылык – көндәшлеккә сәләтле яхшы белем бирү, югары технологияле медицина хезмәте күрсәтү, югары хезмәт хакы, эшкә урнашканда сайлау мөмкинлеге булу. Авылларда болар барысы да чикләнгән. Мәсәлән, кечкенә авылны алыйк, анда төрле яшьтәге 10–20 бала бар. Аларга ничек итеп сыйфатлы яхшы белем биреп булсын?! Бер бүлмәдә 1–4 сыйныф балалары укыганны күз алдына китерегез инде. Төрле яшьтәге балалар төркемнәргә берләшә. Укытучы бер үк вакыт эчендә аларга төрле контент бирә. Шулай булса да төркемнәр аралаша башлый, төркем дәрәҗәсе исә ул – иң зәгыйфь уенчы дәрәҗәсе. Иң кече бала өчен аның үзеннән өлкәнрәкләр белән булуы яхшы анысы, ә менә өлкәнрәкләр өчен бу бер дә файдага түгел инде!
Дөнья тарихына күз салсак, авыл-шәһәрләр генә түгел, хәтта зур дәүләтләр дә юкка чыккан. Территориаль үсеш траекториясе шундый. Һәм монда шуны аңлау мөһим: теләсә кайсы территория үсеш ноктасына әйләнә ала, һәм мәдәни мирас, халык, тарих белән бәйле уникаль контент мөһимләшә. Шул ук вакытта ул инвестицияләр башлангычына, аларны җәлеп итү, нииндирер яңа мөмкинлекләр ачылу ноктасына да әйләнә. Озак вакытка исәпләнгән планда мондый территорияләр кеше өчен уңайлана. Халык авылдан шәһәргә генә түгел, бер илдән икенчесенә дә күчә һәм моны туктатып булмый. Кеше үзе сайлый. Бу һәрвакыт шулай булган, бар һәм булачак.

РОССИЯНЕҢ РУХИ ҮЗӘГЕ

– Татарстанны Россиянең үзәге, дип әйтеп буламы?

Ирина Глебова:
– Ул Идел буе федераль округында лидер, дип әйтеп була. Чөнки башка төбәкләр бездән күпкә артта бара. Тормыш сыйфаты, инфраструктуралар үсеше һәм тулаем кызыктыру буенча.
Һәм әле тагын креатив карарлар үзәге буларак та, нәкъ менә шулар Татарстанга үз позицияләрен даими саклап калырга мөмкинлек бирде.

– Кешеләр Татарстанга ни өчен килә?

Ольга Демьянова:
– Без амбицияле төбәк, шунлыктан барысы да хәлебездән килә. Әйдәгез күрше төбәкләрдәге мәшгульлекне чагыштырып карыйк, мәсәлән, Мари Эл, Чувашстанны алыйк. Татарстан – үзенә генә түгел, якындагы төбәкләр өчен дә эш урыннары булдырган төбәк ул. Күрше төбәк балалары кайда югары белем ала? Халык кайсы клиникаларга бара? Менә игътибар бирелергә тиешле өч нәрсә: Татарстан янәшә, 40 минутлык арада гына. Һәм син анда сыйфатлырак хезмәт, белем, медицина ярдәме ала аласың... Ә боларның барысы артында нәрсә тора? Һәркемнең үз эш урынында тырышып эшләве һәм үзе туып-үскән ватанын яратуы. Шунлыктан бездә шәһәрдә дә, авылда да уңайлы булып чыга. Барыбызны да берләштерә торган нигез менә шул.

– Татарстанны Россия белән нәрсә берләштерә?

Ирина Глебова:
– Биредә кешеләргә бик рәхәт, өйләреннән дә чыгып китмәгән кебек. Монда толерантлык гаять зур роль уйный. Катнаш никахлар, горефгадәтләр, бәйрәмнәр – мәсәлән, татарлар Пасхага йомырка буйый, руслар Ураза гаетенә бәлеш пешерә. Һәрвакыт бер-берсенә ярдәм итәләр. Татарстанны Россиянең рухи үзәге дип атап була.

ЛИДЕРЛАР КОМАНДАСЫНА КУШЫЛЫРГА

– Ягъни, мәсәлән, шул ук Мари Эл пилот мәйданчыкка әйләнергә тели икән, моның өчен нәрсә кирәк?

Ольга Демьянова:
– Моның өчен үз халкын һәм төбәген яратучы көчле идарәчеләр командасы кирәк. Калганы инде механика: идарә системасын төзү, планлаштыру, җитештерүне оештыру, команданың яңа өндәүләрне кабул итү сәләте.

– Әгәр пилот район түгел икән, димәк, ул ялкаурак төбәк булып чыгамыни?

– Монда аңлау мөһим: ялкаулык – кешенең кыенлыкларны җиңеп чыгудан баш тарту омтылышы, ихтыяр көче күрсәтергә, уңайлылык зонасыннан чыгарга теләмәве. Һәм бу һәркемгә таныш халәт, теләсә кайсы яшьтә (хәтта физиологик яктан) кеше үз энергиясен мөмкин кадәр күбрәк сакларлык итеп яратылган. Әмма барыбер һәркемгә үз тормышын яхшырак, кызыклырак, бәхетлерәк итү теләге хас. Мондый тәртипнең нигезендә исә яхшырак, тизрәк, ераграк алга бару теләге ята. Төрле конференцияләрдә булганда, Татарстан җитәкчеләренең федераль үзәк белән уртак тел табу сәләтенә соклану еш ишетелә. Ул диалог алып барырга һәм үз мәнфәгатьләрен кайгыртырга сәләтле. Дөрес сәясәт алып бара һәм яхшы нәтиҗә күрсәтә. Һәм без тагын: әйе, бу да эш һәм үзеңнең рәхәтлек зонаңнан чыгу, дибез.
Икътисадка мөнәсәбәт тә мөһим. Мәсәлән, мирасны да тиз арада туздырып бетерергә сәләтле кешеләр бар. Федераль бюджетка бөтенләй бернәрсә дә бирмәгән төбәкләр дә бар. Шулай булса да, алар үз динамикаларында берничи яңалык уйлап табарга омтылмый. Һәм монда инвестицион финанслау гына түгел, бәлки инвестицияләрне арттыру һәм зур җитештерү предприятиеләре, уңайлы транспорт инфраструктурасы, туристлык системасы, мәгариф, сәламәтлек саклау сыйфатындагы капитал туплау осталыгы мәсьәләсе актуальләшә, ә теләсә кайсы капиталның нигезендә – кешеләр! Хәзер төбәкләр, шулай ук дөньяның төрле илләре арасында санлаштыру, сәнәгать революциясе, технологик укладны алыштыру буенча яңа мөмкинлекләр ачыла, аларны һич тә кулдан ычкындырырга ярамый. Яңа үсеш проектлары эшләп, хәзер үк кушылырга кирәк. Акыл ияләре әйтүенчә, сиңа кыен икән, димәк, син дөрес юлда. Алга баручы кеше генә максатына ирешәчәк!

МӘКТӘП. КИЛӘЧӘКТӘН КАРАШ

Берләшкән Милләтләр Оешмасының милләтара сәясәт комитетын безнең якташыбыз – казанлы Искәндәр Гомәров җитәкли башлады. Аның тынычлыкны яклап ясаган чыгышын чит ил гаммәви мәгълүмат чаралары «соңгы унъеллыкта иң көчле чыгыш», дип бәяләде инде. Үзенең «Washington Post» газетасына биргән интервьюсында Гомәров милләтара килешү һәм гуманизм идеяләре белән мәктәптә укыганда ук кызыксына башлавын искә ала. Моны күргәч, редакциябездә: «Бу бит репортаж өчен менә дигән тема!» – дип илһамландык.

Автор:
Катерина Котова

ЭЧКЕРСЕЗ МӨНӘСӘБӘТ

Һәм менә мин инде шул мәктәп ишеге төбендә басып торам. Директор белән очрашканчы бер ун минутлап вакытым бар. Аны файдалы үткәрим әле – купшы табличка артына чынбарлыкта нәрсә яшерелгәнне сиздерми генә бераз күзәтим. Сүз уңаеннан, бу – полилингваль мәктәп, димәк, биредә бер генә түгел, берничә телдә укыталар.

Коридор буйлап барам. Беренче карашка, барысы да гадәттәгечә кебек – чыр-чу, шау-шу, балалар көлүе, атлаган тавышлар... Кыңгырау шалтырый, һәм мине гаҗәпләндергән иң беренче нәрсә – беркем дә сыйныфларга таралырга ашыкмый. Барысы да холлдагы йомшак диваннарда утыра.

– Доброе утро! Хәерле иртә! Good morning! – дип сәламли балаларны укытучы. – Бүген нәрсә турында хыялланыйк икән?

– Тема бар! – дип кулын күтәрә чәчләре тырпайган бер малай. – Әгәр Җир халкы башка планеталарга яшәргә китсә, алар үзләре белән нинди китаплар алырга тиеш?

«Кара әле син боларны...» – дип уйлап куйдым мин балаларның әлеге «марсианнар» китапханәсен нинди дәрт белән туплаганнарын күзәткәндә. «Син нәрсә! Платонны онытырга ярамый!», «Пушкин, Тукай – болар бит безнең классика!» Барысы да йокыдан уянып бетте, ахры...

«Без балаларның мәктәп режимын үзгәрттек. Сезнең каршыда – белем бирүгә табигатькә ярашлы якын килү», – ди әкрен генә кемдер колагыма. Директор!

– Иртәнге сәгать сигездә балаларның нәтиҗәлелеге бик түбән – алар әле йокыдан уянып бетмәгән! – дип дәвам итә ул. – Без аларны «уятабыз». Хәзер балалар мәктәп ресторанында иртәнге аш ашаячак. Һәм әле унынчы яртылар тирәсендә генә, балалар организмы өчен физиологик актив вакыт җиткәч, сыйныфларда беренче дәрес башланачак. Мондый дәресләрнең файдалылык коэффициенты югарырак була...

Бик яхшы бит бу. Миңа моны ишетү сәеррәк, чөнки безнең хәзерге мәгариф системасы күбрәк фабрика белән ассоциация тудыра – укучыны, конвейер буенча җибәргәндәй, укытучылар кулдан кулга, бер кабинеттан икенчесенә тапшыра, һәм аларның баланың күңеленә үтеп керү өчен вакыты калмый. Тик нигә биредә башкача соң?

– Теләк булса – фән булыша! – дип шаярта директор. – Гуманлы педагогика турында Жан-Жак Руссо ук язып калдырган бит. Хәтерлисезме: «Тәрбия ул – көч кулланмыйча, басым ясамыйча, тәрбияләнүченең иректә эшчәнлегенә юнәлеш бирү, аның табигый сәләт һәм мөмкинлекләрен үстерү», – дигән.

Әлеге ыгы-зыгылы компаниядә тагын бер өлкән кешене күрәм – чәчләре тулымлап үрелгән кызчыкка таба бер хатын-кыз иелгән. Бер үк вакытта тәрбияче дә, педагог та, мәктәп психологы да булган тьюторларның берсе икән. Аның бурычы – үз шәкертләренең шәхси уңыш стратегиясен күзәтеп тору. Беренче сыйныфта укучы кыз баланың никтер кәефе киткән икән – монда, һичшиксез, аны юатачаклар, аның белән сөйләшәчәкләр. Карыйм – чыннан да елмая башлады, димәк, көне уңышлы үтәчәк.

Биредә балаларга шундый игътибарлы мөнәсәбәт күрсәтергә укытучыларны гына түгел, әтиәниләрне дә өндиләр, мәктәптә… Ата-аналар университеты эшли бит. Хәер, бу яңалык түгел – идеяне совет педагог-новаторы Василий Сухомлинский мирасыннан алганнар. Тәрбия процессы стихияле, оешмаган булмаска тиеш, ә бүгенге саннардан гына торган ашкынулы дөньяда нәкъ менә шул күзәтелә дә. Ата-ана «тизлеккә корылган тормышның» тотыгына әйләнде, үз балаларын яхшырак белер өчен, аларга ничек вакыт табарга? Мәктәп университетында исә алар балалар дөньясын танып белә, сабыйларының яшь үзенчәлекләре, физиологиясе һәм психикасына игътибар бирергә өйрәнә. Гармония һәм гуманизмга тагын бер адым бу. Шунлыктан бу мәктәптә ярату җитмәгән балалар юк диярлек икән.

БИРЕДӘ ДӘРЕСЛӘР ГАДИ ГЕНӘ ТҮГЕЛ...

Бер ишекне ачып керәм – беренче «А» сыйныфында математика бара. Балалар мәсьәлә белән «көрәшә»: өрәңге агачында биш яфрак бар иде, икесе коелган… Барысы да гадәттәгечә кебек…

– Ә хәзер тагын бер мәсьәлә чишәбез, тик бусы инде татарча, – ди укытучы. – Кәримнең алты алмасы бар иде…

Балалар тырыша – җавап тиз табыла. Сүз уңаеннан әйткәндә, русчадан татарчага яки инглизчәгә күчү монда һәр дәрестә кулланыла. Шул рәвешле беренче сыйныф укучыларында яңа белемне бер генә түгел, берьюлы өч телдә алу күнекмәсе формалаша.

Күрше кабинетта өченче «Б» сыйныфында хезмәт дәресе бара. Инглиз телендә! Музыка белән рәсем дәресләре дә инглизчә. Җиденче «В» сыйныфында математика, биология һәм география – инглиз, химия һәм физика – рус, тарих һәм җәмгыять белеме татар телендә укытыла. Биредә укучы-

лар өчен бу катлаулы түгел. Ничек мөмкин соң бу?

Сез гаҗәпләнерсез, әмма бу полилингваль мәктәп федераль белем бирү стандартлары кысаларында эшли. Әйе, ул иҗат өчен зур мөмкинлекләр тудырмый, әмма биредә дөрес юлны тапканнар – көн буена укыту мәктәбе иткәннәр һәм полилингвальлек концепциясен дәрестән тыш эшчәнлек хисабына тормышка ашырганнар. Әйтик, башлангыч сыйныф укучыларының атнасына кимендә бишәр тапкыр инглиз һәм татар теле өйрәнү мөмкинлеге пәйда булган. Бу инде өченче сыйныфта ук әлеге телләрдә иҗади һәм гамәли предметлар кертергә мөмкинлек биргән, мәсәлән, балалар дәрес буе вак-төяк әйберләр ясый һәм үзләренең бөтен гамәлләрен инглиз телендә аңлата бара. Бу иҗат, уен кебек кенә, шул ук вакытта исә – яңа сүзлек запасын формалаштыру, телне ишетеп аңларга өйрәнү дә булып тора. Шулай, әкренләп, җиденче сыйныфка кадәр укучылар өч телдә дә яхшы сыйфатлы белем алуга күчеп бетә. Рус, инглиз һәм татар телләре алар өчен бертигез дәрәҗәдәге белем алу коралына әйләнә.

Сүз уңаеннан, мондый практика да яңалык түгел. Мәскәү һәм Ленинградта предметларны тирәнтен өйрәтү һәм инглиз телендә укыту буенча беренче мәктәпләр Сталин указы белән инде 1948 елда ук пәйда булган. Хрущёв чорында алар күпләп ачыла башлаган. Шунлыктан совет дидактикасы бу тармакта шактый яхшы тәҗрибә туплаган. Моннан тыш, дөнья педагогикасы эшкәртмәләре дә бар, мәсәлән, CLIL предмет-телне интеграллаштырып өйрәтү ысулы. Мәктәптә барлык бу казанышлардан файдаланалар һәм шәп нәтиҗәләргә ирешәләр.

Татар телен кертү катлаулырак барган. Мәктәптә төрле милләт балалары укый, ә татар телен чит тел буларак укыту тарихы шактый кыска. Бу хәлдән ничек чыкканнар соң?

– Без ТР Фәннәр академиясе галимнәре ярдәмендә рус телле балалар өчен яңа татар теле дәреслеге булдырдык, – дип сөйли директор. – Ул Европа тел портфеле принципларында төзелгән. Әлеге инновацион программа яхшы сыйфатлы телдән һәм язма сөйләм күнекмәләрен тиз арада формалаштыру мөмкинлеген бирә. Әйе, без ике ел эчендә генә барлык укучыларның белемен уртачалаштыра алмыйбыз. Әмма безнең өчен башкасы мөһим: татар теле ана теле булмаган бала өченче сыйныфка кадәр кимендә ике мең лексик берәмлекне үзләштерергә тиеш. Татар телендә беренче предметларны мәктәптәге дәресләр челтәренә кертү өчен, нәкъ менә шундый белем күләме зарур.

Сүз уңаеннан, биредә мәгариф һәм фәннең үзара хезмәттәшлеге бик тыгыз. Мәктәп каршында чит телләр лингводидактикасы һәм татар теле лингводидактикасы буенча берьюлы ике лаборатория ачылган. Аларның һәркайсы белән үз эшендә янып йөрүче галимнәр җитәкчелек итә, дәресләрне дөрес оештыру, яңа ысуллар кертү, хаталар булдырмауда алар педагогларга чынбарлык режимында диярлек ярдәм итә. Аларның күп еллар буе чарланган тәҗрибәсен бүген республиканың күп мәктәпләре өлге итеп ала.

ҖИҺАН КЕШЕЛӘРЕ

Дәресләрдән соң ишегалдында Нәүрүз бәйрәме гөрли. Аллы-гөлле ярминкәгә мәктәп балалары һәм укытучылар гына түгел, бөтен тирә-як халкы агыла! Татар күн мозаикасы һәм саламнан белорус эшләнмәләрен, русларның Дымков уенчыгын һәм бизәкле мари сөлгеләрен барысын бергә тагын кайда очрата аласың? Бәләкәй Алимбәк кыргыз биюен бии, Мәдинә – Муса Җәлил, Вера исә Есенин шигырьләрен укый, Әгыйлә – курайда, Дима гармунда уйный… Барысын да Нәүрүз берләштергән. Һәм тагын – мәктәп, бүген анда ата-аналар җитәкчелегендә унҗиде милли диаспора эшли бит. Анда балалар үз туган мәдәниятләре белән танышып кына калмый, башка халыкларның гореф-гадәтләрен хөрмәт итәргә дә өйрәнә, Татарстан – күпмилләтле төбәк бит.

Директор миңа мәктәпнең концепциясе нигезендә үзара хөрмәт фәлсәфәсе ятуы турында сөйли. Шунлыктан, бер яктан караганда, дәрестән тыш предметлар арасында килешү фәлсәфәсен тапкач, мин гаҗәпләнмим дә кебек. Икенче яктан караганда, аның

нәрсә турында булуын күз алдыма да китерә алмыйм.

– Менә әйтегез әле миңа, безнең мәктәпләрне тәмамлаучылар арасында Җиһановның «Алтынчәч» операсы сюжетын белүчеләр күпме? Аларга Яруллин музыкасы танышмы? Фешин һәм Шишкин картиналарын күргәннәре бармы? – дип кызып сүзен башлый әлеге предметны инде җиде елга якын укытучы Дмитрий Авенирович. – Боларны белмичә, белемле, фикерле кеше тәрбияләү мөмкинмени?Аннары тагын, әгәр яшүсмер үз мәдәниятен белмәсә, ул, мәсәлән, чит ил әдәбияты – супер, безнеке исә «отстой», дип уйлаячакмы? Мондый хәл булмасын өчен, без белем бирү процессына Татарстан халыклары мәдәнияте буенча курс кертергә тырышабыз, күпмилләтле һәм күпконфессияле җәмгыятебездә балаларны үзара хөрмәткә һәм сабырлыкка өйрәтә торган килешү фәлсәфәсе төшенчәсен аңлатабыз. Әйе, безнең максат – чын зыялы кешеләр тәрбияләү.

Табигатькә ярашлы якын килүне искә төшерәм. Программа буенча дәресләр, телләр һәм милли мәдәният дәресләре, спорт һәм иҗат түгәрәкләре... Әле тагын өй эше эшлисе дә бар бит! Кечкенә кеше өчен бу бик авыр түгелме?

– Яхшы укытучы өйгә эшне аз бирә, – дип елмая директор. – Аның күп булуы укучының уңышларына берничек тә йогынты ясамый. Әмма безнең дәресләр челтәрендә үзлектән әзерлек сәгате бар – балалар өлгерә. Проблема туса, тьюторлар ярдәмгә килә. Һәм кичке сәгать 4 тән соң бала өенә бөтен эшен диярлек эшләп бетереп кайтып китә. Шунлыктан әтисе, кич саен улының өй эшләрен тикшерер урынга, аның белән бергә мәктәп кванториумына килә һәм сыерчык оясы ясый. Әнисе белән кызы исә кулинария остаханәсендә кыстыбый пешерергә өйрәнә. Безнең мәктәп белем алу урыны гына түгел, кешеләр бер-берсе һәм балалары белән аралашырга өйрәнә торган тарту үзәге дә бит.

ХЫЯЛЫЙЛАР ПОСТСКРИПТУМЫ

Кадерле укучым, гаҗәпләнергә ашыкма. Искәндәр Гомәров чыгышын эзләп яңалыклар актарма, мәктәп адресын табу өчен танышларыңа шалтыратырга да ашыкма. Болар барысы да безнең хыял гына. Хәер, рәхәтләнеп чынга ашарлык хыял!

Яңа полилингваль белем бирү комплексы бик тиздән ачылырга тиеш. Менә ул – нигезе һәм субайлары әзер инде! Миңа аларны Айдар Шәмсетдинов күрсәтә – без аның белән бергә хыялланган идек. Айдар Илдар улы – Казанның 165 нче мәктәбе директоры, әлеге комплекс, идеологлар фикеренчә, «Адымнар – путь к знаниям и согласию» проектының беренче «карлыгачына» әйләнергә тиеш. Проектның идеясе исә Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе һәм «Яңарыш» республика фондының Попечительләр советы рәисе Минтимер Шәймиевнеке.

2022 елга Татарстанда өч телдә укыта торган барлыгы алты полилингваль комплекс ачылырга тиеш – Казанда, Яр Чаллыда, Әлмәттә, Түбән Камада, Алабугада. Алар составына, мәктәпләрдән тыш, шулай ук полилингвальлек концепциясе кысаларында эшләячәк балалар бакчалары һәм өстәмә белем бирү үзәкләре дә керер, дип фаразлана.

Ничә бина төзеләчәге һәм аларны нинди заманча матди база белән җиһазландырачакларына без биредә тукталып тормыйбыз. Әйе, бу мөһим, әмма без биредә проектның асылын гына аңлатырга тырыштык. Бу киң колачлы проектның максаты – республикабыз кысаларында заманча белем бирү комплексы төзү, ул безнең балаларга көндәшлеккә сәләтле булу һәм кимендә өч телдә иркен сөйләшү мөмкинлегенә бирәчәк.

Ә «Искәндәр Гомәров» кем соң ул? Шул идеаль мәктәпне тәмамлаучы инде! Ул уңышлы гына түгел, бәлки үз милли мәдәниятен яратучы һәм башка халыклар традицияләрен хөрмәт итүче шәхес тә. Үз тамырларын онытмаучы җиһан гражданы. Киләчәк кешесе. Һәм яхшы кеше.

– Безгә барыбызга да төрле табигый сәләтләр, әмма бер үк төрле зур йөрәк бирелгән, – ди Айдар Шәмсетдинов. – Мәктәп әлеге йөрәкне сизгерлеккә өйрәтә торган урынга әйләнергә тиеш.

БЕЛЕМ АША – КИЛЕШҮГӘ ҺӘМ БЕРДӘМЛЕККӘ

ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев полилингваль мәктәпләрнең зарурлыгы турында.

Иң әүвәл татарлар, татар теленә кагылышлы мәсьәләләрне әрнеп кабул иттек. Ничә еллар буе без РФ һәм ТР Конституцияләренә таянып эшләдек. **Әмма шундый көчләр табыла ки – ана телен кысу омтылышы куәтләнә. Болай булырга тиеш түгел. Ана теле – беренчел.** Бу кемгәдер ошарга, кемгәдер ошамаска мөмкин. Мин һәрвакыт әйтә киләм: бу турыда фикер йөртә башлаганчы, үзегезне туган телегездән мәхрүм итеп карагыз әле, аннары нәтиҗә ясарсыз. Мәсьәлә синең үзеңә кагылмаганда, аның турыда фикер йөртү бик җиңел бит. Бу – бик нечкә материяләр, саграк булырга кирәк.

Проблема чыннан да бар, чөнки Россия – күпмилләтле дәүләт. Мәсьәләне тыныч, сабыр хәл итү өчен көчеңне дә, вакытыңны да кызганмаска кирәк. Нигә тынгысызланырга һәм кеше күңелендә шик уятырга? **Бу сак мөнәсәбәт таләп итә торган өлкә. Безнең үзебезгә дә туган телне укытуның нәтиҗәлерәк методикаларын эшләргә күптәннән кирәк иде.** Без дөньяга ачыла төшкәч, мөнәсәбәт тә үзгәрде.

Хәзер мин белем бирү комплекслары белән таныша башладым. Үзем өчен бу дөньяны ачам. Кембридж һәм дөньядагы башка тәҗрибәләрне өйрәнәбез. Хәзер балалар да башка, аларга дөньякүләм мәгълүмат кыры ачык. Алар, балалар бакчасыннан башлап, күп нәрсәгә өйрәнә ала. Башлангыч мәктәпне дә кушсаң һәм белем бирүне оста итеп оештырсаң, балалар бик күп нәрсәне үзләштерергә сәләтле. Дөньякүләм практика да шуны күрсәтә, бу турыда галимнәр дә сөйли.

Хәзер полилингваль белем бирү юлыннан бер Татарстан гына бармый. Мәскәүдә инде йөзләрчә белем бирү комплексы бар. ЮНЕСКОда Франция тәкъдим иткән карар проекты карала. Аның буенча ЮНЕСКО әгъзасы булган дәүләтләрдә кимендә ике чит тел өйрәнелергә тиеш. Бөтен җиһанда шундый эш бара, моны тормыш үзе таләп итә.

Без үзебезнең беренче белем бирү комплексына база итеп нигә 165 нче мәктәпне сайладык? Бирдә Россиядәге иң шәп мәктәп директорларының берсе Айдар Шәмсетдинов эшли. Аның мәктәбендә татар телен һәм башка телләрне өйрәнү буенча проблемалар юк, төрле милләттән булган эти-әниләр арасында аңлашылмаучанлык та күзәтелми. Гәрчә **бу мәктәптә берничә төрле милләт баласы укыса да. Кайсыдыр – русча, кайсыдыр – татарча, аннары үзара инглизчә сөйләшәләр, телләрне катнаштырып та җибәрәләр.** Шундый гөрелте анда! Мәктәптә укыганда мин умартачылык белән шөгыльләнгән идем, шунлыктан андагы умарта эчендәге кебек гүелдәү тавышы миңа яхшы таныш.

Белем бирү комплекслары маякка әйләнергә тиеш. Хәзер дә бит инглизчә укыта торган мәктәпләр бар, әмма түләүле һәм бик кыйммәт. Без башкачарак эшләргә тырышачакбыз. Барлык тәкъдимнәрне апрель башында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән карадык. Иң әүвәл алты белем бирү комплексыннан башларга булдык.

Ни өчен без әлеге белем бирү комплексларын оттырышсыз вариантка саныйбыз? Беренчедән, бу уку-укыту базасының матди тәэмин ителешен яхшырту. Башка төбәкләр белән чагыштырганда, республикабызда ул болай да начар түгел. **Без белем бирү комплексын мәктәп тә, балалар бакчасы да булган җирдә оештырабыз. Сыналган методика буенча барабыз: мәктәпләрнең берсе базага әйләнә. Әгәр аны үзгәртеп корырга кирәк икән – үзгәртәбез.** Мәсәлән, без 165 нче мәктәпнең хәзерге бинасына янкорма өстибез. Тик бу янкорма гына түгел, бу – киләчәктә башлангыч мәктәпкә әйләнәчәк бина. Ә яңа урында – Бондаренко урамында – урта мәктәп төзибез. 1025 укучыга исәпләнгән урта мәктәп проектын алдык. Һәм болар барысы бергә тулы комплекс булачак: база балалар бакчасы, башлангыч база мәктәбе һәм урта база мәктәбе.

Полилингваль мәктәпләрне тәмамлаучылар югары белемле кешеләр булачак. Без көндәшлеккә сәләтле балалар укытып чыгарырга тиеш. Ата-аналарга һәм мәктәпләрдәге ата-аналар советларына зур роль бирелә. Иң мөһим мәсьәлә – кадрлар әзерләү. Татар теле һәм инглиз теле укытучылары җитми. Әлеге мәсьәләне

Фото: «Татар-информ» МА

хәл итүгә Мәгариф һәм фән министрлыгы, педагогика көллиятләре һәм институтлары тартылды. Алар Чаллыда, Алабугада бар, әмма өйрәнеп, нәрсәне үзгәртергә, нәрсә үстәргә кирәклеген хәл итү зарур. Моның белән хәзер республиканың Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан федераль университеты конкрет шөгыльләнә. Лаеклы педагоглар әзерләргә кирәк.

Социаль-икътисадый үсеш күрсәткечләренә күз салсак, безнең күп нәрсәгә сәләтле булуыбыз күренә. Уйлап кына карагыз әле, елына 600 миллиард сум чамасы инвестицияләрнең кемнең төшенә кергәне бар? Кайчандыр без миллион квадрат метр торак төзү турында хыяллансак, хәзер 2,4 миллион квадрат метр төзибез. Шунлыктан без күп нәрсәне хәл итәргә сәләтле. Әмма мәгариф мәсьәләсе катлаулырак булачак, бигрәк тә милли факторны исәпкә алганда. Без ни өчен моңа күзебезне йомарга тиеш әле? **Проблемаларны уңай хәл итү һәм шул ук вакытта көндәшлеккә сәләтле балалар тәрбияләү өчен безнең акылыбыз җитәргә тиеш. Бу бит безнең балаларыбызның язмышы, ничек инде моның белән шөгыльләнмисең ди?**

Ни өчен алты комплексмы? Икесе – Казанда, тагын – Яр Чаллыда, Әлмәттә, Түбән Камада һәм Алабугада. Без аларны аякка бастырачакбыз һәм нәтиҗәләр ясаячакбыз. Без әле бу системага шәһәрдән читтәге ел буена эшли торган белем бирү кампусларын да кертәбез.

Һичшиксез, чыгымнар күп булачак. Тагын бер кат әйтәм: матди база кертемнәр таләп итә, әмма гамәлдәгеләрен исәпкә алып эшләү зарур. Кайдадыр балалар бакчасына капиталь ремонт ясарга, кайдадыр төзеп бетерергә, кайдадыр мәктәпкә янкорма өстәргә, кайдадыр заманча җиһазлар белән тәэмин итәргә кирәк. **Заманча белем бирү мәйданы булдыру зарур. Балалар белемне аралашу, уку, танып белү барышында алырга тиеш.**

Бу юл җиңел түгел, әмма башкасы юк бит. Ихтимал, кирәге чыкса, бюджетны да кабат бүләргә туры киләчәк. Хәзер башларга, сынарга, юлларын табарга һәм ялгышларны төзәтергә кирәк – башкача булмый. **Потенциал бар, без генетик яктан сәләтле халык. Тормыштан артта калачакбыз икән, үкенечле булачак. Киләчәк хакына хәзер килешү табу зарур.**

Беренче комплексны без «Адымнар – путь к знаниям и согласию» дип атадык. Бу гыйбарә очраклы гына түгел, без аны уйлап сайладык. Бу – белем аша килешүгә, бердәмлеккә атлау. Ышандырып сөйлимме икән, юкмы, әмма моның белән шөгыльләнергә кирәк, дип саныйм. Без бит тикмәгә генә «Хәрәкәттә – бәрәкәт», димибез, хәрәкәтләнмичә генә бернәрсәгә дә ирешеп булмый.

Материал «Интервью без галстука с Андреем Кузьминым» программасы нигезендә әзерләнде.

УЛ БАЛАЛАРГА **РОССИЯНЕ АЧА**

Географияне сыйныфта утырып өйрәнү – бер хәл, ә менә рюкзак асып, атластагы тау сыртлары һәм елга бассейннары буйлап бик җиңел генә шуган күрсәткеч таякка ияреп, дөньяның үзенә чыгып китү – бөтенләй башка.

Ерак араларны үз аягың белән үлчәү, тау башына менеп, күз алдында пәйда булган гүзәллектән телсез калу, таң каршылау, учак янында төн чыгу... – бик күп баланың хыялы, һәм Хәмзә Абдрахманович Кильдиев хыялларга тормышка ашарга мөмкинлек бирә. Казандагы «83 нче лицей – Мәгариф үзәге» МББУ география укытучысы җәяүләп тә, чаңгыда да, машинада да, поездда да бөтен Россияне диярлек аркылыга-буйга йөреп чыккан инде.

Мәктәп балаларын беренче тапкыр сәяхәткә ул 1973 елда алып бара – Кама Тамагы янәшәсендәге Юрьев мәгарәләренә. Кышын мари урманында мич ягып җылытыла торган землянкада яшиләр. Хәзер инде ул «балаларга» да алтмыш тулып килә. Очрашканда, беренче эш итеп, походларын искә төшерәләр...

– Хәзер эти-әниләр балаларын җәен чит илгә, мәсәлән, Төркиягә алып бара. Үз җирен белмәгән тулы бер буын үсеп килә, – дип кайгыра Хәмзә Габдрахманович. – Мин, зур стажлы турист буларак, Россиядәге кебек искиткеч ландшафтларның һәм уникаль табигать һәйкәлләренең дөньяда башка бер җирдә дә булмавы турында теләсә кем белән бәхәсләшә алам! Балага Ватанга мәхәббәтне бары тик турпоходларда гына сеңдереп була. Ул илебезнең искиткеч зурлыгын, аның кабатланмас матурлыгын сәяхәттә генә тоя башлый. Бу ватанпәрвәрлекнең нигезен тәшкил итә. Элегрәк без ел саен диярлек тулы сыйныфлар белән сәфәргә чыга идек. Бервакыт хәтта 97 кешелек төркем тупланды. Ул елларда без яшьләрне шул рәвешле урам йогынтысыннан саклап калырга тырыштык. Нәкъ менә

Фотолар Хәмзә Кильдиевның шәхси архивыннан



Яшь туристлар туган җирләре белән хозурлана...

Хәмзә Габдрахманович Кильдиев – үз эше белән гаять мавыккан һәм укучыларын да кызыктыра алган совет укытучысы. Дәртле, энергияле, иртәгә үк походка чыгып китәргә әзер!

70 нче елларда Казанда беренче җинаятьчел төркемнәр пәйда булды. Туристлык бик күпләрне имгәнүләрдән яки төрмәдән саклап калды. Минем яныма хәзергә кадәр элеккеге укучыларым килеп йөри, рәхмәт әйтәләр. Сыйныф белән очрашуларга чакыралар.

Ул чакта балалар туризмы киң таралган иде, чөнки шәһәрдә – туризм федерациясе, һәр районда исә яшь туристлар станциясе эшләде. Пионерлар сараенда, институтларда секцияләр ачылды. Казан туристлык клубының даны бөтен илгә таралды, чөнки бездә тәрбияләнгән спорт мастерлары һәм оста разрядчылар күп иде. Шефлар да күп ярдәм итте ул елларда. Иганәчеләрне шулай атыйлар иде. Безне Вахитов исемендәге химкомбинат үзенә сыендырды. Алар ярдәме белән Мурманскига, Ташкентка, Алма-Атага, Карпат тауларына очтык...

Кильдиев җитәкчелегендә укучылар төркемнәре шулай ук Уралда, Алтайда, Адыгеядә, Ыссык күлдә, Тянь-Шаньда, Байкал буенда, Саянда һәм Кырымда була. Былтыр лицей директоры Диләрә Бикуева һәм мэр Илсур Метшин инициативасы белән поход оештырыла. Лицейга килгән мэр, ташлар музеен карагач, берәр төрле ярдәм кирәкмиме, дип кызыксына. Хәмзә Габдрахманович югалып калмый, булачак турпоход өчен иганәче кирәклеген әйтә. Мэр ярдәме белән 30 кешелек төркем Кавказдагы Лагонаки платосына сәяхәт кыла.

– Төркем зур булса, мин аны җидешәр кешегә бүләм һәм өлкән сыйныф укучыларын җитәкче итеп куям, – дип аңлата Кильдиев. – Билгеле, куратор укытучылары да бар, тик алар балаларның иреген кысмый, шунлыктан укучылар үзгәрә, җаваплылык аларны мөстәкыйльлеккә өйрәтә.

Малайлар һәм кызлар үзләренең иптәшләре өчен җаваплы булуына төшенә, алар күзгә күренеп көрәя, өлкәнәя. Командага ияләшә алмаганнары исә китә. Андыйларны балалар киләсе походларга алмый инде. Көн саен эшләргә, авыр йөк ташырга, палатка куярга, учак кабызырга, тауга үрмәләргә кирәк... Сәфәрдә дуслык та ныгый.

– Быел без Байкал буена җыенабыз, – дип, планнары белән бүлешә Хәмзә Габдрахманович. – 21 мәктәп баласы һәм 6 өлкән кешелек төркем тупланды. Тайгадагы сырт буйлап йөз чакрым үтәсе. Мин башта маршрутны карта буенча салам, аннары, кирәкле җиргә барып җиткәч, юлны өйрәнәм. Башта үзем барып карыйм, аннары гына балалар белән сәфәргә чыгам. Бу зур җаваплылык бит. ■

Автор:
Гадел Хәеров

Тәҗрибәле кеше киңәше. Бияләй яки оекбашны киптерү өчен, аларны төнгелеккә корсагыңа куеп ятарга кирәк.

Яшәү белән үлем арасында... Тянь-Шаньдагы инструкторлар җыенында мин, кар катламы астыннан күрмичә, бозлы ярыкка төшеп киттем. Ярый әле иптәшем янымда иде, ул югалып калмады һәм бик тиз арканыма ябышты. Мин, тарзанкага асылынган кебек, чайкалып тордым, аста җир күренми иде. Әмма бу вакытта бер дә курыкмадым, судьяларның очколарымны киметүләренә генә кайгырдым.

Кар күмде. Кар ишелмәсе астында ятарга да туры килде. Бу 1980 нче елларда Уралда булды. Без өчәү идек, беребезне кыяга атып бәрде, икенчебез билдән батты, мин исә ике метр калынлыктагы кар астында калдым. Менә шул чакта мин уйларымда яшь хатыным белән хушлаштым инде. Әмма каешка бәйләнгән капрон тасманы күреп алып, мине таптылар һәм казып чыгардылар.

1974 ел.

WORLDSKILLS. ШӘП СТАРТ

«WorldSkills Russia» VII илкүләм чемпионаты җиңүчеләрен бүләкләү тантанасында «Татнефть Арена» сәхнәсенә күтәрелгән һәр икенче кеше шатлык яшьләрен тыеп кала алмады. Ярыш призерлары хөрмәтенә күтәрелгән Россия төбәкләре флаглары арасында югарыга барыннан да ешрак Татарстан флагы үрләде.

Автор:
Алёна Кутыркина

Чемпионатның беренче көнендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов илкүләм бәйгеләр оештыруны бөтендөнья ярышлары алдыннан генераль репетиция дип атады. Нәтиҗәләр чыгарганнан соң, республика җыелма командасының медаль хисабында беренче урын алуы билгеле булды.

– Татарстан өчен чемпионатларда катнашу һәм җиңү генә түгел, беренче чиратта, белем бирү системасына Worldskills хәрәкәте белән кертелә торган иң яхшы дөнья методикалары, технологияләр һәм стандартлар мөһим. Бу – яшьләргә хәзерге заманның хезмәт базарында көндәшлеккә сәләтле һәм кирәкле булырга мөмкинлек бирә. Шуңа күрә сезнең әлеге финалда ышанычлы җиңүегез – карьерагызның, халыкара ярышларда яңа җиңүләрнең, һөнәри осталыгыгыз формалашуның шәп старты ул. Сез бик зур тәҗрибә тупладыгыз, ул киләчәк карьерагызда һәм шәхси үсештә бәяләп бетергесез өстенлек бирәчәк, – дип мөрәҗәгать итте республика башлыгы Татарстан җыелма командасына.

ҺӘРКЕМНЕҢ КҮЗ АЛДЫНДАГЫ ҺӨНӘРИ ЮНӘЛЕШ

92 компетенция буенча киеренке ярышлар өч көн барды. Аларның күп өлешен «Казан Экспо» Халыкара күргәзмә үзәге кабул итте. Аның һәр кластеры күпләгән секцияләргә бүленгән иде. Тамашачылар бина эчендә иркенләп йөреп, конкурс биремнәренең үтәлү процессын күзәтә алды.

...Бүлмәләрнең берсендә яңа пешкән икмәк исе таралган. Үтәкүренмәле, ике катлы дивар артында ярыш бара, бәйгедә катнашучылар бик зур игътибар белән эшли. Кемдер камыр баса, кемдер мичне тикшерә, ә кемдер инде күмәченә матур, ипле рәвеш бирә. Күрше сектордагы нәфис гәүдәле кызга, шактый көч куеп, авыр блоклар белән эш итәргә туры килә. Аңа ландшафт дизайны өлкәсендәге күнекмәләрен күрсәтергә – бетон эшләнмәләрдән билгеле бер форма булдырырга, композицияне төрле үсемлекләр белән бизәргә кирәк. Тагын да түрдәрәк төзүчеләр ярыша: секторда инде әзер дип әйтерлек кирпеч диварлар калкып чыккан. Табло буенча фикер йөрткәндә, эш бетәргә 20 минуттан азрак вакыт калган. Ярышта катнашучылар, соңгы рәтне куйганчы, өймә һәм җөйләрнең тигезлеген кабат-кабат тикшерә...

Төрле һөнәр вәкилләренең эшен биредә – Worldskills чемпионатында гына үз күзләрең белән күреп була. Нәкъ менә шуңа күрә «Казан Экспо»га экскурсиягә урта махсус уку йортлары укучылары һәм студентлары килгән иде. Балалар һәр яңа секция янында тукталып, яшьтәшләренең станоклар һәм инструментлар белән җитез идарә итүен сокланып карап торды. Бәлки, чемпионатның күп кенә кунаклары үзләре өчен нинди һөнәр сайларга икәнен нәкъ менә биредә карар иткәндер.

Фото: Алёна Кутыркина; «Татар-Информ» МА



ХИСЛӘР ТУЛЫП ТАШЫЙ

– «Шәфкать туташы эше» компетенциясендә үз осталыгыбызны күрсәтергә безгә Казан мәдәният институты студентлары ярдәм итте. Алар өлкән яшьтәге кешеләр итеп гримланган иде һәм төрле модульләр өчен кирәкле рольләрне башкарды, – дип сөйли Казан медицина көллиятенең 3 нче курс студенты **Луиза Мәхмүтова**. – Җирәбә буенча мин кич белән, бик соң чыгыш ясадым, көн буе борчылып йөрдем һәм шунлыктан бик арыдым. Максималь балл җыя алмам инде дип уйлаган идем. Әмма беренчелекне яуларга насыйп булды. Нәтиҗәләрне игълан иткәч, мине хис-кичерешләр ташкыны биләп алды. Алтын медаль тапшырганда, бәхеттән еладым.

«Башлангыч сыйныф укытучысы» компетенциясендә алтын медаль белән…» дигән җөмләдә үз исемен ишеткәч, **Мария Сангинова** да шуңа якын хис-тойгылар кичерә.

– Мин җиңү өчен бар көчемә көрәштем, бик авыр булды, хәтта тавышым бетте… – Казан педагогика көллияте студенты, хатирәләрен барлаганда, күз яшьләрен тыя алмый. – Озын-озак тренировкалар бушка китмәде. Бүләкләү вакытында сүз белән аңлатып бетергесез хисләр кичердем.

ӨЛКӘН ЯШЬ – КОМАЧАУ ТҮГЕЛ

Чемпионатта катнашучылар белән бер мәйданчыкта яңалык: тәүге тапкыр монда өлкәнрәк яшьтәге белгечләр дә ярышты. 26 компетенциядә 50 яшьтән өлкәнрәк 200 катнашучыны берләштергән «Зирәкләр күнекмәләре» номинациясе яраткан эшеңә яшьнең һич комачауламавын күрсәтте.

Өлкән яшьтәге, чал чәчле волонтер белән очрашуым да шуны раслады. Чемпионат дәвамында **Наилә Ибраһимова** ярыш кунакларын каршы алырга ярдәм итә. Аның волонтерлык тарихы 2013 елгы Универсиадада ук башлана, шул вакытта ук дөньякүләм масштабтагы чаралар энергиясе ташып торган әлеге ханым тормышының аерылгысыз өлешенә әверелгән.

– Казан өчен, шәһәр кунаклары өчен нидер эшләү мөмкинлеге барлыкка килүгә, уйлап та тормый ризалык бирәм. Бирелә, «Казан Экспо» үзәгендә, шундый яшьтә үк инде менә дигән осталарга әйләнгән һәм алга баруны, үз максатларына омтылышны туктатмаган егет-кызларны күрү бик күңелле. Безнең чорда хезмәт юлын сайлау авыр булды, чөнки мәктәп укучыларына һөнәри юнәлеш бирү тиешле дәрәҗәдә алып барылмады. Хәзер яшьләрнең мөмкинлекләре шулкадәр күп, бу миңа да көч-дәрт бирә, – ди тамашачылар өчен сервислар волонтеры.

Быел **Наилә Ибраһимовага** 81 яшь тула, шуңа карамастан аның волонтерлык эше графигы берничә ай алдан язып куелган.

ҺӨНӘРИ КИЛӘЧӘК

Илкүләм чемпионат көннәрендә «Казан Экспо» эшлекле сөйләшүләр мәйданчыгына да әйләнде. Россия Федерациясе Хөкүмәте рәисенең социаль сәясәт мәсьәләләре буенча урынбасары Татьяна Голикова катнашында узган пленар утырышта хәзерге белем бирү системасының проблемалары турында фикер алыштылар. «Сколково» Мәскәү идарә мәктәбе гамәли профессоры, киләчәктә белем бирү модельләре һәм күнекмәләре өлкәсендә белгеч сыйфатында чакырылган Павел Лукша кызыклы фикер белдерде:

– Һөнәрләр дөньясы үзгәрә, шунлыктан мәгариф системасы сыгылмалырак булырга тиеш. Быелтыр без уздырган тикшеренүләр күрсәткәнчә, 2029 елда иске һөнәрләр белән мәшгуль 10 млн кеше (ким дигәндә), эш урыннарын ташлап чыгып китәргә мәҗбүр булачак. Калыплашмаган карарлар кабул итәргә әзер креатив профессионалларга сорау туачак.

Проблема шунда ки, нинди-дер бер һөнәр икътисадка бөтен кирәк түгел, ә башкаларын әлегә укыта-өйрәтә торган урын юк. Хәзерге шартларда кайбер компетенцияләрнең тормыш циклы 10–15 елны тәшкил итә, шуңа күрә кеше үз тормышында берничә төрле карьера үтәргә мөмкин, без мондый хәлләргә әзер торырга тиеш. Аерым бер һөнәр үсешенә генә түгел, үз-үзеңне үстерүгә дә өлеш кертү зарур. Уку-укыту экосистемасы хезмәт күнекмәләрен кешегә оффлайн да, онлайн да үзләштерергә мөмкинлек бирә торган белем провайдерына әйләнергә тиеш.

Әлеге фикер алышу нәтиҗәләре Россия мәгариф системасы өчен якындагы елларга бер юнәлеш булачак. Әле эшләнергә генә тиешле бу программаның максаты – төрле өлкә һәм яшьтәге белгечләр өчен уңайлы белем алу мохите булдыру һәм аларны эшкә урнаштыру.

«Веб-дизайн һәм сайт эшләү» компетенциясендә беренче урын алган **Рәшит Сабиров** та теләсә кайсы яшьтә укырга кирәк дип саный:

– Минем компетенциядә катнашучылар күп, әмма дүрт төбәк кенә көчле иде, Татарстан – шулар арасында. Без былтыргы җиңүчеләр тренер сыйфатында чыгыш ясаган җирдә өстенлек бар дип уйлаган идек, ләкин биремнәр ел саен катлаулана бара һәм һәркем үзенең белем дәрәҗәсен күтәреп торырга тиеш булып чыкты. Бигрәк тә программалаштыру юнәлешендә, чөнки анда мәгълүмат тиз искерә. WorldSkills хәрәкәтенә әлегүемә мин бик шат, чөнки бүтән беркайда да мондый тәҗрибә һәм белемнәрне ала алмаган булыр идем.

КАМИЛЛЕК ОЧРАКЛЫ ТҮГЕЛ

WorldSkills Kazan 2019 чемпионаты стартына өч айдан азрак вакыт калды. Бүген медаль яулаганнар ил җыелмасының киңәйтелгән составына тәкъдим ителәчәк, шулай ук 2021 елда Шанхайда узачак дөнья чемпионатында һәм 2022 елда Санкт-Петербургта үтәчәк EuroSkills Европа чемпионатында Россия данын яклау мөмкинлеге алачак.

Казанда узачак дөнья чемпионатында 69 илдән 1500 дән артык яшь белгеч катнашыр дип көтелә, алар 56 компетенциядә ярышачак.

«Мода технологиясе» компетенциясендә беренче урынны алган **Хава Гагиева** EuroSkills бәйгесендә чыгыш ясарга ниятли:

– Бу бәйгегә юл бик озын һәм авыр булды, ләкин мин көндәлек эшемнән дә, нәтиҗәдән дә канәгать калдым. Призлы урын алмаган егетләргә-кызларга мөрәҗәгать итәргә телим идем: нәрсә дә булса уңышлы килеп чыкмаса, туктарга кирәкми. Минеке дә беренче тапкырдан гына килеп чыкмады, әмма үҗәтлек һәм тырышлык нәтиҗәсендә Татарстанга алтын медаль яулый алдым, ә хәзер Россиягә барып алтын алырга җыенам.

– Августта Россиядә, Казанда булачак бәйгене бөтен дөнья игътибар белән күзәтеп торачак. Һөнәри осталык җәмгыять, компанияләр һәм тулаем ил үсешенә этәргеч бирә. Бәйгедә катнашучыларга: «Камиллекнең беркайчан да очраклы булмавын онытмагыз», – дип мөрәҗәгать итәсем килә. Бу – үҗәтлек, зур хезмәт һәм тырышлык нәтиҗәсе! – дип сәламләде ярышларда катнашучыларны WorldSkills International башкарма директоры Дэвид Хоуи.

WORLDSKILLS RUSSIA 2019 САННАРДА

447,5 балл – Татарстан җыелма командасы нәтиҗәсе. Яуланган медальләр саны: 55 алтын, 47 көмеш һәм 39 бронза.

438 балл – Мәскәү җыелма командасы нәтиҗәсе. Яуланган медальләр саны: 91 алтын, 22 көмеш һәм 22 бронза.

147 балл – Мәскәү өлкәсе җыелма командасы нәтиҗәсе. Яуланган медальләр саны: 13 алтын, 17 көмеш һәм 22 бронза медаль.

www.protatarstan.ru
Поиск...
РУС | ТАТ
ТАТАРСТАН
Подписка!
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
Тукайның билгесез хаты?
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
06 июня 2019
05 июня 2019
Ишми ишан: ике дәвер чигендә
Кзыл Ялан: кечкенә дә төш кенә
Затлы мирас кайда саклана
Тукайның билгесез хаты?
Шәриф Хөсәенов. Тормышның
Сугыш җырлары: күпме
Татарстан Язучылар берлеге
Реклама 16+

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Уяв Гырон быдтоннан **НИЧЕК** аерыла

«Россия лидеры» **КҮПМЕ** көндәшен узган

Солтан өстәлен бизәрлек сыйны **НИЧЕК** пешерергә

Команданы **НИЧЕК** республиканың брендына әйләндерергә

Бакчачы **НИНДИ** сыйлар белән сыйлый

БӘЙРӘМ ТЕРРИТОРИЯСЕ: УЙНАГЫЗ, ГАРМУННАР!

10 АЕРЫМЛЫКНЫ *яисә* ОХШАШЛЫКНЫ *тап*

Татарстан – Россия халыклары бәйрәмнәре территориясе. Милли костюмнар, милли сыйлар, милли җыр һәм биюләр – болар барысы да бабаларыбыз яшәгән чорлардан алып, күпмилләтле Татарстанның төрле почмакларында яшәүче халыклар дуслыгы белән сугарылып, бүгенге көнгә кадәр сакланып калган. Республикада һәркем әти-әнисе традицияләрен саклаучы, туган телен яратучылар гына бәхетле булуын аңлый, шуңа күрә тарихи ватаннарыннан ерак яшәгәндә дә кешеләр туган йортларының җылысын тоеп яшәсеннәр өчен барысын да эшлиләр.

КАРАВОН РУС ХАЛЫК БӘЙРӘМЕ

УЯВ ЧУВАШ МӘДӘНИЯТЕ РЕСПУБЛИКА БӘЙРӘМЕ

#Добро пожаловать! #Рәхим итегез! #Гажаса ӧтиськом! #Ырӑ сунса кӗтетпӗр! #Пагален ӱжына!*

Фото: Александр Ефремов, «Татар-информ» МА

* Рәхим итегез!

САБАНТУЙ ТАТАР ХАЛЫК БӘЙРӘМЕ

СЕМЫК МАРИ МӘДӘНИЯТЕ БӘЙРӘМЕ

#Добро пожаловать! #Рәхим итегез! #Гажаса ӧтиськом! #Ырӑ сунса кӗтетпӗр! #Пагален ӱжына!*

БӘЙРӘМ ТЕРРИТОРИЯСЕ: ТҮГӘРӘК БИЮ

ГЫРОН БЫДТОН | **УДМУРТ ХАЛЫК БӘЙРӘМЕ**

ПИТРАУ | **КЕРӘШЕННӘРНЕҢ ХАЛЫК БӘЙРӘМЕ**

#Добро пожаловать! #Рәхим итегез! #Гажаса ӧтиськом! #Ырӑ сунса кӗтетпӗр! #Пагален ӱжына!*

* Рәхим итегез!

10 АЕРЫМЛЫКНЫ *яисә* ОХШАШЛЫКНЫ *тап*

САБАНТУЙ ТАТАР ХАЛЫК БӘЙРӘМЕ

КАРАВОН РУС ХАЛЫК БӘЙРӘМЕ

#Добро пожаловать! #Рәхим итегез! #Гажаса ӧтиськом! #Ырӑ сунса кӗтетпӗр! #Пагален ўжына!*

ГАСЫР ПОРТРЕТЛАРЫ. ТАТАРСТАНГА ГАШЫЙК



Игнат **Петухов** 25 яшь

Свердловск өлкәсендә туып-үскән Игнат Петуховка хыялына ирешү өчен берничә ел кирәк була. Хыялы исә... Татарстан була. «Әгәр үз төбәгегезгә читтән карасагыз, аның кешене ни белән җәлеп итүе шундук күренәчәк: бу – үсеш мөмкинлекләре дә, кешеләр дә, хәтта бирәдә хөкем сөргән атмосфера да», – ди Игнат. Хыялына илтәсе юлның җиңелен түгел, әмма җиңүлесен сайлаган ул. Татарстанга Игнат «Алабуга» Корпоратив университеты үткәргән конкурста җиңү аша килгән.

Ул вакытта Свердловск өлкәсе Хисап палатасы хезмәткәре булган Игнат университетка кабул ителгән бәхетлеләр исемлегенә эләгә. Ә аннан соң «Алабуга» махсус икътисадый зонасы идарәче компаниясеннән әлеге алдынгы команданың бер өлеше булырга тәкъдим килә. Игнатның яңа урында иң беренче тойгысы – ул нәкъ менә үзенә язылган җиргә: илен һәм республикасын яратучы, тормышыбызны яхшы якка үзгәртергә омтылучы, бернәрсәгә дә битараф калмаган кешеләр мохитенә эләккән бит! Кыскасы, хыялы тормышка аша, тик аны шунда ук башкасы алыштыра. Шул рәвешле Игнат «Россия лидерлары» Бөтенроссия конкурсында катнашырга ният кыла һәм, ил күләмендә 220 меңгә якын көндәшен узып, җиңү яулый. «Миңа калса, «Алабуга» бу җиңү өчен бик яхшы плацдарм булды, чөнки бирәдә заманча идарәче сыйфатларын һәм лидерлык компетенцияләрен үстерүгә аерым игътибар бирелә. Мин күп нәрсәгә өйрәндем!» – ди ул.

Туган елы – ***1994*** *ел*

БУ ЕЛДА – ТАТАРСТАНДА ҺӘМ ДӨНЬЯДА...

Россия белән Татарстан дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында Шартнамә, мөгаен, ил күләмендәге иң билгеле вакыйга булгандыр. Икътисадта исә уңай вакыйгалар аз күренә. «ГАЗ» конвейерыннан беренче «Газель»нең төшүе – күп булмаган казанышларның берсе. Хәтергә «кара сишәмбе» булып кереп калган 1994 елның 11 октябрендә долларның курсы 2833тән 3926 сумга кадәр артты. Июль ае ахырында МММ бөлде һәм финанс пирамидасында катнашкан миллионлаган кеше үз акчаларыннан колак какты. Шунысы кызык: МММның реклама роликларының төп герое Лёня Голубков, 1994 елда Ел кешесе булып танылды, рейтингта ул чакта илебез президенты булган Борис Ельцинны ун баллга узып китте.

Мәдәният кырында андый ук күңелсезлек күзәтелмәде. 1994 елның 27 маенда язучы Александр Солженицын, 20 ел дәвамында чит илдә яшәгәннән соң, кире Россиягә кайтты. Никита Михалков үзенең « Утомлённые солнцем» фильмын төшерде.

Ел ахырында яңа Россияне тагын бер җитди сынау көтә иде: Беренче чечен сугышы башланды.

ТАТАРСТАН ӨЧЕН НӘРСӘ ЭШЛӘГӘН:

Хәзер инде чып-чын алабугалы Игнат Петухов республикага башка төбәкләрдән талантлы кешеләрне эзләү һәм җәлеп итү белән шөгыльләнә. Күптән түгел «Алабуга» предприятиеләре штаты өметле кырык белгеч белән тулыланды: аларны Ростов-на-Донудан алып Новосибирскига кадәр югары уку йортларын яңа тәмамлаган биш мең кеше арасыннан сайлап алдылар. «Татарстанда планка югары куелган. Шуның белән бергә республика кеше капиталына акча да кертергә әзер, һәм бу инвестицияләр үзен унлата аклый!» – дип сөйли Петухов. «Алабуга» МИЗның үсеш стратегиясе нигезендә, 2023 елга Россиядә шундый ун мәйданчык корылачак. Аларны җитәкләргә сәләтле, заманча фикерле, нәтиҗәле идарәчеләр кирәк. Шуңа күрә өметле хезмәткәрләр эзләү дәвам итә! «Үземнең нәрсәгә омтылып эшләвемне аңлау минем өчен бик мөһим, ә мондый масштаблы максат илһам бирә һәм яңа казанышлар өчен көч-энергия өсти», – ди Игнат.

1973 2020

ГАСЫР ПОРТРЕТЛАРЫ. МӘГЪРИФӘТ КЕШЕСЕ



Фото: Александр Ефремов

Әбүбәкер хәзрәт (Газизов Дәүләт Атоевич) 46 яшь

Әбүбәкер хәзрәт – Чистайдагы «Әнәс» мәчете имамы. Бу – һәркемне колач җәеп каршы ала торган искиткеч матур мәчет. Ул Тубылгы авылының совет чорында танылган комбайнчысы, өч баласын ислам дине рухында тәрбияләп үстергән Әнәс Әхмәтҗанов исеме белән аталган. Әлеге мәчетне аның балалары төзеткән дә инде.

Мәчет эчендәге үзенә бер төрле җылы мохит, ә иң мөһиме, аның янәшәсендә яшәүче һәм бирегә кунакка килүче кешеләргә, нинди дин вәкиле булуларына карамастан, дустанә мөнәсәбәттә булган имамның барлыгы – бу фактор озын-озак үгет-нәсихәтләргә һәм исламга өндәүгә караганда күбрәк тәэсир итә. Әбүбәкер хәзрәт Газизов – тулы канлы тормыш белән яшәүче кеше. Тумышы белән таҗик булган имам – чын мәгърифәтче дә, шәһәр генә түгел, татар халкы тарихы буенча энциклопедик белемнәргә ия зат та.

Туган елы – 1973 ел

БУ ЕЛДА ТАТАРСТАНДА ҺӘМ ДӨНЬЯДА...

СССР Авторлык хокукларын саклау турында Женева конвенциясенә кушылды. Вьетнамда сугышны туктату һәм тынычлык урнаштыру турында Париж килешүенә кул куелды. Телеэфирга беренче тапкыр «Очевидное-невероятное» фәнни-популяр программасы чыкты. «Луна-21» совет планетара станциясе Ай өслегенә йомшак кына төшеп утыргач, «Луноход-2» Җирнең табигый иярчене буйлап сәяхәткә кузгалды. «Queen» төркеменең беренче альбомы чыкты. Байконур космодромыннан «Марс-5» совет планетара станциясе җибәрелде. «Язның унҗиде мизгеле» сериалы күрсәтелә башлады. Парижда Солженицынның «Архипелаг ГУЛАГ» романының беренче томы дөнья күрде. 1973 елда Советлар Союзында партия документларын алыштыру башланды.

Түбән Камада илнең ике зур автомобиль заводы – АЗЛК һәм ВАЗны тәэмин итәчәк икенче шин заводы төзелә башлады.

Казан циркы җирле әһәмияткә ия архитектура һәйкәлләре исемлегенә кертелде.

Гарифҗан Ахунов Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

Казанда Шаляпин укулары башланды.

ТАТАРСТАН ӨЧЕН НӘРСӘ ЭШЛӘНГӘН:

Әбүбәкер хәзрәт Татарстанга 1993 елда, Совет армиясе сафларында хезмәт иткәннән соң килә. Биредә ул татар әдәби телен үзләштерә, татар халкы тарихын өйрәнә һәм мәгърифәтчелек эше, иҗтимагый эшчәнлек белән шөгыльләнә башлый. Менә инде егерме ел Чистай халкына аң-белем тарата.

Мәчетләрендә китапханә, уку сыйныфы, видеотапшыру системасы, балалар мәйданчыгы, хәтта мини-футбол, волейбол, баскетбол һәм зур теннис уйнарга мөмкинлек биргән стадион да бар. Кул көрәше һәм шахмат буенча турнирлар, балалар өчен квестлар үткәрелә. Спорт мәйданчыгы мөселманнар өчен генә түгел, һәркемгә ачык. «Әнәс» мәчетенең футбол командасында руслар да, чуашлар да, башка милләт вәкилләре дә бар.

Әбүбәкер хәзрәт фикеренчә, мондый уртак чаралар кешеләргә бер-берсен яхшырак аңларга ярдәм итә, чөнки нинди дин тотуларына карамастан, аларга һәрвакыт тынычлыкта, үзара килешеп яшәргә кирәк. Шуңа күрә мәчет «Ел хәйриячесе» төбәк конкурсында җиңүче дип табыла да.

1920 ... 1959

ГАСЫР ПОРТРЕТЛАРЫ. ИКМӘК ПЕШЕРҮ ОСТАСЫ

ТАССР 100 ЕЛ



Осман Шаһин 60 яшь

Төркия инде күптән тормышыбызның аерылгысыз бер өлеше булып тора. Республикада бу ил вәкилләре – бизнес-партнерлар һәм көтелгән кунак кына түгел, күп кенә татарстанлылар өчен яхшы дус һәм хәтта туганнар да. Осман Шаһин Төркиянең Денизли шәһәрендә туган. Истанбулда укып, хәрби хезмәтен үткәч, туган ягына кайта һәм электр приборларын ремонтлау белән шөгыльләнгән үз фирмасын төзи. Ул вакытта аның абыйсы Сөләйман Шаһин Бөгелмәдә икмәк-күмәч ише нәрсәләр җитештерә башлый. Османга да төрки халыклар мәдәнияте кызык була һәм ул Төркиядән Казанга күчеп килергә карар кыла. 1996 елның язында монда абыйсы белән ипи пешерү йорты ачалар. Биредә ул Наилә ханым белән гомер юлын бәйләп җибәрә. Кызлары Хурия туа.

Туган елы – 1959 ел

БУ ЕЛДА ТАТАРСТАНДА ҺӘМ ДӨНЬЯДА...

Яңа 1959 елның беренче көнендә Фидель Кастро Куба президенты Батистаны бәреп төшерде. Бер көннән соң СССРда беренче «Луна-1» автоматлашкан планетаара станциясе космоска җибәрелде, ул Айга барып ирешкән тәүге галәм аппараты булды.

Март аенда Нью-Йоркта узган уенчыклар ярминкәсендә Барби исемле, киләчәктә миллионлаган кызларның яраткан уенчыгы булачак яңа курчак тәкъдир ителде.

СССР экраннарына Василий Ординскийның «Яшьтәш кызлар» фильмы чыкты, андагы кечкенә эпизодта беренче тапкыр Владимир Высоцкий күренде. Мәскәүдә ВДНХ ачылды.

Мәскәүдә узган Америка күргәзмәсендә АКШ ның вице-президенты Ричард Никсон капиталистик хуҗалык казанышларын күрсәтте, Никита Хрущев СССРның АКШын тиздән куып җитәчәген һәм тормыш дәрәҗәсе буенча узып китәчәген һәм, гомумән, «күрмәгәннәрен күрсәтәчәген» белдерде. Сүзгә сүз тәрҗемә ителгән бу гыйбарә америкалыларны аптырашка калдырды. Икенче тапкырында генсек үзенең атаклы янавын шул ук 1959 елда, АКШна баргач кабатлый. Аның шәхси тәрҗемәчесе соңыннан болай дип искә ала: «Без Лос-Анджелес буйлап бара идек, Никита Сергеевич тирә-юньдәге тук тормышны озак күзәтте, ә аннары кинәт янә Кузьманы һәм аның әнисен искә төшерде. Яңадан тәрҗемә белән бәйле тоткарлык килеп чыкты, әмма шунда Хрущев үзе ярдәмгә килде: «Нәрсә соң сез, тәрҗемәчеләр, изаланасыз? Без Америкага әле ул беркайчан да күрмәгәнне күрсәтербез дип кенә әйтергә телим!»

АКШнда кибетләргә яңа товар – хатын-кызлар өчен капрон колготкилар сатуга чыкты. СССР исә моңа каршы зур күләмле проектлар белән җавап бирде: «Ленин» совет атом бозваткычы үзенең беренче сәфәренә кузгала. «Луна-3» космик аппараты галәмгә җибәрелә, ул беренче тапкыр Айның караңгы тарафын фотога төшерә. Стратегик максатлардагы ракета гаскәрләре оештырыла».

1959 елның 3 ноябрендә Казанның Шамил Усманов урамындагы яңа студиядән Татарстанда телетапшырулар башланды.

Республиканың социаль өлкәсендә дә уңай үзгәрешләр булды. Колачлы торак төзелеше җәелеп китте. 1959 елда башланган җидееллык кысаларында Татарстанда 4 миллион квадрат метр торак төзелә, 80 мең фатир газлаштырыла, 270 километр суүткәргеч һәм 125 километр канализация челтәрләре салына. Кыскасы, бу «совет кешеләренең тыныч иҗади хезмәте чоры» булды.

ТАТАРСТАН ӨЧЕН НӘРСӘ ЭШЛӘГӘН:

Иң талантлы кондитерлар гына Шәрык тәм-томнарын солтан табыннарына куярлык итеп әзерли ала, диләр. Төркиягә бер тапкыр булса да кунакка барган һәр кешегә таныш пәхләвә, лукум, ләвәш һәм икмәкләрнең асыл тәмен табу өчен, Осман төрек осталары тәҗрибәсен бөртекләп җыя.

Осман үз эше белән генә чикләнеп яшәми. Татарстанлылар һәм Төркия халкы арасында элемтәләрне ныгытып, ул Казан һәм республиканың мәдәни тормышында актив катнаша. Төркиянең Ататөрекне искә алу, яшьләр һәм спорт көне уңаеннан 20 майда Казанда узган концертка иганәчелек ярдәме күрсәтә.

Ел саен Нәүрүз бәйрәмендә казанлылар һәм башкала кунаклары Төркия тәм-томнарын татып карый һәм бәяли дә ала. Төрле мәдәният кешеләрен уртак икмәк телеменнән дә яхшырак итеп тагын нәрсә шулай якынайтырга һәм үзара мөнәсәбәтләрне ныгытырга сәләтле? Чөнки борынгы гадәт буенча, бер йортта икмәкне бүлешеп авыз иткәннәр гомергә дус булып кала ул.

Фото: Александр Ефремов

ГАСЫР ПОРТРЕТЛАРЫ. ҖИҢҮЧЕ ОСТАЗ

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ

Араик Маргарян 68 яшь

Ул үз эшенә бар күңелен салып эшли. Чирәмдәге хоккей буенча «Динамо-Казан» командасының баш тренеры Араик Арташович Маргарян Россия чемпионатының алтын медальләрен гадел һәм кискен көрәштә 16 тапкыр яулады. Бүген ул – чирәмдәге хоккей буенча тренерларыбызның илкүләм аренада гына түгел, ә халыкара спорт җәмәгатьчелеге өчен дә иң хөрмәтле һәм мактаулыларыннан берсе. Аның командасы яулаган бүләкләр арасында 2007 елгы «Трофи кубогы», 2013 елгы Бөтендөнья җәйге Универсиадасының алтын медале бар .

«Динамо-Казан» клубында эшләгән дәвердә Россиянең атказанган тренеры клуб һәм милли җыелма команда өчен берничә буын чемпионнар әзерли. Маргарян хоккейчылары – республикабыз флагы астында чыгыш ясаучы профессионаллар бренды булып тора.

Туган елы – *1951 ел*

БУ ЕЛДА ТАТАРСТАНДА ҺӘМ ДӨНЬЯДА...

1951 ел дөньяда да, СССРда да, Татарстанда да вакыйгаларга бай булды.

Беренче совет ЭВМы – кече электрон-исәп машинасы даими файдалануга тапшырылды. Ул Украина СССР Фәннәр Академиясенең электротехника институтындагы Сергей Лебедев лабораториясендә эшләнә.

Көнчыгыш Берлин өченче Бөтендөнья яшьләр һәм студентлар фестивале кунакларын кабул итте. Май аенда биредә «Тынычлык һәм дуслык өчен – атомтөш коралына каршы» шигаре астында коммунистик карашларга тугры егетләр һәм кызларның гаять зур очрашуы узды.

Нью-Йоркта рәсми рәвештә БМО штаб-фатиры бинасы ачылды.

СССРда телевидениенең Үзәк студиясе төзелде – киләчәктә ул Беренче каналның нигезенә әйләнәчәк.

Казанда тантаналы рәвештә Пионерлар сарае ачылды. Казан ЭВМ заводының тарих сәхифәләре языла башлады – СССР Министрлар Советы завод төзү турында карар кабул итте.

Казан Кремленең Спас манарасы янындагы 1 Май мәйданында Ленин һәйкәле Сталин монументы белән алыштырылды. Дөнья пролетариаты юлбашчысы ул вакытта Ирек мәйданына күчерелде һәм шул вакытта төзелеп килгән опера театры каршында урнаштырылды.

СССРдагы тугандаш республикаларның социаль-икътисади үсешендә нефть чыгару аерым роль уйный. 1951–1955 елларда Татарстанның нефть тармагына 5 миллиард сум акча кертелә. Нефть чыгару күләме 21 тапкыр арта. Алдагы елларда да нефть чыгару югары темплар белән үсүен дәвам итә.

Элек «Саратовнефтегаз» берләшмәсе составына кергән бораулау кадрларын әзерләү мәктәбе «Татнефть» карамагына тапшырылды.

ТАТАРСТАН ӨЧЕН НӘРСӘ ЭШЛӘГӘН:

Араик Маргарян республиканың халыкара абруен ныгытуга, Казанны Россиянең спорт башкаласы буларак популярлаштыруга зур өлеш кертте, хәзер дә актив иҗтимагый эшчәнлек алып бара. Әрмәнстан Республикасының Раздан шәһәрендә туган остаз күпмилләтле республикада дуслыкны саклау һәм ныгыту үрнәге булып тора. Ул үзен Татарстанның, ягъни профессиональ тренерлык карьерасының иң яхшы еллары узган республиканың, чын патриоты дип саный. Маргарян бөек тарихи-дини мәдәниятка ия халыкларның күп еллар тынычлыкта һәм татулыкта янәшә яшәү үрнәге буларак еш кына нәкъ менә Татарстанны атый. Спорт белгече фикеренчә, көндәлек тормышның һәр өлкәсендә чагылыш тапкан белем-мәгърифәт кыйммәтләренең синтезы, нинди милләт һәм дин тотуларына карамастан, Татарстан халкына һәм аның кунакларына хас толерантлык республиканы планетада тиңдәшсез урынга әверелдерә.



Автор:
Ольга Туманская

ПЕЧИЩИГА, ЯНКА КУПАЛА ЯНЫНА…

«Хәтер өчен рәхмәт!» – Александр Лукашенко Янка Купала музеен карагач, әнә шундый култамга калдыра. 2005 елда Белоруссия Президенты Казанга БДБ илләре саммитына килгән иде. «Бу бит Татарстан җирендә белорус мәдәнияте почмагы!» – дип сокланды һәм гаҗәпләнде ул, чара уңаеннан Печищидан китерелгән күргәзмәне тамаша кылып йөргәндә.

Янка Купала. 1916 г.



– Добро пожаловать! Рәхим итегез! Калі ласка! – дип, өч мәдәният телендә сәламли безне Янка Купаланың илдәге бердәнбер, дөньядагы икенче мемориаль комплексы директоры Римма Абызова. Беренчесе – Минск янында аның туган хуторы Вязынкада, сугыш вакытында могҗиза белән генә хәрабәгә әйләнми калган. Икенчесе – бирердә, Татарстанның Югары Ослан районында.

Экспозиция XIX гасырда тегермән янәшәсендә төзелгән иске бинада урнашкан. Янка Купала 1941 елның 13 ноябрендә эвакуацияләнеп безнең якларга килгәч, нәкъ шушында яшәгән.

…Менә шагыйрьнең эш кабинеты. Карават, этажерка, абажур – барысы да шул чордан калган. Шәхси әйберләре – аларын күп еллар узгач, йортның чарлагыннан, чормасыннан табып алганнар. Кульязмалар һәм китаплар, тәмәке төрепкәсе һәм махорка тәмәкесе янчыгы, кул таягы һәм ак яка… Диварда – репродуктор. Печищида ул елны алар икәү генә була: берсе – авыл советында, икенчесе – шагыйрь карамагында. Көн саен, кышкы көннәрдән кала, Купала аны тәрәзәдән чыгарып куя торган була. Барысы да фронт хәбәрләрен һәм музыкаль тапшырулар тыңлый алсын өчен, билгеле.

ТУУЫ ДА ТАБЫШМАК

Ясь үзе – морзалар нәселеннән, шляхтичлардан, әкиятләр һәм ырымнар тыңлап үскән, жалейка һәм балалайкада уйнаган, көтү көткән, чыра яктысында укырга өйрәнгән… Янка Купаланың бөтен балачагы халыкның көнкүрешен чагылдыра. Кечкенә генә экспозиция аның тормышының төрле еллары турында сөйли. Анда – Минскиның милли мәдәниятләр үзәге бүләк иткән белорус киемнәре, баш киемнәре, тәкыялар, чуен һәм муенлы чүлмәкләр һәм, әлбәттә, саламнан эшләгән нәзакәтле әйберләр! Чынлап та шулай – Татарстан җирендәге Белоруссия почмагы бу.

Сүз уңаеннан, Купала тәхәллүсен шагыйрь юктан гына алмаган. Иван Купаланың серле дә, бәйрәмчә дә, иске календарь буенча 1882 елның 24 июненнән 25енә каршы төнендә Иван Луцевич туган. Һәм, беренче шигырен язып, аны «Төньяк-көнбатыш төбәге» газетасына илтергә тәвәккәлләгәндә, ул «Янка Купала» дигән имза куя. «Что я мужик, да все тут знают, Повсюду, белый свет велик, Смеются, паны, презирают, – Ведь я мужик, простой мужик…» – Ходай хикмәте белән нәкъ менә шушы беренче юлларын Максим Горькийга укырга насыйп була. Илһамланып, рус теленә генә тәрҗемә итеп калмый, авторга киңәш тә бирә – тагын язарга куша. Горький ялгышмый. Купаланы белорусларның Пушкины дип йөртә башлыйлар, аның шигырьләре 117 телгә тәрҗемә ителә, пьесаларын бик күп театрларда куялар, ә җырлары совет ансамбльләре репертуарында да, яңа рокерлар композицияләрендә дә яшәячәк әле.

Луцевичның тормыш юлында бик күп очраклы хәлләр, табышмаклы мизгелләр дә булачак – ул аларны үзенең сихри туган көне белән бәйләп караячак. Печищидагы музеенда да бу турыда онытмыйлар – Иван Купала төнен бирердә сихри итеп үткәрә беләләр.

Фото: Александр Ефремов

ТӘРӘЗӘСЕ ИДЕЛГӘ КАРЫЙ ТОРГАН БҮЛМӘ

1941 елның 11 ноябрендә Казанга каршы Идел ярында машиналардан озын чират тезелә. Ул яңгырлы көнне переправага эләгергә теләүчеләр күп була. Тикшерү үткәрүче хәрби комендант Григорьевның игътибарын «Шевроле» җиңел машинасы җәлеп итә. Килә, документларын күрсәтүләрен сорый. Таныш түгел кеше Белоруссия ССР Югары Советы депутаты Иван Доменикович Луцевич исеменә таныклык суза. «Бу бит Янка Купала!» – дип кычкырып җибәрә тегесе.

Григорьев ипи комбинаты директоры Иван Наякшинга чиратта бөтен илгә билгеле шагыйрь торуы турында хәбәр итеп өлгерә. Наякшинның аның белән шәхсән күрешеп танышасы килә. Идел ярына чыга, әмма Купаланы машинасында очрата алмый – тегесе Печищиның танылган геологик киселешенә чыгып басып, елгага сокланып тора икән. Шагыйрьне үзенә чәйгә чакыра. Гаҗәеп тәмле төнәтмә һәм Печищида тарттырылган оннан пешерелгән телне йотарлык тәмле алма пәрәмәчләре белән сыйлый ул аны. «Бәлки, бездә калырсыз? Күршедәге фатир буш тора – баш инженер фронтка китте», – дип тәкъдим итә Наякшин кунакка. Луцевичка Казанга килергә диелгән була. Паромга чиратсыз керү мөмкинлегеннән баш тарта ул.

Белорусның Печищидагы тарихы моның белән генә бетми. Наякшинның тәкъдиме барысының да күңеленә хуш килә – Казанда тору урыны табу авыррак вакыт була. Шулай итеп, Янка Купала хатыны Владислава Францевна Луцевич белән тегермән янындагы иске йортка урнаша.

Купала төннәрен яза торган була, әмма иртә тора. Иртәнге алтыда комбинатка эшчеләр килә. Алар янына төшә, үзе төреп ясый торган тәмәке белән бүлешә. Утыралар, тарталар, һәртөрле бәяннәр тыңлыйлар... Көндез исә хезмәттәшләре янына Казанга китә – кайчак паромда, кайчак елга аша чаңгыда гына. Владислава Францевна да тик тормый – мәктәптә җиң сызганып хезмәт куя. Чын мөгаллимә була ул, Печищида үзенә фикердәшләр, дуслар, ахирәтләр таба. Эше күп булу сәбәпле, Язучылар берлеге чакыруы буенча ире белән Мәскәүгә дә бара алмый. Нибары беренчә көн, югыйсә, ә юл – катлаулы. Ә шагыйрь өчен әлеге сәфәр соңгысы була.

«Владка, «Москва» кунакханәсенә урнаштым, 414 нче номерда», – дип яза Купала аннан. Башкаладан килгән икенче хәбәр фаҗигале була. Аны кунакханәнең баскычында үле килеш табып алалар. Әлеге үлем табышмак булып кала. Фаразлар күп. Рәсми документ әлегә кадәр сер итеп саклана.

«Москва» кунакханәсе юк инде. Баскыч култыксалары, «ул мәңгелеккә китеп барган» 414 нче номерның ишеге шагыйрьнең Минскидагы музеенда саклана. Анда Печищидагы тормышыннан да фрагмент бар. Сүз уңаеннан, «Шевроле» машинасы бездә 1948 елга кадәр кала. Аннан соң аны Мәскәүгә алып китәләр, 2012 елда гына – Белоруссиягә. Хәзер ул шагыйрьнең Левкидагы дачасында.

Владислава Францевна моннан тиз генә китми әле. Минскига кайту белән ул – шагыйрьнең җан дусты гына түгел, ә беренче әдәби тәнкыйтьчесе дә – киләчәктә булачак музей өчен экспозиция җыя башлый. Печищины да онытмый – бу урын кадерле була аңа. «Туган яктан еракта булуыбызга карамастан, без монда үзенчә бәхетле идек. Биредә безнең соңгы яшәү урыныбыз», – дип яза Владислава Францевна.

Авыл мәктәбендәге ахирәт дуслары янына ул биш ел саен кайтып тора. Нәкъ менә ул биредә музей булдырырга тәкъдим итә, һәм бу фикер, еллар узгач булса да, гамәлгә ашырыла. Бүгенге көндә ике музей да тыгыз элемтәдә яши, хезмәттәшлек итә. Белоруслар ерак Татарстандагы Печищида аларның кумиры турында хәтер саклануы белән горурлана.

Ак каеннар арасында аклы-каралы сыерлар, аклы-каралы песиләр йөри.

ТҮБӘН УРӘС: РӘХИМ ИТЕГЕЗ яки ГАЖАСА ӦТИСЬКОМ*!

Россия көнен «Татарстан» Россиянең ерак бер авылында билгеләп үтәргә булды. Татарстан читендәге Түбән Урәс исемле авылга юнәлдек.

Автор:
Татьяна Вафина

Карта безгә шундый саф рус атамалы (русчасы – Нижняя Русь – авт.) авылның Кукмара районында урнашуын хәбәр итте. Һәм менә инде килеп тә җиттек. Безне исерткеч сирень исе һәм шул чәчкәләргә күмелгән өр-яңа мәктәп бинасы каршы алды. Шунда юнәләбез дә. «Добро пожаловать!» – дип сәламли безне мәктәп һәм татарча «Рәхим итегез!», удмуртча «Гажаса отиськом!» дип тә өсти. Менә нинди икән ул Түбән Урәс!

ПОЛИГЛОТЛАР АВЫЛЫ

– Безнең удмуртлар өчәр тел белә, – дип аңлатты безгә авыл советында секретарь Ольга Васильевна Петухова. – Удмурт, татар һәм рус телләрен. Безнең бит монда яртылаш татар, яртылаш удмурт авылы, – дип таныштыруын дәвам итә ул, эш буенча шалтыратучыларга әледән-әле телефоннан йә татарча бик өлгер, йә удмуртча көйләп җавап бирә-бирә.

– Ә татарлар?

– Ә татарлар русча һәм удмуртча белә. – Удмуртча барысы да сөйләшми.

– Ә руслар?

– Руслар бездә икәү генә: бер укытучы һәм удмуртка кияүгә чыгып безнең авылга килгән тагын бер ханым. Укытучы әле икеел гына эшли, килен булып төшкәне исә удмуртча сукалый инде.

– Полиглотлар авылы икән бу! – дип сокланабыз, чөнки үзебезнең, оят булса да, шул кадәр телдә сөйләшергә хәлебездән килми.

– Безнең Ольга бөтен нәрсәне белә! – дип елмая Түбән Урәс авылы җирлеге башлыгы Ринат Шәмиев. – Венера апа янына алып бар син аларны, – дип фәрман бирә үзе. – Ул авылыбыз турында бөтен нәрсәне сөйләп бирер. Яки Рүзәлә апага барыгыз, ул 1936 елгы, авылның иң карт кешесе.

ТАТАРЛАР ВЕРСИЯСЕ

Без күрсәтелгән адреслар буенча барабыз, тик Рүзәлә апа гына өйдә булып чыкты.

– Нигә минем яныма татар хәбәрчесен җибәрмәделәр? – дип хафалана әби. – Мин бит русча сөйли белмим, татарча гына сөйлим…

– Үзем тәрҗемә итәрмен, – дип тынычландыра аны удмурт кызы Ольга Петухова. Һәм иң оста тылмачтай тәрҗемә дә итә. – Иң башта бирегә удмуртлар гаиләсе килеп урнашкан, аннары татарлар килгән. Авыл нигә шулай аталамы – чөнки биредәге елга татарча Түбән Урыс дип аталган, шуннан авыл исеменә дә әйләнгән.

УДМУРТ НЕЧКӘЛЕКЛӘРЕ

Авыл тарихының удмуртларга кагылышлы нечкәлекләрен ачыклар өчен без элекке тарих укытучысы һәм җирле мәктәп директоры Виталий Николаевич Егоров янына юнәләбез. Әмма керергә куркып торабыз, чөнки капкага «Сак булыгыз! Усал эт!» дигән табличка кадакланган. Яшелчә бакчасы ягыннан керергә булдык, шундагы түтәлләр арасында очраттык та үзен.

– Кайчандыр мин әйләнәтирәдәге авыллар тарихы буенча мәҗмуга да бастырган идем, – дип сөендерде безне Виталий Николаевич. – Хәзер эзләп карыйм.

Тапты да. Ачты. Мәктәптә эшләгәндә, бу китапчыкны ничек язуын исенә төшерде…

– Сез аны озак тоткарламагыз. Бакчада да эшлисе бар бит! – дип кисәтә безне Виталий Николаевичның хатыны.

– Усалмыни? – дип куркып калдык без.

Фото: Александр Гайнутдинов

* Гажаса ӧтиськом! – Рәхим итегез! (Удмурт теленнән тәрҗемә).

– Безнең удмуртлар өчәр тел белә, – дип аңлатты безгә Ольга Петухова.

– Безнең Ольга бөтен нәрсәне белә! – дип елмая Түбән Урәс авылы җирлеге башлыгы Ринат Шәмиев.



– Нигә минем яныма татар хәбәрчесен җибәрмәгәннәр? – дип хафаланды Рүзәлә апа.


– Мин авылның удмурт өлеше өчен генә җаваплы, – дип көлә Виталий Егоров.

– Ул да элекке укытучы, – дип елмая Ольга.

Виталий Николаевич исә рәхәтләнеп китапчыгын актара башлады, безгә өзекләр укып күрсәтте, аларны үзенең хатирәләре белән баета барды һәм «Барысын да тикшерергә кирәк, чөнки соңгы елларда күп нәрсә ачыкланган булырга тиеш», дип кисәтергә дә онытмады.

МӘҖҮСИЛЕК БАЛБАЛЛАРЫ ҺӘМ КАРА ТАТАР

– «Борынгылар әйтүенчә, Түбән Урәс авылы иске тегермән урынында барлыкка килгән. Анда мәҗүсиләр яшәгән. Билгесез сәбәпләр буенча, алар бу урынны ташлап киткән...» – дип укый ул һәм, күзләрен кыса төшеп, хәтерен яңарта: – Мин әле кечкенә идем, тик исемдә: абзарлар артында сыннар тора һәм без, балаларга, алар янына бару тыела иде. Куркыныч урын санала иде. Анда гыйбадәт кылганнар һәм корбан чалганнар... Йә, аннары ни дип язганмын икән? – Һәм ул тагын укуга чума: – «Аннары бу урынга бер удмурт гаиләсе килеп төпләнә. Бу моннан якынча 350–340 ел элек була. Төп шөгыльләре – игенчелек. Удмуртның Мәрсәлим һәм Мәслим исемле ике улы була – берсе бик көчле һәм таза, икенчесе – бик ябык һәм чирләшкә. Петр I заманында сәламәт улларын 25 елга солдатка алырга тиеш булалар». – Элек шуның кадәр хезмәт иткәннәр, – дип шәрехли укыганын Виталий Николаевич. – «Армиягә бармас өчен, ул христиан диненә күчә. Менә шуннан Түбән Урәс авылы башлана да инде. Авылның яртысы халкы христиан динендә, яртысы мәҗүси була». Баштарак авылны елга атамасы белән Урыс Очы (Уряс Учи) дип атаганнар. Хәзер бу инешне ни өчендер Ушманга әйләндерделәр... Тик сез барысын да ачыклагыз! – ди ул. – Бу бит риваять кенә.

– Ә татарлар Түбән Урәскә каян килеп эләккән?

– Татарлар турында Венера ападан сорагыз, моның белән ул шөгыльләнде. Мин исә удмурт өлеше өчен генә җаваплы, – дип көлә Виталий Николаевич. – Әмма менә нәрсә ишеткәнем бар: саф удмурт авылына кара татар килеп төпләнгән. Гаилә корган. Түбән Урәс халкының татар өлеше шул кара татардан үрчегән.

ПӘРӘПӘЧМЕ, ПӘРӘМӘЧМЕ?

Без элекке мәктәп директоры белән сөйләшкән арада, безнең десант турында хәбәр бөтен авылга таралган. Юлда барганда Ольгага әле рус, әле удмурт телендә тәкъдимнәр яуды: мәктәп музеена барыгыз, Хариска шалтыратыгыз, Венера ападан сорагыз...

Ольга барысына да елмая, рәхмәт әйтә һәм биредә барысының да ничек тату яшәве турында сөйли:

– Пасхада удмуртлар йомырка буйый, татарларны сыйлый. Татарлар бәлеш пешерә, безне сыйлый. Без пәрәпәч пешерәбез... Әллә пәрәмәчме? Мин буталып беттем инде. Кайсы татарча, кайсы удмуртча, тәгаен генә белмим дә... Әй, ярар! Гөмбәле яки бәрәңгеле шаңгә ул. Бик тәмле!

НИЧЕК БАРЫП ҖИТӘРГӘ:

Түбән Урәскә кадәр юл шактый ерак – Казаннан көнчыгышка таба 115 километр, Кукмарадан көньякка таба 20 чакрым. Нократ аланы аша да барып җитеп була – 24 км

НИЧЕК БУТАЛМАСКА:

Элегрәк Түбән Урәстә татарлар күбрәк яшәгән, диләр. Аннары удмуртлар күбәйгән. Аннары тагын беренчеләре арткан, икенчеләре кимегән. Һәм хәзергә кадәр шулай. Тулаем алганда, катнаш халык яши биредә, Казан губернасы вакытында «Ревизские сказки и переписные книги Вятского края» 1744–1748 елларда аларны «дәүләт ясаклы вотяклары» дип атаган. Ничек телисез, шулай аңлагыз инде шуннан.

НӘРСӘ БЕЛӘН ХОЗУРЛАНЫРГА:

Түбән Урәс – бик матур авыл: үзәк урамнан үтсәң дә, кырыйларыннан урасаң да! Таулар, инеш, болыннар, тугайлар... Ак каеннар арасында аклы-каралы сыерлар, аклы-каралы песиләр йөри: аларның токымы шундый – Түбән Урәснеке.

PRESSA

Күренекле бакчачы, язучы, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, ТРның атказанган фән эшлеклесе, икътисад фәннәре докторы Фарсил Зыятдиновта кунакта.

ТАБИГАТЬ КОЧАГЫНДА ҖИЛӘКЛЕ СЫЙ

Июнь җәйнең иң матур аедыр. Табигатьне каплаган яшеллек кояшта кибәргә, саргаерга өлгермәгән, аллы-гөлле чәчәкләр турында әйткән дә юк. Ә сандугачлар... Быел алар аеруча матур сайрый кебек. Бу юлы без аш-су рубрикасын да могҗизалы итәргә уйладык. Ризыкларны табигатьтә әзерләдек. Ә аш-су остасы итеп атаклы бакчачы Фарсил ага Зыятдиновны чакырдык. Ул безгә берьюлы ике ризык әзерләде.

Автор:
Руфия Фазылова

«ҮЗЕМ ТӨЗЕДЕМ»

Фарсил абыйның дачасына кергәндә иң беренче шуңа игътибар иттем: капкага чия агачы терәлеп үк үскән. Аның ботаклары нәкъ баш очына туры килә. Күз алдына китерегез: капканы эчке яктан ачасың һәм чия ботаклары арасыннан урамга карыйсың.

Тәҗрибәле бакчачы безне тормыш иптәше Венера апа белән каршы алды. Җылы итеп, күптән күргән танышлар кебек күрештек.

– Фотога төшәсе була дигәч, Фарсилга ак күлмәк бирдем, ярыймы, – дип, Венера апа безнең белән киңәшләшеп алды. Ак күлмәгенә төс итеп, тормыш иптәшенә баш киеме сайлый башлады.

– Егетләр итте үземне, – дип, Фарсил абый да канәгать кенә елмайды.

Шуннан барыбыз бергә «экскурсиягә» – бакча белән танышырга чыктык. Хуҗа буларак, Фарсил абый «дилбегәне» үз кулына алды:

– Әлеге бакчачылык ширкәтен 1979 елда үзем оештырдым, – диде ул. – Министрлар Советыннан җиргә рөхсәт алып, кишәрлекләрне бүлеп, кешеләргә тараттым. Барлык мәйдан – 11 гектар. Шул җирләрне тимер челтәр белән әйләндереп алдык, су үткәрдек, 60 тонналы цистерналар алып кайтып, күтәртеп куйдык. Бакчачылык ширкәтен шулай җанландырдык. Идел елгасы буенда булганга, «Идел» дип атадык. Башта шактый еллар монда рәислек тә иттем. Хәер, хәзер дә барысын инә күзеннән үткәреп торам әле. Монда мине барысы да белә, киңәш-табышка да киләләр.

Фарсил абыйның бакчасы үзенчәлекле. Без иялэнгәнчә, бередә бербер артлы түтәлләр тезелмәгән. Чәчәкләр арасында суганы да, бәрәңгесе дә бар. Уч төбе кадәрле җирдә – кишер, арттарак дару үләннәре, агачлар, куаклар...

– Фарсил абый, сез бала вакытта бакчада яшелчә, җиләк-җимеш үсмәгәндер. Бу юнәлешкә ничек кереп киттегез? – дим.

– Безнең авыл янында таллар, кыргый җимеш агачлары үсә торган болын бар иде. Бала чакта шуннан карлыган төпләп алып кайтып утыртып карадым. Ул үсеп киткәч, яшелчә үстерәсе килә башлады. Орлыкларны җиргә төртеп куясың да, ул шытып чыга – карап торуы кызык бит. Минзәлә районындагы бер рус авылыннан безгә тозлаган кыяр, помидор алып килеп саталар иде. Шуны авыл халкы чират торып алды. «Ә нишләп үзебез үстермибез?» – дип, аптырый идем. Шуннан, тынгысызланып, яшелчә үстерә башладым.

ФАРСИЛ ЗЫЯТДИНОВТАН ҖИЛӘКЛЕ ДЕСЕРТ РЕЦЕПТЫ:

Кирәк булачак (4 порция өчен):

1. Ике кап куе, натураль йогурт яки эремчек
2. Бер банка куертылган сөт
3. Виктория җиләге – 1 стакан
4. Печенье – 100 г

Фото: Александр Ефремов

1. Ваклыйбыз!

2. Салабыз!

3. Алабыз!

4. Кушабыз!

5. Агызыбыз!

6. Турыйбыз!

7. Төшерәбез!

8. Кыздырабыз!

9. Салабыз!

10. Бизибез!

«БӘЙРӘМ БУЛСЫН ӘЛЕ!»

Үзенчәлекле әлеге бакчада бердәнбер өлгергән җиләк-җимеш – бакча җиләге. Фарсил абый белән Венера апа ел да бу вакытта кыяр ашасалар, быел андый бәхет тәтемәгән. Иделдә су саекканга күрә, дачада суны 1нче июньдә генә биргәннәр.

– Җиләкләрне гадәттә кышка туңдырабыз гына, – диде Венера апа. – Алай витамины да саклана, мәшәкате дә аз.

Фарсил абый Виктория җиләгеннән десерт әзерләргә булды.

– Җиләкне бөтен кеше катыра белә хәзер. Гел сөйли-сөйли, халыкны бу җиңел ысулга ияләндереп бетердем, – диде.

– Ә бу җиләкле десертны еш әзерлисезме? – дим.

– Юк, беренче тапкыр. Рецептын фәкать сезнең өчен дип эзләп таптым. Тәмле килеп чыгар, дип өметләнәм. Венера апагыз шашлык та ясап куйды, анысын да пешерербез. Бәйрәм булсын әле!

Кулларын янә бер кат юып, Фарсил абый эшкә тотынды. Башта ул печеньены куна тактасына куеп төйде. Аннан шул валчыкларны стакан төбенә салды. Һәм бер савытка куертылган сөт белән эремчек салып, яхшылап бутады. Шуннан соң, әлеге массаны кашык белән печенье валчыгы өстенә төшерде.

– Ярты эш бетте, – диде Фарсил абый. – Хәзер берничә җиләкне турап, шикәр комы белән бутап, ике-өч минут табада пешереп алам да – була.

Җиләкләрне түгәрәкләп кисеп табага салганнан соң, өйгә кердек. Хуҗа кеше газны кабызып, табага шикәр комы өстәде дә газга куйды.

– Җиләкләрегез тигез пешкән, баллы да. Сорты нинди? – дим.

– Безнең бакчада ике төрле җиләк үсә – «Фестивальная», «Зенга Зенгана». Болар икесе дә иске сорт санала, Советлар чорыннан ук килгән. Бакча җиләгенең төрле сортларын утыртып карадым, шуларыннан да отышлысын тапмадым. Һәр төр җиләк-җимешне, агач, куакларны утыртканда, иң беренче аның безнең климатка яраклашуын карарга кирәк. Мисал өчен, соңгы елларда Краснодар краеннан алмагач, груша агачлары алып килеп саталар. Ә алар үсеп китә алмый, чөнки кышны исән-имин чыкмыйлар. Аның сәбәбе бик гади – безнең климат өчен түгел ул.

– Алайса алмагачларны каян сатып алырга?

– Бары тик махсус питомниктан алырга кирәк. Нигездә, алар үзләрендә үскән, ялганган, ягъни безнең шартларга яраклашкан үсентеләрне саталар.

Ул арада табадагы җиләкләр пешеп, кызыл кайнатмага әйләнде. Фарсил абый аны бакчага алып чыгып, өстәлдә торган стаканнарга салды.

– Булды бу, – дип куйды. – Хәзер берничә җиләкне кисеп десертыбызны матурлап куябыз...

– Моның кадәр тиз бер ризык та әзерләгән дә юк иде әле, – дим.

– Ә мин бит махсус бакча шартларында тиз әзерләнә торган ризык сайладым.

Фарсил абый десертны җиләкләр белән бизәде. Һич арттыру түгел, сәнгать әсәре килеп чыкты.

– Тәмен соңрак белербез, – дип, хуҗа десертны суыткычка алып куйды.

«МАКСАТЫМА ИРЕШТЕМ!»

Әле бит шашлык пешерәсе бар. Фарсил абый күмерне ягып җибәрде. Күреп торам: бу эшне Венера апа җитәкли. Шашлык пешерә торган сеткага тавык итен матурлап тезде.

– Итне ике көн элек ясап куйган идем, – диде хуҗабикә. – Бер-ике көн торган шашлык тәмлерәк, сусылрак була.

– Бу өлкәдә сезнең тәҗрибә зур ахрысы? – дим.

– Зур дип... Дачада булганда еш әзерлибез. Үзебезгә генә түгел, әлбәттә. Балалар яки берәр кунак килгәндә инде.

– Фарсил абый кыздырамы?

– Килгән кеше үзе кыздырып ашата. (Көлә.)

Фарсил абый башка төрлерәк уйлый булса кирәк, Венера ападан итне алып, учакка алып китте. Янәсе, менә хәзер пешереп күрсәтәм!

Әлеге сөйкемле ханым белән атаклы бакчачыны язмыш шактый сынаган. Бу икесенең дә икенче никахлары. Тормыш иптәшләрен югалтканнан соң, картлык көннәрендә шулай кавышкан алар.

– Фарсил хатынын җирләгәч, бик төшенкелеккә бирелгән иде, – диде Венера апа. – Дөресен әйтим, кызгандым мин аны. Өстәвенә, армиядә имгәнеп кайтып, акылына зыян килгән улы Айваз да бар. Аны ашатырга, карарга кирәк дигәндәй. Ә Фарсил ул вакытта өч җирдә эшли. «Әйдә, никах укытып, бергә яшик инде», – дигәч, каршы килмәдем.

Шунысы кызык: алар яшь вакытта ук танышалар. Ләкин төрле сәбәпләр аркасында очрашып яшәргә насыйп булмаган.

Сүзне читкәрәк борып, Фарсил абый белән бакчачылык турында сөйләшә башладык. Мине бер нәрсә гаҗәпләндерде: теге яки бу яшелчә, җиләк-җимеш турында сөйләшә башласаң, һәркайсының исемен атый. Төрле ашлама, бөҗәкләргә каршы агуларның да исемнәрен белә. Атаклы бакчачының бер фикере кызык тоелды:

– Элек кешенең бакчасы юк иде, бәрәңге бакчасы саналмый, – диде ул. – Моннан 50 еллар элек, татар зиратларына кереп, безнең халык күпме яши икән дип, махсус карап чыктым. Якынча 47–50 ел яшәгәннәр. Татарлар витамин җитмәүдән, яшелчә, җиләк-җимеш ашамаудан, камыр ризыгы белән бәрәңге генә тукланудан шулай кыска гомерле

дигән нәтиҗәгә килдем. Һәм үземә үзем максат куйдым – һәрбер кешенең үз бакчасы булсын, яшелчә, җиләк-җимешне үзе үстереп ашасын. Максатыма ирештем бит! Хәзер республика буенча командировкаларда йөрим дә канәгатьлек кичерәм: элек кычыткан, әрекмән, чүп үләне үскән урыннарда бүген яшелчә, җиләк-җимеш гөрләп үсә...

ҖИҢЕЛ ДӘ, ТӘМЛЕ ДӘ

Шашлык пешеп чыкты. Фарсил абый бик канәгать йөз белән безне өенә чакырды. Венера апа мул итеп табын кору белән мәшгуль. Тын да алмыйча, шушы икәүне күзәтәм: берсенә – 82 яшь, икенчесе 77не тутыра. Никадәр сынаулар узылган. Ә яшәүнең тәмен-ямен югалтмаганнар.

– Фарсил абыегыз өчәр сәгать мунча керә әле, – ди Венера апа. – Аннан чыгып, суга сикерә.

Бу урында шуны әйтергә кирәктер: әлеге дачаларның иң зур үзенчәлеге – бакчалар бетүгә, су башлана. Бу урынны алар Идел елгасы култыгы дип йөртәләр. Шәп бит: тирләп-пешеп эшләп аласың да бер-ике метр аралыктагы суга сикерәсең.

– Җәй буе дачада яшисезме? – дим.

– Юк, җәй буе яшәп булмый. Кайта-китә йөрибез, – диде Венера апа. – Фарсилне гел радиога, башка җиргә чакырып торалар. Аннан әле ул һаман китап яза, фән белән кызыксына. Кара көзгә кадәр шулай ике арада йөрибез, эш бетми бит.

Табынга утырыштык. Башта шашлык белән яңа бәрәңгедән авыз иттек. Шашлык шулкадәр йомшак ки, ашта пешкән кебек.

– Искиткеч, моны ничек ясадыгыз, Венера апа? – дим.

– Өйдә нәрсә бар, барысын да салдым: тавык өчен тәмләткеч, майонез, аз гына аш серкәсе, тоз, борыч, суган. Иң мөһиме – итне ясагач, бер-ике көн тотарга кирәк. Бөтен сере шул.

Иң дулкынландыргыч мизгел килеп җитте – бакча җиләгеннән десерт кабып карыйбыз... Баллы, авызда эреп китә. (Эремчек белән куертылган сөт бер-берсенә бик туры килә икән. Ул көнне мин үзем өчен шундый ачыш ясадым!) Шундый тиз әзерләнүен исәпкә алсак, моны ир-атлар, балалар да җиңел генә эшли ала.

– Кара, Фарсил әллә нинди тәмле әйберләр әзерли белә икән бит, – диде Венера апа.

– Ә көндәлек тормышта әзерләмиме? – дим.

– Әзерләгәнне генә ашый шул. Менә хәзер белермен инде. Бик әйбәт рецепт икән, онытмаска кирәк әле.

Менә шулай итеп, Фарсил абый унбер ел бергә гомер иткән тормыш иптәшен шаккатырды.

Алай гына да түгел, хезмәттәшләрем – ике Александр (фотограф белән машина йөртүчебез) да ул көнне, өйләренә кайткач, тормыш иптәшләренә шушы татлы десертны әзерләп ашаткан. Хәләл җефетләренең күңеленә әлеге ризык бик хуш килгән. Сез дә, хөрмәтле ир-атлар, тормыш иптәшләрегезне гаҗәпләндерәсегез килсә, әзерләгез. Аңа ун минут вакыт җитә!

Бакча җиләге – С витаминына иң бай җимешләрнең берсе, аның 100 граммында көнлек норма бар. Бу яктан ул бары тик карлыганнан гына калыша. Уртача зурлыктагы биш җиләктә С витамины зур бер әфлисунда булган кадәр.

ИЮЛЬ–АВГУСТ АЙЛАРЫНДА БАКЧАДА НИЛӘР ЭШЛӘРГӘ КИРӘК

ФАРСИЛ ЗЫЯТДИНОВТАН КИҢӘШЛӘР:

– Июль азагында бакча җиләге утырту вакыты. Мыеклары өч-дүрт яфрак җибәргәч, аларны кисеп алып утыртырга була. Аның да үз сере бар: мыекларның беренче, икенче үсентеләрен алырга кирәк, чөнки өченче һәм аннан соңгылары яхшы үсми. Бакча җиләгенең сортлары күп төрле: кайсысы иртә өлгерә, кайсы төре баллырак. Бакчачы анысын үзе карый.

– Июль – шулай ук куак-агачларда яши торган корткыч-бөҗәкләргә каршы көрәш ае. Аерым җир корткычлары күпләп үрчеп киткәндә, махсус өстәмә чаралар кулланырга мөмкин. Мисал өчен, гөблә (тля) белән зарарланган агач-куакларны, карбофос белән эшкәртергә кирәк: 10 литр суга 80 грамм нисбәттә. Икенче ысул: 5 литр суга, угычтан уылган яки вакланган сабын белән 200 грамм тәмәке салып ясалган төнәтмә ясап кулланырга була.

Талпаннарга каршы да да 10 литр суга 60 грамм карбофос катнашмасы сибәргә кирәк.

Кырмыскаларга каршы көрәштә «Муравьин» препараты яхшы. Ничек кулланырга кирәк икәнлеге инструкциясендә язылган.

– Август аенда теплицаларда авырулар нык тарала. Бигрәк тә ак канат зыян сала. Кыяр яфрагының аскы ягына ак канат үзенең ашказанында эшкәртелгән ризыгын бүлеп чыгара да, акрынлап гөмбәчекләр барлыкка килә. Шул сәбәпле яфраклар кибә һәм үсемлек һәлак була. Ак канаттан котылу өчен, теплицада бер генә чүп үләне дә калдырмагыз, чөнки алар арадашчы ролен үти. Ак канат шунда оя корып үрчи. Теплицадагы үсентеләрне бакыр купоросы эремәсе (10 литр суга 100 грамм бакыр купоросы) белән эшкәртергә кирәк. Шулай ук хәзер тагын бер препарат бар – «Имудон» дип атала. Ул корткыч бөҗәкләргә каршы нәтиҗәле көрәшә.

– Август ае – бакча казу чоры да. Элек колхозларда «туңга сөрү» дигән төшенчә киң кулланылышта иде. Бакчада да бу эшне онытмаска кирәк. Туңга сөрү дигән эш – кышка казып калдыру дигән сүз. Мондый туфракта яшелчәләр әйбәтрәк үсә, уңыш та мул була. Августта казылган җирдә микроорганизмнар эшли башлый, ә ашлама кертсәң, ул тагын да активлаша. Шуңа күрә казыр алдыннан җиргә ашлама кертергә киңәш итәм. Мисал өчен, 1 квадрат метрга 1 кашык суперфосфат яки шул ук нисбәттә калий сульфаты кертергә. Калий сульфаты булмаса, аның урынына көл сибәргә дә ярый. Һәм җирне казырга мөмкин.

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

Реклама 16+

Безнең Инстаграмда – «Татарстан»ның йөрәге!

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Казан ханлыгында **КАЙСЫ** шагыйрьләр яшәгән

Гитлер **КЕМНЕҢ** башы өчен өч миллион рейхсмарка вәгъдә иткән

Сугышта югалганнарны **НИЧЕК** эзләргә

Кырлайдагы Тукай музее бинасын **КЕМ** эшләгән

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ӨЧЕН МАХСУС

КАЗАН ХАНЛЫГЫ ШАГЫЙРЬЛӘРЕ: «БУ ҖИҺАН УЛ – ИГЕЛЕК ҺӘМ ХӨРМӘТ ҖИРЕДЕР...»

«Безнең татар гаҗәеп халык. Китап һәм шигырь «җене» кагылган кызык халык, – дип язган иде үзенең бер мәкаләсендә академик Миркасыйм Госманов. – Патшадан алып колларына, олы руханиларыннан яшь шәкертләренә кадәр ул гел укыган, язган, сүзләрдән юллар тезгән, уй-хыяллары белән кайгы-хәсрәтләрен җыр-шигырьгә салган». Менә хан Казаны турында Мөхәммәдъярның язып калдырган сүзләре: «Бер гаҗиб бу кем шәһәр эче тулуг: шагыйрь улмыш барча кечек һәм олуг». Чыннан да шулай – халкыбыз талантларга бай. Болгар-татар язма әдәбиятының Кол Галиләр чорыннан, хәтта тагын да борынгырак дәверләрдән, Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганилардан башланып киткән традицияләре ханлык чорында да дәвам иттерелә, үстерелә, баетыла.

Автор:
Фаяз Хуҗин

Әйе, Казан ханлыгы чорының рухи культурасы аңа кадәр яшәгән Идел Болгары һәм Алтын Урда дәүләтләренең рухи мирасы нигезендә формалаша. Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф»ы, Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис»е, Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е, Харәзминең «Мәхәббәтнамә»се, Хисам Кятибнең «Җөмҗәмә солтан»ы, Сәйф Сараиның «Гөлстан бит-төрки»се нигезендә туган иҗат җимешләре алар – ханлык чоры шагыйрьләренең безнең көннәргә кадәр килеп җиткән шигырь-поэмалары. Кызганыч, Мөхәммәдъяр әйткән күпсанлы «олуг-кечек» шагыйрьләрнең иҗатын гына түгел, хәтта исемнәрен дә белеп бетермибез. Белгәннәребез асылда түбәндәгеләрдән гыйбарәт.

ӨММИ КАМАЛ

Казан ханлыгы чорында иҗат иткән атаклы шагыйрьләрнең иң элгәреләреннән (1475 елда вафат). Аның чын исеме – Исмәгыйль, Өмми Камал – тәхәллүсе. Туган җире төгәл генә билгеле түгел, Идел буе шәһәрләренең берсендә түгелме икән дигүчеләр бар, шигъри телендәге үзенчәлекләренә карап, туган илен Төркия белән бәйләп караучылар да юк түгел. Күренекле әдәбият галиме, профессор Хатыйп Миңнегулов Өмми Камал бу ике төбәкнең икесе белән дә бәйләнгән дип саный: «Ул үз гомеренең шактый өлешен Идел – Җаек (Урал) буйларында һәм Кырымда уздырып, аннан Төркиягә күчеп киткән булса кирәк». Шунысы кызык: Өмми Камалны һәм аның әсәрләрен Төркиядә белмиләр диярлек, ә менә татарлар яшәгән Идел – Җаек төбәкләрендә шагыйрьнең иҗаты кульъязмалар рәвешендә киң таралган булган. Өмми Камал шигырьләре Казанда XIX йөздә һәм XX йөз башында күп тапкырлар китап рәвешендә дә басылып чыга. 1897 елда дөнья күргән «Китабы Өмми Кәмал» исемле җыентыгына аның 140 шигыре урнаштырылган.

Шагыйрь иҗаты суфичылык рухы белән сугарылган. Ул һәм аның лирик герое – бөтен күңелен, бөтен барлыгы белән үзен Аллаһка юнәлткән, бары тик Аңа гына табынган искиткеч диндарлар. Укучысын ул дөнья малына кызыкмаска, нәфес колы булудан туктарга, гөнаһлардан арынып, игелекле гамәлләр генә кылып, гадел яшәргә өнди, юлдан язганнарны, гайбәт сөйләүчеләрне, ялганчыларны, начар гамәл кылучыларны кискен тәнкыйть утына тота, юк кына языклары өчен үзен дә битәрли.

Кешедә яхшы сыйфатлар тәрбияләп, җәмгыятьтәге тискәре күренешләрдән арынып, киләчәккә омтылу, ахыр чиктә, һәркемгә бары тик Аллаһ кушканча гына яшәргә тиешлеген исенә төшереп тору Өмми Камал иҗатының асылын тәшкил итә һәм аның нигездә гуманистик рухта булуын раслыйлар.

МӨХӘММӘД ӘМИН

Аның исеме безгә таныш инде. Әйе, ул 1487–1496 һәм 1502–1518 нче елларда Казан ханы булып торган күренекле шәхес. Казанда Мәскәү протектораты урнашкач, Иван III даирәсендә тәрбияләнеп үскән бу егет – Олуг Мөхәммәд нәселенең соңгы вәкиле – рус патшасы сүзеннән чыкмаска тырышып, ханлык белән идарә итә башлый. Халык ризасызлыгы аны тәхеттән ваз кичәргә мәҗбүр итә. Яңадан тәхеткә кайтканнан соң Мөхәммәд Әмин мөстәкыйль сәясәт алып бара башлый, Казанның бәйсезлеге өчен көрәш юлына баса. Илдә тынычлык урнаша, хуҗалык үсәныгый, чит илләр белән сәүдә җанланып китә. Хан үз тирәсенә шагыйрьләр, җырчы-чичәннәр, музыкантлар, рәссамнар туплый, алар белән дустанә аралаша, әңгәмә-бәхәсләр оештыра. Күрәсең, безнең Милли музеебызда саклана торган һәм ян-ягына шигъри юллар язылган матур бизәкле комганның Насыйр исемле оста тарафыннан нәкъ менә Мөхәммәд Әмин заказы белән ясалуы да, вафатыннан соң аның төрбәсендә шагыйрь Мөхәммәдъярның сакчы булып торуы да очраклы хәл түгелдер.

Мөхәммәд Әмин иҗаты тулысы белән сакланмаган, әлбәттә. Безгә аның Болгар иленә яу белән килеп, шәһәр-авылларны көлгә,

Н. Хуҗиәхмәтов рәсеме

хәрабәгә әйләндергән Сәмәрканд әмире Аксак Тимергә нәфрәт белдереп язган «Гыйкаб» («Үч алу») исемле шигыре билгеле:

– Чыкды һиҗрәттән җиде йөз илледә –
Төште галәмгә хәраблык зилзилә.
Үзе – аксак, гакылы – ахмак, фетнәдар
Золымыны изһар кылды һәр йиргә.
Күп голәмә вә мәшаехләр шәһид
Булдылар дине ислам нуры илә.
Дарел-ислам фетнәсендин, бел гайан,
Булды вәйран, акды йәшьләр хәуфилә.
Нә җавап бирер Хода каршында ул,
Сорса Алла шиддәт вә гыйкаб илә.
Йа Илаһи, әйлә ул бәндәңне сән
Ахирәтдә залим вә җаһиле илә.

Мөхәммәд Әмин чәчмә әсәрләр дә язган булырга тиеш, диләр галимнәр. Мәсәлән, филология фәннәре докторы Мәсгут Гайнетдинов зур гына күләмле «Могҗизнамә» әсәрен (ул 2004 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты) Мөхәммәд Әмин иҗатына нисбәтле булуын раслады.

К. Нәфыйков рәсеме

МӨХӘММӘДЪЯР

Безгә мәктәп елларыннан ук таныш, Казанда Сәхиб һәм Сафа Гәрәйләр идарә иткән бик авыр, катлаулы чорда ил язмышы өчен борчылып, аның киләчәге турында кайгыртып яшәгән һәм иҗат иткән олуг шагыйрь, фәлсәфәче, гаделлек җырчысы.

Әдип руханилар гаиләсендә дөньяга килә («Атамыз Мәхмүд хаҗи догачы...»), XV гасыр ахырында Казанда тугандыр дип фаразлана, һәрхәлдә гомеренең күп өлеше Казанда үтә, үзенең әсәрләрен дә биредә яза. Нинди эш белән шөгыльләнгән – анысы билгесез. «Нуры содур» поэмасында ул үзенең 1519 елда үлгән Мөхәммәд Әмин хан төрбәсендә мөҗавир – кабер сакчысы булып торуы турында хәбәр итә. Тормышы җиңелдән булмагандыр, дип уйларга нигез бар: «чикдем әмма рәнҗ вә мәшакъкать бихисап», – дип яза ул «Төхфәи Мәрдан»да. Шагыйрьнең үлгән елы да билгеле түгел. Ул да, чордашы Кол Шәриф кебек, 1552 елгы сугышта һәлак булгандыр, дип уйлаучылар бар.

Безнең көннәргә кадәр Мөхәммәдъярның өч әсәре сакланган – югарыда телгә алынган «Төхфәи мәрдан» («Егетләргә бүләк»), «Нуры содур» («Күңелләр нуры») поэмалары һәм «Нәсыйхәт» шигыре. Шагыйрьнең «Төхфәи мәрдан» поэмасы XIX гасырның беренче яртысында Казан һәм Санкт-Петербург университетлары профессоры И.Н. Березин чыгарган «Төрек-татар кулъязмалары тасвирламасы»нда һәм «Төрек хрестоматиясе»нең 1 нче томында телгә алына. «Нуры содур» поэмасын фәнни әйләнешкә 1941 елда «Совет әдәбияты» журналының 4 нче санында басылып чыккан мәкаләсендә Нәкый Исәнбәт кертеп җибәрә. «Нәсыйхәт» шигыре исә иң әүвәл М. Ивановның 1842 елгы «Татар хрестоматия»сендә басылып чыга.

«Нәсыйхәт» шигырендә Мөхәммәдъяр күңелне бакча белән тиңли, аны чиста тотарга, нурларга чакыра:

– Күңел бакчаңа кунган кошчык былбыл,
Тыңла, эшмәкәрем, ни дип сайрый ул:
«Бакчаң – золмәт, чәнечке үскән, гөле юк,
Эче тулы хәшәрәт, нәҗесе чук».
Канат киереп ул бакчаның эчендә
Очып йөрде хәсрәттә көн-кичен дә.
Ахыр бер көн табып рәйхан гөлен,
Ачты аңа гашыйклык ярсу хален.
Әйтә: И сөйгәнем, рәйхан гөлгенәм,..
Ни өчен ул чәнечкеләрне коймыйсың,
Нигә үз орлыгың чәчеп куймыйсың?
Ул чак бакчаң булыр иде сөйкемле,
Хуҗасы да – көткән кунак шикелле.
Йөрер иде күпләр тамаша кылып,
Явар иде өстеңә нигъмәт тулып».
Әгәр камил булсаң акыл ягыңа,
Надан булма, гөлләр утырт багыңа...

«Төхфәи мәрдан» поэмасын Мөхәммәдъяр, үзе күрсәтеп үткәнчә, 1539 елның 22 декабре белән 1540 елның 12 гыйнвар арасында яза. Әсәрнең исемен бүгенге әдәби телгә гадәттә «Егетләргә бүләк» яисә «Егетләр бүләге» дип тәрҗемә итәләр. Миркасыйм Госманов аны «Ил агаларына бүләк» дип тәгаенләргә тәкъдим итә; чөнки, ди ул, поэма егетләргә генә түгел, бәлки, беренче чиратта, ил башында торучы иҗтимагый көчкә ия булган ир-атларга, идарәчеләргә атап язылган. Шагыйрь аларны сүзнәсыйхәт ярдәмендә тугры юлга дәшә, гади халык өчен игелекле гамәлләр кылырга өнди.

Поэма, электән килгән традиция буенча, Аллаһы Тәгаләгә һәм аның пәйгамбәрләренә мөрәҗәгать белән башлана:

– Илаһи, Син юмарт, ризык бирүче,
Бер Син, бар Син, рәхим, гафу итүче.
Хәсрәтленең сердәш дусты, яры Син,
Һәр мескенне дәвалаучы бары Син...
Синнән килсә кайгы – дәва бир Үзең,
Авыру Синнән икән – шифа бир Үзең...
Биргәнеңә күп шөкерләр, Илаһым,
Кылган хатам өчен кичер, Илаһым.

Поэманың калган өлеше укучыны, төгәлрәк әйтсәк, ил агаларын, гел яхшылык эшләргә өндәүдән гыйбарәт:

– Көчең барда тырыш, арттыр ишеңне,
Тик үзеңә дошман итмә кешене.
Ачу, нәфрәт, кинә тотып юанма,
Дошманым зәгыйф дип эчтән куанма...
Чын ир шулдыр – яман сүзне кичерер,
Мәрхәмәт табыныннан җам эчерер...
Чын, хакыйкать, тугры эшне эшлә син,
Һәм үзеңнән яманлыкны ташла син...
Бер яхшыны кылсаң, – унны алырсың,
Унны бирсәң, – урнына йөз алырсың...

Мөхәммәдъяр фикеренчә, яхшылыкны иң элек көчлеләр – көчсезләргә, байлар фәкыйрьләргә карата эшләргә тиешләр. Шундый фикерне ул поэмада күпсанлы гыйбрәтле мисаллар – хикәятләр белән раслый. Кеше дөньяга мәңгелеккә килми, ди шагыйрь, шуңа күрә ул мәңгелеккә, теге дөньяга, үзеннән соң да искә алып сөйләрлек яхшылык эшләп, игелек кылып китәргә тиеш, чөнки «бу җиһан ул – игелек һәм хөрмәт җиредер».

«Нуры содур» поэмасы да асылда әхлак проблемаларына багышланган. Аның эчтәлеге, Мөхәммәдъяр иҗатын тирәнтен өйрәнгән олуг галимебез Шакир ага Абилов язганча, «гаделлек нигезендә корылган идеаль дәүләт турындагы хыял белән сугарылган». Бу аңлашыла да, чөнки поэма 1521–1524 нче елларда Казан ханы, аннан соң, 1532 елдан башлап, Кырым ханы булып торган Сәхибгәрәйнең үтенече белән язылган һәм аңа багышланган. Бу әсәрен Мөхәммәдъяр 1542 елның 18 маенда тәмамлый.

Мөхәммәдъяр актив иҗат белән хан тәхетендә Сафагәрәй утырган катлаулы чорда шөгыльләнә башлый. Кырым белән Мәскәү тарафдарлары арасында Казан тәхете өчен көрәш, Сафагәрәйнең урыс җирләренә, Василий III һәм Иван IV хәрбиләренең Казанга яулары, тәхет тирәсенә елышкан кырымлыларның халыкны талавы, күләме елдан-ел артып торган салымнарны түли алмыйча хәлдән тайган «кара» халыкның ризасызлыгы аркасында әледәнәле булып торган фетнәләр, ыгызыгылар – боларның барысы да Мөхәммәдъяр күз алдында эшләнә. Ул үзе дә шул гади халык вәкиле ич, өстенлеге тик шунда – табигатьтән килгән акылы һәм таланты бар, күпне күрә, аңлый, уйлана. Мәскәү идарәчеләре басымы астында Сафагәрәй хакимиятенең озакка бармаячагын сизенә. Идеаль дәүләт, гадел хан турындагы уйлары күңеленә тынычлык бирми.

Менә шул халәттә инде ул Сәхибгәрәй хан үтенечен кабул итәргә карар кыла. Чөнки Мөхәммәдъяр аны куәте-абруе елдан-ел үсеп баручы Кырым ханы буларак кына түгел, бәлки тирән белемле, мәгърифәтле һәм үз халкы, иле турында нык кайгыртучы хаким буларак та белә. Шуңа күрә дә ул әсәрен Сәхибгәрәй ханга мактау сүзләре белән башлап җибәрә:

Олуг солтан бөек Сәхибгәрәй хан, –
Җир йөзенең шаһы, шөһрәт иясе,
Байлык, бәхет, муллык, рәхәт иясе.
Ил-халыкны акыл белән тотты үзе,
Шуңа йөри мәшрикъ-мәгърибтә сүзе.
Ике дөньяда Хак аны зур итте,
Барча баш иеп, тез чүкте, җир үпте.

Шуннан соң инде Мөхәммәдъяр хакимнәр өчен иң кирәкле ун сыйфатны санап үтә һәм аларның һәрберсе турында аерым бүлекләрдә тулырак итеп сөйли. Шагыйрьнең ихластан инануынча, гаделлек, рәхимшәфкать, юмартлык, оялчанлык, сабырлык, аз сүзлелек, үз динеңне яклап көрәшергә әзер булу, сүзеңдә тора белү, тугрылык, кирәк чакта гафу үтенә белү кебек матур сыйфатлар хакимнәргә генә түгел, һәр кешегә хас булырга тиеш. Санап үтелгән ун сыйфат арасында гаделлек беренче урында тора. Ул – дәүләтнең бөтенлеген, иминлеген, байлыгын, кешеләрнең тигезлеген тәэмин итүче иң беренче шарт, хезмәт халкының хыялы – житеш тормышның нигезе.

Гуманист-шагыйрь Мөхәммәдъяр үгет-нәсыйхәт юлы белән халыкны агартып-тәрбияләп, хакимнәрне гаделлеккә өндәп, Аллаһка якынлаштырып, киләчәктә идеаль җәмгыять кору турында кайгырта һәм бу яктан аның уйфикерләре Көнбатыш Европада XVI гасырда формалаша башлаган социаль-утопистлар идеологиясенә аваздаш.

Мөхәммәдъяр иҗатында ханлык чорында яшәгән ерак бабаларыбызның дөньяга карашы, әхлак-горефе, эстетик зәвыгы, киләчәге турында уйлары-хыяллары чагылыш тапкан. Ул безгә шул ягы белән кадерле.

Даян Мурзин.

Мурзинның партизан отряды.

Даян Мурзин, ул Юрий Васильевич да, ул «Кара генерал» да, ул «грузин генералы Юрий» да.

Партизаннарның Җиңү парады. Алда – Даян Мурзин.

Даян Мурзин Владимир Путин белән. 2005 ел. Словакия.

КЫЛ ӨСТЕНДӘГЕ ГОМЕР: ГИТЛЕРНЫҢ ШӘХСИ ДОШМАНЫ

Прага, 1944 елның көз азагы, караңгы төшеп килә... Партизан Даян Мурзин, берничә сугышчыны ияртеп, Үзәк Комитеттан таныш түгел берәү белән очрашуга китеп бара. Һәм чактан гына немец автоматчыларына юлыкмый кала. Немецлар төзәп аякларына ата – сугышчыларны тере килеш кулга алырга телиләр. Даян елгага сикерергә өлгерә, немецлар ээрлекләп, артыннан елга буйлап йөгерә. «Кара генерал» Даянны тоткан өчен Гитлер өч миллион рейхсмарка бирергә вәгъдә иткән була!

АЮ ӨНЕНДӘ ДҮРТ КӨН

Пуля яңгыры астыннан елга агымына ияреп котылганнан соң, ул, яралы килеш судан чыгып, урманчы өенә үрмәләп килеп җитәргә көч таба. Өйдә калу куркыныч була, шуңа да урманчы, сугышчының яраларын бәйләп, аны яңадан урман куелыгына алып керә. Ташландык аю өнендә вакытлыча калдырып китә.

Автор:
Алёна Кутыркина

– Ботаклар аша күреп ятам – фашистлар 15 метрда гына печән кибәненә ут төртәләр, этләр минем өн тирәли әйләнгәләп йөри, әмма эзгә чыга алмый, – дип искә төшерә Кара генерал, еллар узгач. – Мин ул өндә дүрт көнгә якын яттым. Ашарга юк иде, сусауны кар белән бастым. Ул арада аяктагы яраның сызлавына түзәр чама калмады – ул бик нык үлекләгән иде. Кыр сумкасыннан компасны алып, аның пыяласын пистолет белән бәреп ваттым. Иң зур кыйпылчыкны алып, яраны кисеп җибәрдем. Үлек агып чыкты, авыртудан мин аңымны җуйдым...

Аңына килгәндә, аны иптәшләре сарайга күчергән була инде. Яралары төзәлгәч, ул янә дусларын эзләп таба, янә сугыш өермәсенә барып керә.

БЕЗ СУГЫШКА ЫШАНМАДЫК

Совет-фин сугышы башланганда Даян мәктәп директоры булып эшли. Ул үз ирке белән фронтка китәргә языла, әмма сугыш фәнен үзләштергән арада сугыш бетеп өлгерә. Даян Рига хәрби училищесына укырга керә. 1941 елның июнен ул Балтыйк буе хәрби округының 10 нчы укчылар дивизиясендә взвод командиры буларак каршылый.

– Бөек Ватан сугышы минем өчен башкаларга караганда, иртәрәк башланды. 1941 елның 19 июнендә үк әле безне, көтмәгәндә, чик буендагы шәһәргә җибәрделәр. Без барыбыз да аптырашка калдык. Ике немец коммунисты чик аша үтеп, безнең командованиене фашистларның һөҗүм итәчәге хакында кисәткән булган икән, – дип яңгырый Даян Мурзинның тасмага яздырылган тавышы. – Күпләр моңа ышанмады, хәтта окоплар казыганда да. 21 июньнән 22 июньгә каршы төнне без тулы әзерлек белән аягүрә басып торып үткәрдек, һичкем керфек тә какмады, бәләкәй генә кыштырдаган тавышка да колак салдык. Иртән иртүк безнең баш өстеннән фашистларның беренче самолетлары очып үтте...

МИН КАЛДЫМ...

Сугышның беренче көннәре гомерлек булып истә калды. Самолетлар улавы, танклар гөрелтесе, пулялар сызгыруы, яралыларның ыңгырашуы – немецлар изеп-таптап алга ыргылды. Дүртенче көнне, Рига вокзалындагы кул сугышы вакытында, Даянның эченә штык белән кадыйлар. Яугирләр күп итеп канын югалткан иптәшләрен яу кырыннан алып чыгалар.

– Ул вакыттагы газапларга адәм баласы түзәрлек түгел иде. Мин: «Үтерегез мине!» – дип ялвардым, күрәсең, берәүнең дә кулы күтәрелмәгән. Минем белән алар ерак китә алмый иде. Зинһар, урман юлындагы чокырда калдырыгыз, дип үгетләдем.

Ике көн аңсыз ятканнан соң яралы аңына килә. Янәшәдән үтеп баручы крестьянга сигнал бирә ала. Латыш кешесе, арбасына салып, солдатны табиблар кулына тапшыра. Күпмедер хәл җыйганнан соң, Даян хастаханәдән кача һәм шунда ук үзенекеләрне куып тотарга ашыга. Минск янында баш түбәсенә приклад белән оралар. Әсирлеккә төшә. Бу юлы Вера исемле шәфкать туташы качарга булыша аңарга. Әмма инде фронтны куып тота алмый.

ПАРТИЗАН, ДИВЕРСАНТ

Ямпольскинның «За Родину» дигән партизаннар төркеменә кушылып, Даян беренче операциясенә китә. Аларның төркеме күпердә немецларның йөк машинасын каравыллап торып, җиде фрицны юк итә һәм трофей итеп корал алып кайта. Шуннан соң яшь егетне взвод командиры итеп куялар.

Икенче операция вакытында аның башын яралыйлар. Яралы партизанны Горькийдагы госпитальгә озаталар. Сәламәтләнгәч, диверсион мәктәптә уку көтә үзен.

Командование Мурзинны фронт сызыгының артына, Төркестан легионына җибәрергә хәл итә. Шәхси составны таркату бурычы куела. Нәтиҗә озак көттерми – озакламый Төркестан легионы һәм Идел-Урал легионы бүлекчәләре Кызыл армия ягына чыга башлый.

ДЖЕЙМС БОНДТАН ДА БОЛАЙРАК

Бурычны уңышлы үтәгәннән соң, сугышчыны Коминтерн халыкара мәктәбенә җибәрәләр, анда чит илләрдә каршылык күрсәтү өчен разведчиклар һәм диверсантлар әзерлиләр. 1944 елның августында Даян Мурзин Ян Жижка исемендәге интернациональ партизаннар бригадасының командиры була.

– Миңа 1944 елда 23 кенә яшь иде әле, ә минем бригадада – меңнән артык кеше, шуларның яртысы кырык яшьтән узган. Мәктәптә миңа өлкәнрәк булып күренер өчен сакал үстерергә кирәк, дип киңәш бирделәр. Чөнки ул бик куе иде, һәм мине, шул сакалыма ишарәләп, Кара генерал дип йөртә башладылар. Ел ярым йөрттем мин аны. Сугыштан соң, инде кыргач, фронтташ дусларның: «Син малай гына икән бит әле!» – дип исләре китте.

Әнә шул «малайга» берничә көндә 300–500 кешелек отрядлар җыярга туры килә, алар дошман тылында көтелмәгән һөҗүмнәр ясый. Бригадада руслар, чехлар, словаклар, поляклар, инглизләр, французлар, итальяннар, венгрлар, румыннар һәм хәтта ике Америка очучысы, шулай ук немец коммунистлары да була.

Даянның Чехиядә хәрәкәт итүче партизаннар отряды турында Гитлер белеп ала һәм чын мәгънәсендә котырына. Әлеге сакаллы әрсез партизанның тотып китергәннәре өчен ул 3 миллион рейхсмарка вәгъдә итә. Шулай итеп, «Кара генералны» тотарга дип СС оберштурмбаннфюреры Отто Скорцени чыгып китә. Партизаннар отрядының берсе яшеренгән Плоштина авылын камап алалар. Фашист анда икенче Хатынь оештыра.

Даян Мурзин иптәшләре өчен үч ала башлый. Аның төркеме танк дивизиясенең генерал-лейтенанты фон Мюллерны әсирлеккә ала. Бу фашистлар җитәкчелегенә шок ясый, әмма ул вакытта аның барлык фронтларда да проблемалары башланган була инде – Кызыл Армия Берлинга якынлаша.

МИЛЛИ КАҺАРМАН

Сугыштан Даян Баян улы инвалид булып кайта: яралары бихисап. Чехиядә подпольеда булганда танышкан радист кызга өйләнә. Туган Башкортостанында Даян Мурзин эчке эшләр министрының кадрлар буенча урынбасары дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Еш кына Чехия белән Словакиягә барып йөри, анда ул – милли каһарман һәм 16 шәһәрнең мактаулы гражданы, хәтта урамнар аның исемен йөртә.

Россиядә Мурзин исемендәге урам әле һаман да юк. Кызганыч, разведчиклар туган илләрендә сирәк очракта гына танылу ала шул.

Даян Мурзин җиде ел элек вафат булды. ■

– Ул бик киң күңелле, игелекле җанлы, гаҗәеп язмышлы кеше иде. Һичбер нәрсәгә үкенмәде, үтә дә оптимист рухлы булды, – дип сөйли танылган партизанның кызы Роза Даян кызы. – Әти безне: «Намуслы булыгыз, көчсезләрне рәнҗетмәгез һәм әти-әниегезне, ватаныгызны яратыгыз!» – дип өйрәтте.

СОЛДАТНЫҢ ИСЕМЕН КАЙТАРЫЙК



Соңгы солдат җирләнмәгән килеш сугыш тәмамланмаган дип исәпләнә. Кайчандыр бөек полководец Александр Суворов әйткән бу сүзләр төгәлләштерүне таләп итә. Миллионлаган совет солдатларының язмышы билгесез калган икән, димәк сугыш әле, чыннан да, тәмамланмаган. Безнең әңгәмәдәшебез – Татарстан Республикасы Милли музееның Бөек Ватан сугышы Музей-мемориалы мөдире, ТРның «Хәрби дан клубы» Ассоциациясе рәисе Михаил Черепановның фикере шундый.

– Михаил Валерьевич, Бөек Ватан сугышы моннан 75 еллап элек тәмамланган. Һәм әлегә кадәр йөз меңнәрчә сугышчы хәбәрсез югалган дип исәпләнә...

– Йөз меңнәрчә генә түгел – миллионнарча. Татарстанда, ачыкланган белешмәләр буенча, 384 меңнән артык кеше сугыштан кайтмаган. Һәм иң күңелсезе, бабаларыбыз һәм бабаларыбызның аталарының 186 меңнән артыгы «хәбәрсез югалган» дип исәпләнә, ягъни юридик яктан сугышта һәлак булган дип танылмый. Әгәр сугыштан кайтмаган якташларыбызның күпчелеге һәлак булган дип саналмый икән, аларның истәлеген лаеклы рәвештә мәңгеләштереп буламы?

– Эзләнү отрядлары дистәләгән еллар буе сугыш барган урыннарда эшлиләр, һәлак булганнарның калдыкларын табалар, архивлар тулылана... Әмма сез китергән саннар – алар куркыта. Без шулай начар эзлибезме?

– Барысы да гади генә түгел шул. Әле күптән түгел генә, әйтик, рөхсәт ителгәннәр кысасында гына эзли идек. Мәсәлән, әсирлектә һәлак булган яисә яралардан үлгән совет солдатлары һәм офицерлары турындагы мәгълүматлар бик озак сер итеп сакланды. Бары XXI гасырда гына аларның язмышын билгеләү мөмкинлеге туды– мәгълүмат РФ Оборона министрлыгы ачкан сайтларда барлыкка килде. Бүгенге көндә «ОБД Мемориал» һәм «Память народа» кебек сайтларда күп кенә җентекле язмалар урнаштырылды. Тик шунысы начар, мәгълүматның зур өлеше йә бозып күрсәтелгән, йә шифрланган рәвештә бирелә.

– «Бозып күрсәтелгән яисә шифрланган»ны ничек аңларга?

– Бер мисал китерәм. Сез РФ Оборона министрлыгы сайтына керәсез һәм һәлак булган Американов фамилияле сугышчы турында мәгълүмат табасыз. Чынлыкта сүз Әмирханов фамилияле сугышчы турында бара. Кемнеңдер әллә кайчангы хатасы аркасында сугышчы әлегәчә хәбәрсез югалган санала, юкса аның һәлак булуы асылда расланган бит. Әмма туганнарының яки тикшерүчеләрнең кайсысы аның шул ук кеше булуын фаразлый ала? Торак пунктлар һәм хәтта районнар белән дә шундый ук хәл. Эзләнү эшен җиңеләйтер өчен Елена Сөнгатова һәм шушы юлларның авторы җитәкчелегендәге инициатив төркемгә ике яңа сайт – kremnik.ru (Мемориал Великой Отечественной войны) һәм Татфронту.ру сайтларын ачарга туры килде, аларда һәлак булган якташларыбызның исемлеге төзәтелгән хәлдә бирелә. Бу мәгълүмат базасының ихтыяҗга ия булуы турында аның популярлыгы да сөйләп тора. Көн саен бу сайтларга дөньяның 105 иленнән интернет кулланучы берничә мең кеше керә.

Солдатның һәлак булуы турындагы мәгълүматлар аның гаиләсенә ирешсен өчен бик зур тикшеренү эшләре алып барырга кирәк. Һәм ул профессионаллар тарафыннан, һичшиксез, даими килешү нигезендә алып барылырга тиеш.

– Әгәр волонтёрларны җәлеп итсәң?

– Минемчә, бу мәктәп отрядлары һәм волонтёрлар дәрәҗәсендәге эш түгел. Хәер, әлбәттә, тиешле әзерлек һәм эшләргә теләкләре булганда, яшь эзләнүчеләрне дә җәлеп итәргә мөмкин. Сүз уңаеннан, Татарстан Хөкүмәте ягыннан эзләнүчеләрне һәм мәктәп хәрби дан музейлары активистларын югары квалификацияле итеп, күптөрле, формаль булмаган рәвештә әзерләү зарурилыгын аңлау бар. Моның өчен сугыш тарихын өйрәнүнең яңа формаларын һәм методларын, мәгълүмати технологияләрне һәм практик эшләрне куллану таләп ителә. Шушы таянычка өметләнеп, «Хәрби Дан клубы» Ассоциациясе активистлары, Абдулла Алиш исемендәге Балалар иҗат йорты укытучылары белән бергә, «Яшь эзләнүче мәктәбе»н оештырдылар, аның филиаллары Казанның барлык районнарында да бар. Шунысын да искә төшерим, Татарстанда нәкъ менә студентлар

Фото: Александр Ефремов

Быел «Үлемсез полк» хәрәкәтенә 170 мең казанлы һәм мәркәзебез кунагы кушылды.

һәм мәктәп укучылары дәүләти әһәмияттәге бурычны – һәлак булган якташларының 27 томлы Хәтер китабын чыгару бурычын үз җилкәләренә алды. ТР Хәтер китабы редакциясе эшче төркеменең нигезен нәкъ менә ирекле ярдәмчеләр тәшкил итте.

– Әле сиксәненче елларда ук сугыш барган урыннардан һәлак булган сугышчыларның калдыкларын эзләүче Казан «Кар десанты»н бөтен ил белә иде. Эзләнү эшләре хәзер дә дәвам итәме?

– Әлбәттә. Апрель аенда Татарстан эзләнүчеләренең вәкилләре «Безнең Җиңү» яңа Халыкара иҗтимагый оешмасын гамәлгә куючыларның берсе булды, ул БДБның 15 иле, Балтия һәм Грузиянең яшьләр лидерларын берләштерә. Татарстан Республикасы исеменнән оешманы гамәлгә куючылардан шушы юлларның авторы һәм Т.В.Рахманова булды. Оешманың төп максатларыннан берсе – БДБ илләре территориясендә уртак эзләнү операцияләрен әзерләү һәм үткәрү, Икенче дөнья сугышы фронтларында әлегәчә хәбәрсез югалган дип саналган биш миллион совет гражданы турында мәгълүматлар эзләп табу. Һәм шулай ук гаять мөһим нәрсә – табышлар турында Ватанны яклаучыларның туганнарына һәм якыннарына җиткерү. 80 нче еллар ахырында безгә, студентларга һәм мәктәп укучыларына, йөзләрчә мең һәлак булган ватандашыбызның медальоннар һәм документлар буенча танылмавын, кәсләр астында яки ашыгыч рәвештә бомба чокырларына һәм окопларда күмелеп калуын һәм архивларда «хәбәрсез югалганнар» булып саналуын исбатларга туры килде. Хәзер бу факт ил хөкүмәте дәрәҗәсендә танылды.

– Телевизион сюжетларга караганда, «үлем» медальоннары эзләнү барышында хәзергә кадәр хәбәрсез югалган геройларның шәхесләрен ачыкларга булыша...

– Бу шулай. Тик кайчакларда эзләнү отрядлары казыну вакытында медальоннары һәм шәхси әйберләре буенча ачыкланган сугышчыларның туганнарын эзләү белән генә чикләнә. Шунысын аңлау мөһим: «хәбәрсез югалганнар»ның туганнары солдатның язмышы турындагы мәгълүматны каян ала – медальонны тапкан казучыданмы яки компьютер артында белешмә базаларын өйрәнеп утырган архивистларданмы? Асылда, алар өчен барыбер.

– Әгәр кем дә булса хәбәрсез югалган дип саналган туганының язмышын үзе ачыкларга тырышса?

– Туганнарны эзләүнең ысуллары берничә. Бу, әйтик, район хакимиятләренә яисә, матбугат чаралары аша төбәкнең бар халкына мөрәҗәгать булырга мөмкин. Район архивларында кайчакта безнең эш өчен бик тә кирәкле мәгълүмат катламы ята. Мәсәлән, тол хатыннарның пенсия эшләренә теркәлгән «похоронка»лар, алар турында ни солдатның туганнары, ни военкомат хезмәткәрләре белмәскә мөмкин. Тол хатынның үлеме белән мондый документлар еш кына юкка чыга, пенсия эше белән бергә юк ителә. Аерым тематикадагы библиографияне һәм мемуарларны өйрәнү дә шулай ук әһәмиятле. Электрон мәгълүмат базасы белән тикшерену эшләре алып бару – эзләнүчеләрнең нәтиҗәле эш формасы була ала һәм булырга тиеш тә. Әле күптән түгел генә без, кабатлап әйтәм, әсирлектә үлгән ватандашларыбыз исемлеге белән танышу мөмкинлегенә ия булдык. Миллионнарча язмышлар Германия архивларында онытылып яткан яки КГБ архивларында хәтта туганнарыннан да яшереп сакланган! Шул ук вакытта немец лагерьлары карточкалары һәм СССР НКВДсының фильтрацион эшләре үлем турындагы мәгълүматны, фотолар һәм бармак эзләрен генә түгел, хәрби әсирләрнең кыюлык һәм батырлык мисалларын да саклый. Боларның барысын халыкка да ачарга кирәк.

Гаделлекне торгызырга вакыт. Без Җиңүдән соң 75 ел үткәч тә кайда югалганнары билгесез булган миллионнарча исемсез геройлар иле булып калырга тиеш түгел.

Әңгәмәдәш –
Михаил РЯБИНИН

ТЫНГЫ БИРМӘС ХӘТЕР УТЫ

«Дәү әни, ике мәртәбә үлгән дигән хәбәре килгән улының, исән килеш өйгә кайтып кергәнен күргәч, кулындагы бердәнбер фарфор чәйнеген идәнгә төшереп җибәрә. Сугышка сау-сәламәт киткән улы яу кырыннан сукыраеп кайта. Шул килеш тә алар бирешми: дәү әни улын, ягъни минем әтине төрле үләннәр белән дәвалый башлый. Соңрак әти өйләнә. Ә мин туган көнне аның гәүдәсеннән, әйтерсең, ток уза: тәненең һәр күзәнәге чемердәп куя. Шул көнне әтинең күзләре шәүлә күрә башлый...»

Бу танылган эзтабар әдип-архивчы һәм шагыйрь Шаһинур абый Мостафин сөйләгәннәрдән. Илле елдан артык гомерен эзтабарлыкка багышлаган шәхес ул.

Автор:
Руфия Фазылова

-Шаһинур абый, сез әтиегезнең батырлыгы турында һәрвакыт яратып сөйлисез. Эзтабар булып китүегездә аның роле бармы?

– Бик зур. Әтием – Әхмәтсафа Мостафа улы Мостафин, Бөек Ватан сугышында исән калган 9 «матросовчы»ның берсе. 28 нче гвардияче укчы дивизиянең 235 нче укчы полкы рядовое, автоматчы булган ул. 1943 елның 15 октябрендә Псков өлкәсенең Невель районындагы Горушки авылын фашистлардан азат иткәндә, дошман дзоты амбразурасын күкрәге белән каплый. Һәм... Ходайның рәхмәте белән исән кала! Дөрес, башта аны үлгән дип уйлыйлар. Җирдән кара янган кулы гына чыгып торган чөнки. Балчык белән томаланган, канга баткан гәүдәсен актарып алгач, яшь солдатның исән икәнен күреп шаккаталар. Аннан тиз генә госпитальгә алып китәләр. Җиде ай дәвалана ул. «Әти-әнисе җирләсен», – дип, әтине туган ягына – Мамадыш районы Арташ авылына җибәрәләр. (Хәтта аерым шәфкать туташы да билгелиләр.) Шунысын да әйтим: күрсәткән каһарманлыгы өчен әти Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә. Шәфкать туташы сукыр, көчкә йөрүче әтине җитәкләп туган йортына кайтарып куя. Дәү әнинең, барлык туганнарның ул чагында ниләр кичергәнен сөйләп тә, язып та аңлатырлык түгел...

Әти сугыш турында сөйләргә яратмый иде. Бары соңрак, миңа 17 яшь тулгач, бер әманәтен җиткерде. Һич онытасым юк, Бөек Җиңүнең 20 еллыгын билгеләп үткән көн иде ул. Шул көн хөрмәтенә бакчада 20 төп алмагач утырттык. Бик сөенгән иде шул чакта.

– Улым, минем кебек дошман утын каплап та исән калган кешеләр бармы икән, шуны белеш әле, – диде ул. Әтигә:

– Белешәм, – дип сүз бирдем. Һәм шул көннән башлап сугыш каһарманнарын эзләүне үземә бурыч итеп алдым.

– Кеше ышанмаслык хәл бит: амбразураны күкрәк белән каплап ничек исән калып була?! Андыйлар чынлап та булганмы?

– Әйе, кеше ышанмаслык хәл... Ләкин андыйлар булган, һәм берәү генә дә түгел.

Башта Советлар Союзы Герое Александр Матросов турында әйтәсем килә. «Матросовчылар» исеме нәкъ менә аның белән бәйле бит. Ул милләте буенча татар. Чын исеме – Шакирҗан Мөхәммәтҗанов. Әтисе – Юныс, әнисе Мөслимә исемле. Башкортостанның Учалы районы Кунакбай авылында туып-үскән малай. Дөрес, бу турыда без соңрак, архивларга юл ачылгач кына белдек. Башкортостанның танылган журналисты, эзтабар язучы Рәүф Насыйров Александр Матросовка багышлап тулы бер хезмәт эшләде. Шакирҗан Мөхәммәтҗанов 1934 елда, унбер яшендә, туган авылын ташлап чыгып китә. (Әнисе үлә, әтисе икенче хатынга өйләнә. Ашау-

Фотолар Шаһинур Мостафинның шәхси архивыннан алынды

эчү ягы бик такыр була). Балалар йортларында тәрбияләнгән бала, үтә фәкыйрьлектә яшәгән туган авылына кире кайтаруларыннан куркып, үзе теләп Саша Матросовка әйләнә...

Армия генералы, хәрби һәм тарих фәннәре докторы, РФ Хәрби Фәннәр академиясе президенты Мәхмүт Гәрәевнең аңлатмасында («Татары. Воины. Труженики. Патриоты.» дигән китапның кереш өлешендә) мондый юллар бар: «Александр Матросов (Шакир Мухаметзянов) – сын татарского народа. Его легендарный подвиг во время войны повторило много бойцов. Среди них более десятка воинов татар: Газинур Гафиятуллин, Бари Шавалеев, Абдулла Салимов... Многие из них не удостоены никаких наград...»

Унтугыз яшьлек Александр Матросовның геройлыгы турында бик күп газета-журналлар болай дип яза: «1943 елның февралендә, Калинин фронтында, 91нче укчы бригаданың 2 нче аерым батальоны рядовое Александр Матросов дошман амбразурасын күкрәге белән каплады. Шул рәвешле ул үз гомере бәрабәренә дистәләрчә солдатның гомерен саклап калды».

Әлеге батырлык үрнәге яшь солдатларга бер стимул булган. СССР Югары Советы Президиумының 1943 елның 19 июнендә игълан ителгән Указы нигезендә, Александр Матросовка Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Ә ул хезмәт иткән укчы бригада исә 56 нчы гвардияче укчы дивизия карамагындагы Александр Матросов исемендәге 254 нче гвардияче укчы полк итеп үзгәртелә. Һәм шул көннән башлап сугышчылар арасында аерым бер термин барлыкка килә – «матросовчылар».

– Шаһинур абый, Александр Матросовка кадәр үк дошман утын күкрәге белән каплаган солдатлар булган. Тик аларның исемнәрен мәңгеләштерүне кайгыртучы булмаган. Без аларны шуңа да белмибез бит. Ничек халыкка аларның да исемнәрен җиткерергә?

– Әйе, булган. Ни өчен нәкъ менә Александр Матросов исеме мәңгеләштерелгән? Җавап гади – кызу сугыш барганда башкалар тиңләшердәй каһарман кирәк булган. Шул гына...

Архивларда кат-кат эшләвебез нәтиҗәсендә безгә Бөек Ватан сугышында дошман утын күкрәге белән каплаган 478 каһарманның исем-фамилиясе мәгълүм булды. Шуларның 250 гә якыны утыз яшькә дә җитмәгән. Матросовчылар исемлегенә элеккеге СССР территориясендә яшәгән барлык милләт вәкилләре дә кергән. Араларында ике хатын-кыз – Николай Гастелло исемендәге партизан отряды разведчигы Римма Шершнева, медицина хезмәте кече лейтенанты Нина Бобылева да бар.

Амбразурага ташланган иң беренче сугышчы – танкист Александр Панкратов булган. Ул 1917 елгы, тумышы белән Вологдадан. 1941 елның 24 августында Новгород янындагы Спас-Нередица торак пунктында хәрби машинасы сафтан чыккач, Александр дошман утын күкрәге белән каплый. Бу батырлыгы өчен аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Легендар политрук турында 1941 елның 20 ноябрендә «Правда» газетасында саллы гына язма да чыга.



Гомумән алганда, 1941 елда ун сугышчы дошман утын күкрәге белән каплый. 1942 елда бу сан – 44кә, 1943 елда 107 гә җитә. 1944 елда шундый ук батырлык күрсәтүчеләрнең саны 200дән артып китә. 1945 елда бу сан 74 сугышчыга кадәр җитә. Һәрхәлдә, без тапканнары. Тик Панкратов, Матросов, Гафиятуллин кебек батырларның тагын да күбрәк булганлыгына шигем юк. Моның өчен архивларда янә бик күп айлар утырырга, эзләнергә кирәк.

Советлар Союзы Герое Александр Матросов (Шакирҗан Мөхәммәтҗанов).

– Бөек Ватан сугышы каһарманнарын эзләүче бер сез генә түгелдер. Алар тапкан материаллар, фактлар сезнеке белән туры киләме?

– Әйе, эзтабарлар бик күп. Аларның һәркайсының эшләре белән танышып бару бик үк мөмкин дә түгел. Ләкин белгән хәтлесен әйтә алам: туры килә. Архив материаллары бер бит. Мисал өчен, күренекле эзтабар, публицист Эдуард Поляновский «Известия» газетасының 1997 елның 29 гыйнвары санында болай дип язган иде: «С полковником в отставке Александром Петровичем Коваленко я познакомился в Подольском архиве. Он собирал данные о матросовцах. Работа огромная, факты интересные. Матросовцев за войну набралось 470 человек. Из них 9 человек, закрывших грудью амбразуру, остались живы... 83 человека до подвига Матросова стали матросовцами».

– Шаһинур абый, безгә мәктәптә укыганда: «Бөек Ватан сугышында татарлар үзләрен чын батырларча тоткан», – дип сөйлиләр иде. Советлар Союзы Маршалы Родион Малиновский да: «Бу бөек көрәштә татар халкы үзенең сугышта чыдам һәм батыр йөрәкле солдатлары белән бөтен армиябез каршында хөрмәт казанды», –

Әхмәтсафа Мостафинның Шаһинурына изге васыяте шундый: «Билгесез батырларны эзләвеңне киләчәктә дә дәвам ит, улым!» 1981 елның июле.

дип язган. Бу чынлап та шулай булганмы?

– Бөек Ватан сугышында татарларның батырлыгы турында аерым тарих, легендалар йөргән. Советлар Союзы Маршалы Леонид Говоров: «Татар солдатларының сугышчан әзерлекләре иң югары бәягә лаеклы. Алар сугыш кырларында татар халкының иң яхшы сыйфатларын – Ватанга чиксез бирелгәнлек, дошманга аяусыз нәфрәт, җиңү бәрабәренә үлемнән курыкмау, батырлык, теләсә нинди шартларга да түзү сыйфатларын гәүдәләндерәләр. Татар сугышчылары Совет Ватаны алдындагы хәрби бурычларын намус белән үтиләр...» – дип язып калдырган. Немец ефрейторы Рудольф Вольтанг үзенең якыннарына юллаган хатында болай дигән: «Монда безгә каршы бик күп татарлар сугыша. Мин татар белән хәтта төшемдә дә очрашырга теләмәс идем...» («Батырлар» китабы», Казан, Татгосиздат, 1945, 26 бит).

Татар каһарманнары сугышның иң хәтәр урыннарында булган. Шунысы да мәгълүм: немец танкларын һәм самолетларын юк итүдә милләттәшләребез зур батырлыклар күрсәткән. Сугышның хәлиткеч операцияләрендә дә татар хәрби командирлары күпләп катнашкан, немец генералларының да байтагын безнең милләттәшләр әсир итеп алган.

Россия Оборона министрлыгының Үзәк архивына чираттагы баруымда «Гриф секретности снят» дигән китап белән таныштым. 1993 елда Мәскәүдә, «Воениздат» нәшриятында генерал-полковник, хәрби фәннәр кандидаты Григорий Кривошеев җитәкчелегендә чыккан әлегә басмада СССР Кораллы көчләренең сугыш елларындагы югалтулары турында тәфсилләп язылган. Куркыныч саннар: сугышның һәр тәүлегендә уртача 20 мең 869 кешенең гомере өзелгән.

– Татар язучылары, галимнәре арасында сугыш темасын ныклап өйрәнгән, архивларда утырган шәхесләр шактый булган. Сез аларның берәрсен үзегезнең укытучыгыз дип әйтә аласызмы?

– Өч кеше – Самат Шакир, Шамил Рәкыйпов, Рафаэль Мостафинны әйтә алам. Иң башта мине бу эшкә Шамил Рәкыйпов рухландырды. Аннан күреп экспедицияләргә чыктым. Архив документлары белән эшләргә өйрәндем...

– ТР Язучылар берлеге каршында «Хәтер яктысы» дип аталган эзләнү экспедициясе эшли. Сез шуның җитәкчесе. Әлеге үзәк турында сөйләгез әле: кайчан оешты? Анда кемнәр керә?

– Үзәкне 1983 елда оештырдык. Аны башта Шамил Рәкыйпов җитәкләде. Шамил абый, мәрхүм булыр алдыннан, бу өлкәдә эшне алып баруны миңа йөкләде. Безгә сугыш булган бик күп урыннарда – Балтыйк буе һәм Кавказ республикаларында, Украинада, Брянск, Волгоград, Орел, Ленинград, Мәскәү, Псков өлкәләрендә, Карелиядә, Германия, Польшада булырга туры килде. Ел саен җәен бер айлык экспедицияләргә чыгып китә идек. Кая гына барсак та, бөтен җирдә яхшы мөгамәлә күрсәттеләр. Каткат шуңа инанабыз: татарларны бөтен җирдә хөрмәт итәләр. Безнең солдатлар турында бик якты фикерләр ишетәсең.

Бүген дә әлеге юнәлештә эшлим. Иртәнге дүртләргә кадәр утырам. Архив материаллары бик күп, шуларны өйрәнәм, чагыштырам. «Неизвестные герои Великой Победы», «Үлмәс моң варислары» дигән яңа ике китап бастырырмын, дип ниятләп торам. Соңгы елларда сырхауханә юлларын еш таптарга туры килде, Казандагы онкология үзәгендә кат-кат дәваландым... Әмма шул китаплар, өйрәнәсе документлар яшәргә көч бирә. Булмышым белән – оптимист мин!..

«Инде менә ничәнче тәүлек йокысызлыктан җәфа чигәм. Бүген дә шулай. Аптырагач, торып, кунакханәдә үзем тукталган бүлмәнең тәрәзә капкачларын киереп ачып җибәрдем. Сызылып май таң атып килә. Тәрәзәм каршындагы зур бакчада – Россия Оборона министрлыгының Үзәк архивы урнашкан урында – үзәкләрне өзеп-өзеп сандугачлар сайрый...

Һай, телләрен-уйларын белсәң иде шул җырчы кошларның... Ә инде йокысызлыктан интегүемә килсәк, аның сәбәбе бер – архивта эзләнүләргә багышланган киеренке һәр көн нинди дә булса тетрәнгеч тарихи вакыйгалар, сискәндергеч фактлар белән очраштыра, шул дәһшәтле чорларга өермәдәй-ташкындай бөтерелеп алып кереп китә, йокы-ялны, ашау-эчүне, бар дөньяны оныттыра. Әйе, дары исе сеңгән, чит-читләрен ялкын өткән, канга манчылган ул документлар җанга һич тә тынгылык бирмиләр. Күпме каһарманнар, үзләренә «икенче гомер» бүләк иткәнне көтеп, архив киштәләрендәге калын томнар аша сүзсез генә безгә карап торалар. Әрнү дә, өмет тә чагыла кебек аларның карашларында...»

Шаһинур Мостафинның «Батырлык кайтавазы» китабыннан. (Казан, ТКН, 2018)

Бөек Ватан сугышы темасы безнең өчен мәңгелек, чөнки Җиңү бик авыр югалтулар бәрабәренә килде. Ул дәһшәтле көннәр әдәби әсәрләрдә дә зур чагылыш тапты. Бу турыда сугышны үзе күргән, аның ачысын-төчесен үз җилкәсендә татыган кешеләрдән дә дөресрәк итеп язучы булмастыр. Танылган татар язучысы Мөхәммәт Мәһдиев тә «Без – кырык беренче ел балалары» әсәрендә үзенә генә хас моңсу, йомшак юморы белән, сөеп-яратып яшьтәшләре – колхоз кырыннан укытучылар мәктәбенә килеп утырган ярымач егет һәм кызлар турында сөйли. Әсәр бик популяр булса да, без аны журналыбызда кыскартып бирергә уйладык: укыганнар тагын бер кат исләренә төшерсеннәр, таныш булмаганнар үзләре өчен яңалык ачсыннар. Әсәрдә сурәтләнгән вакыйгалар – тарихыбызның бер өлеше, бу турында без һичшиксез белергә тиешбез.



МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ

БЕЗ – КЫРЫК БЕРЕНЧЕ ЕЛ БАЛАЛАРЫ

(КИТАПТАН ӨЗЕК)

МЕНӘ ДИГӘН БЕР МАЙОР...

Бүрек, чабата тузаны аркылы коридордагы кояш нурлары көлтә-көлтә булып сузылган иде. Менә дөньяның рәхәте кайда икән! Әле кичә генә без колхоз басуларында көлтә кертә, бәрәңге ташый идек. Үгезне туарып тәртә ара-сыннан этеп чыгарганга әле тәүлек тә тулмаган. Тырнак төпләрендәге дегет, оекбаштагы арпа кылчыклары, бирчәйгән уч төпләре–кичәге тормышның истәлеге әнә шулар. Миләр катып калган, аларны кыймылдатмаганга өч-дүрт ай. Миләрдә ике-өч кенә тирән сыр бар. Анын берсе – сугыш, канкойгыч сугыш турында. Фронтка икмәк кирәк. Без, атасыз калган малайлар, әнә шул икмәкне кырдан җыеп заготзерноға озатырга тиешбез. Без инде дүрт җәй шулай эшлибез. Мидә икенче сыр – ашау турында. Кайда гына, кайчан гына авызга кабарлык нәрсә булса, без аны кабарга, йотарга тиешбез. Ә йотарлык әйбер һәр җирдә бар. Көлтә йөгендә утырып кайтасың – бодай башы уып ашыйсың. Урман буенда күшә, су буенда кыр суганы, җир җиләге очрый. Амбар тирәсеннән узганда кесәгә борчак тутырып китәсең. Алабута, кычыткан, чөгендер, яшь бәрәңге яфрагы – болары ашка китә. Табигать бай – үз баласын ул ничек тә саклый. Мидә өченче сыр… Өченчесе – юк. Кичә юк иде…

Бүген беренче октябрь – сугышның дүртенче көзе. Без, аркага капчыкларыбызны асып, кемнеңдер теләге буенча, укырга килдек. Үгезләрдән, дегет, камыл исеннән, күксел урманнардан, зәңгәр түтенле, көйгән бәрәңге исе килеп торган басулардан безне кем аерды? Ник аердылар? Моны беребез дә белми.

Җәй буе борчак, яңа бәрәңге, әвендә киптерелгән, тәтеп тәме сеңгән яңа арыш умачы ашап, капчык күтәреп тән ныгып беткән – бүген әнә шул көчне кая куярга белгән юк. Кичә кичен генә мунча кергәнне сылтау итеп, битен дә юмаган 15–16 яшьлек малайлар бүген училище коридорында колхоз тузанын кагалар. Менә коридорның бу почмагында Түбән Кенә малайлары. Барысы да чиста ыштырдан, яңа чабатадан. Менә зәңгәр сырмалар кигән Карадуган малайлары – һәммәсе кишер ашый. Мөрәле малайлары кесәләрен әйләндереп бер төрерлек тәмәке эзлиләр, шул арада ду килеп бәргәләшеп алалар. Чабыш атлары кебек барысының да борын тишекләре киңәйгән. Беренче кыңгырау чылтыраса да, класска керергә уйлап та караган кеше юк.

Кинәт өлкән курс малайларыннан берәү:

– Завуч! – дигән бер генә сүз кычкырды да класска кереп юк булды. Коридор буйлап электр тогы узгандай булды, һәм без туң миләребезне кыймылдатып өлгергәнче, тузан болыты эченнән күзлекнең ялтыравыклы ике пыяласы күренде. Миләр кыймылдады. «Әһә, шул ике пыяла – завуч икән»,– дип уйлап алдык. Ике пыяла безне гипнозлагандай итте. Аяклар класска өстерәделәр. Коточкыч тынлык урнашты. Мин класска күз төшердем. Бүреген салырга акылы җиткән Мөрәле малайларының чәч төпләренә хәтле кызарган, башларыннан пар күтәрелә. Нәкъ шул секундта ишек ачылып, аннан ике түгәрәк пыяла күренде. Миләр кызу-кызу эшләделәр. Нигә алай? Нәрсә, безнең кеше күргәнебез юкмы әллә? Безме? Без бит фронтка икмәк җитештергән мала…

– Шапки снять!

Тәрәзә пыялалары зыңгылдап алды. Кемнеңдер парта астындагы сөт салган чирек литрлы шешәсе идәнгә тәгәрәде.

Завуч – рус теле укытучысы икән.

Тынлык урнашты. Тәрәзәдән еректагы сары басу күренә, аның күк белән тоташкан урынында тук кибәннәр өем-өем булып утыралар, биектә-биектә тилгәнме, ниндидер кош тирбәлә. Күк йөзе зәп-зәңгәр. Көлтә йөге өстендә үгез көенә баруы никадәр рәхәт иде! Ә монда кыймылдарга да шикләнеп торасың… Күзлекле кеше кесәсеннән саплы зур тарак алып озын чәчләрен рәтләде. Аннан, күзлеген салып, аны ап-ак кульяулык белән озаклап сөртте. Күзлеген салгач, бу кеше бөтенләй хәтәр булып тоелды. Гел йөгән белән күреп ияләнгән ат янына йөгәнен салгач барырга куркасың. Ул әллә нинди талый торган ат күк тоела…

– Мин сезгә рус теле укытырмын, ребятки,–дип, күзлекле сүз башлады.– Мин бүгенгә сезнең белән татарча сөйләшәм. Ләкин без акрынлап дәрестә русча сөйләшүгә күчәрбез…

Һи-и, безнең өчен бу яңалык түгел! Без моны инде бишенче класстан бирле ишетеп киләбез. Барыбер бернәрсә дә чыкмаячак. Әле бик әллә кем булып кылансаң, үзеңне сугышка да алып куярлар. Гәүдәң бик төз, тавышың таза күренә. Менә дигән бер майор чыгар үзеңнән…

– Миңа алтмыш яшь,– дип дәвам итте күзлекле калын, көр тавыш белән, классның нәрсә уйлаганын сизгәндәй.– Минем сезне культуралы, белемле кешеләр итеп күрәсем килә. Укып бетергәнче миндә рус теле өйрәнсәгез – үкенмәссез. Мин үзем Мәскәү татары. Поездларда йөргәндә сезнең як халкының рус сүзләрен сытып сөйләшүенә минем йөрәгем әрни. «Брач барение белән чәй эчә» дип сөйләгәннәрен ишеткәндә, мин бөгелеп төшәм, оялуымнан кая керергә белмим. Беренче дәресне без шуңа күрә бик җиңел бер эштән башларбыз. Сез миңа ике баганага бишәр сүз язгыгыз. Беренче баганага «б» авазына, икенче баганага «в» авазына башланган сүзләр булсын. Мин шул сүзләрдән чыгып кемнең кем икәнен үзем чамалармын…

Борыннар тартылды, каләмнәр кыштырдый башлады. «Җиңел» генә дигән эш шактый авыр булып чыкты. Парта араларыннан кайнар һава күтәрелгәндәй булды, кемнеңдер каләме сынды, берәүнең карасы түгелеп, кемнеңдер чалбарын буяды, кайсыдыр язуын бозды…

Зур газаплар белән унар сүз язылып бетте. Күзлекле парта араларында йөри башлады. Ул, һәр кешенең дәфтәрен алып, күз йөртеп чыга, һәр дәфтәрнең үзенә аерым чырае. Бертөрле дәфтәрне алгач, «әһә-әһә» дип тиз генә карап ала да:

– Кайсы мәктәптән? Укытучың кем иде? – дип сорый. Кайбер дәфтәрне почмагыннан чеметеп җирәнеп кенә кулына ала, авызы кыйшаеп китә, йөзе чытыла. Үзе бер сүз дә дәшми, теге малай да моның чытык йөзе астында кып-кызыл булып утыра, башын аска ия…

– Фамилия?

Тәрәзә пыяласы тагын зыңгылдап алды. Тез башлары ямаулы күксел чалбар кигән Мөрәле малае үлем җәзасы алган кешедәй башын түбән иде, партаны шыгырдатып басты. Ун минут элек кенә бу малай коридорда бөтенебезне чалып егып, изеп йөргән иде.

– Зарифуллин,– диде ул, ияген бишмәт якасына яшереп. Күзлекле исә башкача бер сорау да бирмәде. Ул Зарифуллинның пычранган дәфтәрен парта өстенә төшереп җибәрде. Аннан кесәсеннән дүрткә бөкләгән ап-ак кулъяулык алды да бармак очларын сөртте. Моны ул шулкадәр чынлап эшләде, бу вакытта бөтен классның күзе шунда гына булды. Әйтерсең Зарифуллинның дәфтәр битендә микроблар өелеп яталар, әйтерсең ул микроблар күзлеклeнең кулына да үрмәлиләр. Бу микроблар керсә, кешене чирләтәчәк икән…

Ә күзлекле озак итеп бармак башларын сөртте…

…Мәскәү татары шулай итеп бу дәрестә безне җиңде. Ормады, сукмады, хәтта бер генә тапкыр ачулы сүз дә әйтмәде, шулай да җиңде.

Без авыл мәктәбендә иркенлектән тулысы белән файдаланган идек. Ир укытучылар юк, хатын-кызлар гына… Укытучылар да безнең кебек үк ачлар, утыннары юк. «Бәлки, безне дә сугышка алырлар әле» дип җибәрергә дә күп сорамый идек. Шунлыктан күбебез тәмәке тарта, телләгән дәресенә керә, теләмәгәненнән кайтып китә ала иде. Әнә шундый иркенлектән соң, Мәскәү татарының безнең өстән ниндидер власть урнаштыруына, әлбәттә, риза булмадык. Тәнәфескә чыккач әле тел шомартып маташтык.

– Һи-и, исегез киткән икән, мондыйларны гына бөккән бар инде!

– Ә бездә, ә бездә… Моннан да усал иде химиядән укытты берәү. Рогаткадан «шалт» тегенең күзлегенә бер малай. Шуннан сон майлагандай булды…

– Ә безнең авылда… Ә безнең авылда…

Малайлар шаулаштылар, ләкин барысы да моның болай гына, бүрәнә артыннан бүре куу гына икәнен беләләр иде. Моны Зарифуллин да бик яхшы аңлаган иде. Ул, сүзгә катнашмыйча гына, горизонттагы кибәннәргә таба карап, тәрәзә янында тора иде…

АТА КАРА ТАРАКАННЫҢ КАН ӘЙЛӘНЕШЕ

Әркәшә Пермяков – рус малае. Анын чиркәү кушкан исеме Аркадий булгандыр инде. Ләкин туганнан бирле татар авылында яшәгәнлектән, ул Әркәшәгә әйләнгән дә беткән. Хәер, башка яктан да ул нәкъ безнең кебек: русча бер авыз сүз белми – чөнки әти-әнисе гомер буе татар авылында яшәгәнлектән, гел татарча гына сөйләшәләр. Киеме дә татарча: өсте брезент тышлы бишмәт, аягында олтанлы манган итек. Бөтен булган аермасы фамилиясендә һәм… су коенганда гына күренә.

Аның әтисе авылда ветеринар булып эшли. Халыкта ветеринар дигән сүз юк, «ат врачы» дигән сүз генә бар. Аксап йөргән кәҗәңне дәвалаcа да, бозаулый алмый яткан сыерыңны бозаулатса да, Пермяковның исеме гел «ат врачы» булып калды. Җиденчене бетергәч, Әркәшә дә ат врачлыгына укырга китә икән дип сөйләгәннәр иде, ләкин укытучы булуны артыграк күргән, ахрысы, безнең белән училищега килде. Наданлыгы бер дә безнекеннән ким түгел иде, ләкин рус грамматикасы дәресендә кинәт кенә дәрәҗәсе күтәрелде.

Икенче дәрестә без инде ия белән хәбәр табу, җөмлә турында кагыйдә әйтү кебек эчпошыргыч эшләр булыр дип тора идек. Бөтенләй башкача булып чыкты.

– Сез – колхозчы крестьян малайлары,– дип сүзен башлады Мәскәү татары,– һәм киләчәктә дә күбегез авыл балаларын укытыр. Менә без авыл халкы өчен кирәк булган кайбер сүзләр белән танышыйк әле. Исегездә тотыгыз, мин яздырачак сүзләрнең бик күбесен руслар үзләре дә белми. Бигрәк тә шәһәрдә яшәгәннәре. Йә, сезнең татарда кызыл ат буламы?

Безнең өчен бу сорау – сорау да түгел.

– Кызыл туры,– дип кычкырабыз.

– Ә сары ат?

– Була!

– Кара ат!

– Кара туры!

– Менә хәзер шуларны русча әйтегез.

Без тынып калдык. Мөрәле малае Әлтафи миңа борылып пышылдап кына болай диде:

– Чукынды, малай, монда ат печүчеләр әзерлиләр икән, укытучылар түгел.

Ләкин мин аңа җавап бирергә өлгермәдем. Укытучы безне яңа сораулар белән күмде:

– Ә атның бәкәле русча ничек булыр? Ә бәкәл өстендәге ялы ничек? Ә? Менә монысын руслардан да бик сирәк кеше белә.

Әркәшә әнә шул дәрестә танылды. Ул бер-ике сорауга дөрес җавап бирә алды. Мәскәү татары аны мактап: «Май чүлмәгенең тышыннан билгеле»,– диде. Без, борыннарыбызны тарта-тарта, тактадан күчереп яздык һәм гаҗәпкә калдык: баксаң, ике атның төсе бер үк төрле булып та, ялы, койрыгы икенче төрле булса, рус телендә икесенә дә аерым исем бар икән. Дәрестә татарча да шактый мәгълүмат алдык. Ат төсе без уйлаганча ике-өч төрле генә булмый икән. Аның коласы да, җиранә дә, алмачуары да, бурлысы да була икән! Каян белеп бетергән боларны Мәскәү кешесе? Әйтерсең ат врачы булып эшләгән. Әллә, югыйсә, чыннан да ат врачымы икән? Бу сугыш вакытында кемнәр генә кем булып йөрми. Әнә, лесхоздагы почта начальнигы, алтмыш биш яшьлек Иван Георгиевич безгә рәсем дәресеннән керә. Училищеның хуҗалык мөдире Исмәгыйль агай безгә зоология дә укыта бит әле!

…Рус теле дәресендә дәрәҗәсе күтәрелеп киткән Әркәшә бер көн эчендә ике фәннән харап булды.Берсе, әлеге дә баягы, рәсем дәресендә.

Иван Георгиевич бу җирләрдә беренче земский больницалар, телеграф бүлекләре ачылганда ук дөньяга килгән кеше икән. (Ул беренче дәрестә үк безгә мондагы алпавыт утарының тарихын, беренче больница, беренче телеграф бүлегенең ничек ачылуын сөйләде.) Үзе революциягә кадәр гимназия белеме алган, аннан ниндидер институтта укып элемтәче булып киткән. Әтисе потомственный дворянин булган икән. Моны ишетүгә, безнең колаклар торды. Әлтафи моңа һич тә риза булмыйча, бөтен класска ишетелерлек итеп татарча:

– Череп таркалган сыйныф, – диде.

Әркәшә дә моңа кушылып:

– Алайса, безде алпавыт калдыгы укыта икәд,– дип куйды.

(Әркәшәнең һәрвакыт борыны тыгылган була иде һәм ул бервакытта да борын авазларын әйтеп мәшәкатьләнмәде.)

Ләкин алпавыт калдыгы безне ормады-сукмады, ә кемнең нәрсәгә сәләтле икәнлеген белү өчен өстәл өстенә тумбочка утыр-

тып куйды да шуны кәгазьгә төшерергә кушты. Йа хода! Кемнәрдән нәрсәләр генә чыкмады! Ну, тапты эш бу картлач үзе дә! Ирекле рәсем дисен иде ул хет! Менә, ичмасам, авыл мәктәбендә укытучылар безгә шулай дип кенә әйтәләр иде. Кем әтәч, кем куян, кем яфрак ясый иде.

Тумбочканы әмәл-чөмел китергәч, Иван Георгиевич, нәкъ безнең теләкне белгәндәй, ирекле рәсем ясарга кушты. Әркәшә әнә нәкъ шул ирекле рәсем белән харап булды.

...Дәрес бара, һәркем кыштыр-кыштыр килеп нәрсәдер эшли, артка борыла, кемнәндер нәрсәдер сорап ала, мышкылдый. Берәүләр ясаган рәсемнәрен резинка белән выжылдатып уалар, икенчеләре сугышка кадәр үк алынган буяу карандашының калдыгын тел очына тиерә-тиерә буйыйлар.

...Иван Георгиевич һәркемгә ниндидер бер киңәш бирә, җылы сүз әйтә.

– Менә сезнең яфрагыгыз сабагына караганда бик кечкенә чыккан,– дип телен шартлатып куя...

– Ә менә сезнең әтәчегез бик әйбәт. Тик нигә аның шпорлары юк? Ә? Сезнең авылда әллә әтәчләр шпорсызмы?

– Яхшы, бик яхшы. Сездән киләчәктә менә дигән рәссам чыгарга мөмкин. Тик шунысы бар: куянның бервакытта да колагы яшел булганы юк.

Кинәт Иван Георгиевич «ээ» иткән тавыш чыгарды. Карасак – аның кулында Әркәшә дәфтәре. Рәсем укытучысының куллары дерелди, икегә бүленгән мыегының очлары берсе аска төшә, икенчесе өскә күтәрелә сыман тоелдылар...

– Сез... Сез...– Ул, кулъяулыгын чыгарып, ютәлләргә керешге.– Сез нәрсә эшлисез, ә? Йә, басып сөйләгез әле. Бу нинди натурализм? Сезгә ничек...– ул ютәләнә буылды.– Сезгә ничек оят түгел? Сез нинди бәләкәй хулиган? Совет мәктәбе эчендә сез нәрсә эшлисез?

Карт кыштыр-кыштыр атлап өстәле янына китте. Калтыранган куллары белән журналда Әркәшәгә икеле куйды. Аннан рәсем дәфтәренең битен ертып алды да, йомарлап, мич артындагы утыннар арасына ыргытты. Натуралист Әркәшә кып-кызыл булып түбән карап утырды. Ахырдан гына билгеле булды: ул айгыр рәсеме ясаганда бераз чаманы югалтып җибәргән икән.

Иван Георгиевич исә дәрес беткәнче ютәлләде.

Бәхетең бер йомарланмасын... Аннары бетте диген. Рәсем дәресендәге вакыйгадан айнып та җитмәдек, зоология дәресендә тагын Әркәшәне бастырып куйдылар.

Укытучы керер алдыннан гына, Әркәшә сөйләнеп утырган иде:

– Мин үзем бернәрсә дә белмим, ничек кенә сөйләрмен инде.

Шулай диеп әйтеп кенә бетерде...

– Узган дәрестә,– диде юан корсаклы хуҗалык мөдире урыныннан торып,– без ата кара тараканның кан әйләнешен өйрәндек.

Ул авызын зур итеп ачып бер иснәде. Ахырында бераз гына үкереп авызын япты.

– Пермяков,– диде ул журналга карамыйча гына,– узган дәрес материалын бик һәйбәтләп безгә сөйләп бир. Ә сез тыңлап утырыгыз.

...Мәет тә мәет, Әркәшә дә мәет. Ябык муенына утыртылган, бераз гына шакмакка охшаган башын бик нык иеп акрын гына басты. Җиденче класстан килгән гадәт буенча, ачык китабын алдагы иптәшенең аркасына сөяп куйды да сөйләмәкче булды. Ләкин җөмләнең беренчесен һич кенә дә ерып чыга алмады.

– Ата кара тараканның кан әйләнеше... Кан әйләнеше... гаять... гаять...

– Йә, йә,– диде укытучы сәгатен озак итеп куенына сала-сала.– Йә, шуннан...– Әркәшәнең, каушаудан, борыны тыгылды...

Ата кара тараккаттык... Кара ата тараккаттык... гаять гаять...

Ах, бу «гаять»не! Ну язалар инде китап авторлары да, ач калгырлары!

– Кара тараканның кан әйләнеше гаять... гаять...

«Гаять» – Әркәшә өчен капкын булып чыкты. Күпме генә тыпырчынмасын, ул аннан ычкына алмады. Биология укытучысы авызын зур итеп ачып күңелсез генә тагын бер иснәде дә Әркәшәгә икеле куйды.

– Син, пнимаешь, оятсыз, тик ятып ашарга килгәнсең,– дип сүгеп тә алды.– Укымыйсың, пнимаешь, икеле аласың. Менә мин синең ипи карточкаңны тоттырып калдыртыйм әле, булгахтырга әйтеп... Ата кара тараканның кан әйләнешен белмәгән көе кая бармакчы буласың син, ә? Оятсыз син, пнимаешь, актык сүз шул сиңа...

Әркәшә киселгән арыш башагыдай партага ауды. Капланып ятты. Ипи карточкасы... Ник аңа тия бу завхоз, ә? Әркәшәләрнең өйдә сигез бала. Әтисе берүзе эшли. Колагы чукрак булу аркасында, сугышка алмадылар. Башкаларга тигән льготалар аларга тими. Колхоздан аванска алган икмәк өстән чыгып бара. Гаиләдә иң олы бала булган Әркәшә авансны биология дәфтәренең соңгы битенә үзе язып бара. Менә дәфтәрнең ул бите әле дә ачык. «Колхоздан ашарга алынган. 1944 елда» дип язып та куелган. Әркәшә вак яза, пөхтә яза. Хәрефләрне авыштыруны бер дә яратмый, һәр хәрефен туры гына итеп утыртып куя. Үзе өчен язганда хәрефләрне ул тары бөртеге кадәр зурлыкта гына яза. Дәфтәр битеннән туп-туры бер багана төшеп киткән.

12 кг арш
8 кг арш
12 кг арш
14 кг арш

Бу багана бик биек. Ләкин ни өчен «арыш» дигәндә бер хәрефне төшереп калдыра ул? Әркәшәне белмәссең, ул йомык күңелле малай...

Ата кара тараканның кан әйләнеше яңадан бөтен классның тамак төбенә төер булып утырды. Ну, бу ата кара тараканны! Кансыз гына яшәсә булмаганмы соң аңа, кансыз бөҗәкләр бит әнә дачурта!

«Эһ» иткән тавыш юк. Кабер тынлыгы. Завхоз сәгатен алырга куенына кереп бара. Чыннан да, сәгатьне бик озаклап ала. Әлтафи сүзе дөрес булыр. Ләкин бу хәл ата кара тараканнан коткармаячак. Кара таракан – котылгысыз. Тагын кем генә харап бу...

– Абый, Исмәгыйль абый,– дип урыныннан торды Әлтафи кинәт кенә.– Безнең бит кичә бәрәңге җирендә чиләкләр калды.

Класс өстеннән ниндидер җиңел һава дулкыны узды. Күзләр ниндидер өмет белән Әлтафига текәлделәр. Хәзер нәрсә дә булса булыр... Тик тараканнан гына котылырга иде.

– Йә, йә, Хәлимов, нәрсә әйтмәкче буласың моның белән?

– Соң, абый, нәрсә әйтергә дип инде, шул: дәрес урынына әллә басуга гына барабызмы? Кайтышлый складка берәр чиләк бәрәңге күтәреп кайтырбыз.

Мең яшә, Әлтафи! Исмәгыйль агай куен кесәсенә тагын кереп китте. Әлтафи ыргыткан кармакка шул арада хәйләкәр, мут Баязитова җим киертте.

– Абый, имә, безнең класс малайлары тимер көрәкләрне кайрыйбыз дип әйтәләр. Көрәкләр бик үтмәсләнгән, кичә дә уч төпләре кабарып чыкты.

Зоология укытучысы шул секундта юк булды. Аның урынын хуҗалык мөдире алды. Класс җиңел сулап куйды.

– Бәрәңге алып кайтырга дисезме? Ашханәгә каграз бүген бәрәңге кирәк. Ә дәреснең ничә минуты калган соң? Ә кемнәр көрәк кайрый белә? Кулларыгызны күтәрегез әле. Яхшы. Бүген дәрестән соң складка килерсез.

Исмәгыйль агай нәрсәдер уйлагандай күзен йомып торды. Аннан кинәт кенә яктырып журналга тотынды.

– Тукта, без бит әле исемлек тикшермәгән.

Ул акрын гына исемлек тикшерә башлады. Күренеп тора, аңа нәрсә беләндер вакытны уздырырга кирәк. Исемлек тикшерү менә болайрак булды.

– Абдуллин?

– Мин!

– Әһә, Абдуллин бар. Аны бар дип куябыз. Ярый. Абдуллин, булды, билгеләдек. Баязитова?

– Мин!

– Әһә, Баязитова да бар. Ярар, аны да бар дип билгеләп куйыйк. Инде килеп, Зарифуллин? Ә? Әллә юкмы?

Беразга гына соңга калган Зарифуллин да торып басты.

– Ә, бармыни? Мин әллә юкмы дип торам. Шулай, бар дип билгелибез.

Безгә нәкъ менә шушы гына кирәк иде. Беребездә дә сәгать юк, шулай да, чама белән, чирек сәгать дәрес калгандыр Болай булса, эш начар түгел Исемлек әле зур. һәрхәлдә ата кара тараканга кабат кайтылмас… Җай гына барган эш. Әркәшәгә җиткәч, тагын тәртелде Әркәшә баягы ударлан әле дә айнып җитмәгән иде һәм укытучы аның фамилиясен әйткәндә, ул, әлбәттә, җавап бирерлек хәлдә түгел иде. Ләкин, йөз сум акчаң булганчы, йөз дусың булсын! «Пермяков» дигән сүз чыгуга, Әлтафи утырган җиреннән генә нәкъ Әркәшәнең үзе төсле әйтергә тырышып җавап бирде:

– Пид!

Барыбыз да шыпырт кына хихылдаштык Әлтафи, әлбәттә, тотылды. Әле генә бик эшлекле кыяфәттә бәрәңге алып кайтырга тәкъдим кертқән Әлтафи инде аягүрә бастырып куелган иде.

– Кешенең физик кимчелегеннән көләргә һич ярамый, Хәлимов,– диде биолог, куенына керә башлап. – Ярамый. Ул нинди шовинизм ул, пнимаешь? Шовинист булырга ярамый, шту син…

Ләкин никадәр генә каты әйтелмәсен, дәрес бетеп класстан чыкканда, Әлтафиның йөзендә ниндидер шатлык балкый иде. Ни дигән сүз ул шовинист? Шайтан белсен! Ләкин менә шул хикмәтле сүзне Әлтафига ябыштырып куйдылар бит әле!

Шулай горур кыяфәттә шовинист Әлтафи коридорга чыгып китте. Класста иң арткы партада натуралист Әркәшә генә ятып калды…

КОЛАЯМБУ ПЛАНТАЦИЯДӘ ЭШЛИ

Шулай да, бу уку дигәннәре…

Таш кисәр идек, укымас идек! Менә ташлыйм, менә качам дип йөри торгач, инде икенче чирек тә үтеп бара. Иң авыры, рус теле, дибез, Юк, алай түгел, иң авыры психология. Аты коргыры фән! Меланхолик, сангвиник, холерик, флегматик, имеш. Гыйззәтуллин– меланхолик, Әлтафи – флегматик, Зарифуллин – холерик, имеш. Юк, иң авыры, шулай да, немец теле. Үзе булсын ул бер дигән дошманыңның теле, шуны тагын өйрәнеп ят. Шуның өстенә укытучысы – нечкә аяклы, чандыр яңаклы, шүрәле бармагыдай нәзек озын бармаклы ир уртасы бер кеше. Уң кулындагы озын урта бармагын күзеңә терәгәндәй чукый-чукый белем бирә.

– Син ничә тел белсәң, шуның кадәр әйбәтрәк кеше буласың… фәлән-төгән,– дип йөрәкне боза.

– Син бөген бер икеле алдың, димәк, син Гитлер тегермәненә бер чүмеч су салдың. Син бер бишле алдың, димәк, син фашизмга удар ясадың.

Һәр сүзе – ярага тоз. Җитмәсә, татар сүзләрен дә үзенчә бозып сөйләп үзәккә үтә. «Бүген» дими, «бөген», «соңга калдың» дими, «сыңа калдың»… Шуңа һәр сүзе авыр, һәр җөмләсе баш миенә чүкеч белән суккан күк.

Әлтафи сөйли, имеш, мал суя торган җирдә сыерның капкадан килеп керүенә таза гына берәү авыр чүкеч белән тегенең нәкъ маңгай уртасына берне тондыра икән… Шуннан сыер үз аягы белән суючы янына барып гөрселдәп егыла икән. Аягын да бәйлисе юк, ди… Без дә нәкъ шулай… Гитлер тегермәнен әйтеп, дәреснең башында ук безнең мине параличлап куя да аннан безнең белән теләгәнчә кылана.

– Немец теле – бөек тел. Немец милләте дөньяга Гётене, Шиллерны, Бетховенны бирде. Немец халкы кешелек җәмгыятенә Марксны, Энгельсны, Бебельне, Либкнехтны бирде. Эрнст Тельман немец телендә сөйләшә…

Миләр кабара, баш шаулый…

– Немец телен Владимир Ильич Ленин бик яхшы белгән, Фридрих Энгельс сигездән артык тел белгән…

Йа хода, моннан соң ничек яшәрбез, бер генә чит тел белмибез бит! Шуны уйлагач, баш мие бөтенләй эшләүдән туктый. Ә сары күлмәкле чандыр ир тукуын дәвам итә:

– Без бөгенге көндә сезнең белән немец милләтенә каршы көрәшмибез. Без сезнең белән кешелек җәмгыятенең иң кабахәт адәм актыклары – фашистларга каршы көрәшәбез. Немец булу әле ул фашист булу дигән сүз түгел…

Чандыр кул уйный да уйный. Менә хәзер ул уйнаудан туктар, хәзер ул кемне дә булса бастырыр. Бу – бик коры кеше, моның белән шаярып булмый. Бу – белдергәнче укытачак. Каптык… Кем генә котыртты соң безне укырга… Нинди хәерсез сәгатьтә юлга чыгылды соң?

– Бөген без узган дәрестә өйрәнгән «Колаямбу» текстын кабатлыйбыз.

Тагын газап, тагын баш өстендә рәшә, күз алдында боҗралар. Әйе, әйе, бу текст хәтердә, бик хәтердә. Гомердә онытылырлык итмәдең узган дәрестә, һәр сүзен хор белән әйттереп җаныбызны каһәрләдең. «Нох айн маль, нох айн маль» дип җелегебезне суырдың. Янәсе, тагын бер мәртәбә, тагын бер мәртәбә. Менә монда бер сүз бар, дидең, анысы французча. «Плантаге» дип язылган, «план-тэжэ» дип укырга, дидең. Кат-кат кисәттең. Ул көнне Әлтафи хәтта авылына хат та язды. Имеш, немец телен без инде су урынына эчәбез, ну, шуның өстенә аз-маз француз телен дә өйрәнгәлибез…

Чираттагы корбан – Гыйззәтуллин.

…Класста калтыравыклы сыек кына тавыш ишетелә. Иҗек саен тәртелеп, чигенә-чигенә хут белән кисәк алдырып, Гыйззәтуллин укый. Бите кып-кызыл. Ышан син аңа, минем каным аз дип йөргән була тагын.

– Колаямбу арбәйтэтә… арбэй… арбайтете… ауф… ауф… эйнэр… айнэр план… планта…

Харап кына булмаса ярар иде бала! «Плантэжэ» кирәк, кеше буласың килсә, берүк хәтерлә, шулай укы. Юк, газап барысын да онытгырган…

– Айнэр планта… планта…

Чигерде. Бер хәл булыр. Хәзер кызулык белән чыгып киткәндә ни булса да булыр.

– Ауф айнэр плантаге ин Африкэ.

Нәкъ шул секундта класста кемдер төчкереп җибәрде, һәм «плантаге» шул тавышка күмелде. Бөтен класс берьюлы сулыш алды. Дөм бәхетсез түгел икәнсең, Гыйззәтуллин!

Ләкин… ләкин, күрәчәкне күрми гүргә кереп булмый, диләр. Гыйззәтуллин бу төчкерү аркасында әле үзенең нәрсәдән котылганын белми иде. Сары сатинлы гәүдә алгарак сузылды. Озын бармак класс өстенә таба очты.

– Нох айн маль!

Класс яңадан тораташ булып катты. Күрше бүлмәдәге пианинода җыр укытучысы уйный, ахрысы, нигәдер гел бер теленә басып бер үк тавышны бирә. Бу тавыш класстагы авыр тынлыкта «маль, маль, маль» булып ишетелә. Язмыштан узмыш юк. Нох айн маль икән, нох айн маль, чукынып китсен…

Бөтенләй сыекланган, кызлар тавышы белән Гыйззәтуллин теге җөмләгә тагын кереп батты. Әнә ул, маңгаена чүкеч белән сугылган сыер шикелле, суючы янына хәзер үзе бара:

– Колаямбу… янбу… ямбу… Колаямбу арбайтэтэ ауф айнэр…

Кара син дуңгызны, ничек шома бара!

– Ауф айнэр плантагэ ин Африкэ.

Классны коры яшен суккандай булды. Сары күлмәкленең зәһәр тавышы яңгырады. Озын бармак нәкъ Гыйззәтуллинның каш өстенә атылды.

– Плантагэмы, плантэжэмы?

Бу шулкадәр каты, шулкадәр кычкырып әйтелде ки, юк-барга ышануы белән дан тоткан Әлтафи хәтта култык асларын сыпырып алды.

Гыйззәтуллин теге коры яшен чатнаган вакытта авызын ачып калган иде, берничә секунд буена шуны яба алмыйча катып торды. Бите ап-ак булды. Ләкин сары күлмәкле – нигездә мәрхәмәтле кеше. Ул, Гыйззәтуллинның битенә кызыл таплар чыккач кына, яңадан дәште.

– Кабатла минем арттан,– диде.

Аның тавышы, һәр сүзе чырт-чырт итеп чатнап чыга иде. Физика кабинетында электр тогы ясый торган бер машина бар. Шуның аксыл тәгәрмәчен бик каты әйләндергәч, металл щеткалары чартчорт киләләр, һавага әллә нинди җиңел, төссез ис тарала. Моны, имеш, озон дип атыйлар. Сары күлмәк эчендәге юка гәүдәсен, озын бармагын селкетеп сөйләгәндә теге явыздан да шундый ток тарала. Чарт-чорт… Класска хәтта озон исе чыккандай була.

– Кабатла минем арттан: мин ялкау, игътибарсыз малай. Ну!

Беттек. Тагын бер чартнау… Гыйззәтуллин питон авызына үз ихтыяры белән кереп барган гипнозланган куян шикелле берни аңламыйча аның артыннан кабатлый:

– Мин ялкау, игътибарсыз малай.

– Минем дәрескә хәзерлексез килүем – бөген дошманга ярдәм итүем дигән сүз.

– Минем дәрескә хәзерлексез килүем – дошманга… дошманның… дошманнан ярдәм итүем дигән сүз.

Гыйззәтуллинның, күп яшәсә, ике-өч минутлык гомере калгандыр. Менә-менә бу кешенең каршында ул кисәк авып китәр. Тагын әйттермәсә генә ярар иде, харап була бит малай…

– Кабатла: мин бөген икеле алам.

– Мин бүген икеле алам…

– Шуның белән мин Гитлер тегерменәнә бер чүмеч су салам.

– Шуның белән мин… мин… Гитлер тегерменәнә… чүмечләп… бер чүмеч су салам.

Ну, нык кеше икән бу Гыйззәтуллин. Тәки бөтенесен әйтеп бара бит!

– Кабатла: ләкин мин алдагы дәрескә хәзерлек белән киләчәкмен. Тырышып укып, мин фашизмны җиңү көнен якынайтачакмын…

Гыйззәтуллин биреште. Тавышы теткәләнде, вак-вак кисәкләргә таркалды, берәзлексез борыныннан акты. «Якынайтачакмын» сүзен әйтеп бетерә алмыйча, кинәт кенә урталай сынып партага ауды.

Сары күлмәкле исә безгә бүтәнчә бәйләнмәде. Бераздан йомшак кына тавыш белән болай дип сөйләп китте:

– Суда еракка йөзгән кешедә билгеле бер урында шикләнү туа. «Ә шушында батсам?» дип куркып куя ул. Менә шул ноктаны узгач, кеше үзенең көченә ышана башлый һәм алга таба җиңелрәк бара. Сез дә хәзер менә шул ноктада. Ләкин без моны узарбыз. Әйе, узарбыз! – Аның тавышы тагын чартлый башлады.– Партия, хөкүмәт бездән укытучы кадрлар көтә. Институт студентлары бөген кулларына корал тотып фашизмга каршы көрәшәләр. Сезнең күбегез, ихтимал, җидееллык мәктәптә чит тел укытучысы булып эшләр. Партия, хөкүмәт мине бөгенге көндә фронтка җибәрмичә, сезне укытырга кушты. Мин үземнең сугышчан бурычымны ил алдында намус белән үтәргә тиеш. Сезнең яхшы укуыгызга ирешү – минем изге бурычым. Һәм мин моңа сезнең белән берлектә ирешәчәкмен! – Шулвакыт урта бармак безнең өскә атылды һәм тавыш чартлады.

– Һичшиксез, ирешәчәкмен!

…Дәрес бетте. Без авыр кайгы баскан кыяфәттә урыннарыбыздан тордык. Ул немец телен ничекләр итеп өйрәнербез? Ә бу үзенекен итми калмый инде. Моның хәтле көчәнүгә баш ничек чыдасын! Әнә ул Гыйззәтуллин кеше була алырмы инде?

Без, малайлар, класс бүлмәсендә калдык. Елмаерга тырыштык, булмады. Тәрәзә янына җыелышып күзләребезне еракка текәдек. Беркем бер сүз дәшмәде.

Шулвакыт класс ишегендә тагын сары күлмәкле күренде. Җиңенә кызыл бәйләгән, димәк, бүген ул дежур укытучы. Безгә карамыйча гына яны белән басып болай диде:

– Дежур укучы форточканы ача, парта өсләрен, тактаны сөртә. Калганнар барысы да коридорга чыгып җырлы уенга керәләр.

«Ача, керәләр…» Бу сүзләргә җиңел холыклы Зарифуллин бик гарьләнде.

– Әллә ачмый торгандыр! Әллә керми торгандыр! – дип, ишек ябылуга ул бик нык үртәләнде.

Кара син аны ә, каян килгән куәт бу кешедә! «Ачыгыз» дими, «уенга чыгыгыз» дими. Юк, үзен алай ваксытмый. Хәтта безгә карамый да бит. Ачалар, керәләр имеш.

Партадан башын күтәреп, иң беренче булып Гыйззәтуллин чыгып китте. Бичара! Мәктәптә җиде ел укып аның бер генә мәртәбә дә кызлар белән җырлы уен уйнаганы булмагандыр. Шулай, Гыйззәтуллин теге сары күлмәкле янына үз ихтыяры белән китте. Әлтафи исә бик батыр кыяфәттә гәзит кәгазеннән ясаган карталарын чыгарды. Безнең арада кечкенә генә ыгы-зыгы булып алды. Сүзне Зарифуллин башлады.

– Нәрсә, бу бигрәк тагын, мыскыл итәм дигәч тә!

– Ие! Кызлар белән түгәрәк уен уйнарга бигрәк тагы! Ничә ел колхозда эшләгән башың белән, оялмыйча!

– Һи, исегез киткән икән, уен уйнау мәҗбүри түгел. Чыкмыйм мин и вчу. Анысына билге куя алмый ул!

– Дөнья явызы ул, беләсең килсә. Белдеңме шуны? – Зарифуллин шул урында бүленеп калды. Чөнки ишектә сары сатин күренде.

– Зарифуллин, ни өчен уенда түгел?

Зарифуллин яланбаш тора иде, ниндидер аңсыз хәрәкәт ясап, башыннан бүрек эзләде. Ләкин бүрек парта астында икән.

– Абый, мин…

– Юк, син сорауга җавап бир: ни өчен син уенда түгел?

Зарифуллин шулай итеп бер сүз әйтә алмады. Ул бер читкә барып басты. Эшнең бик җитдилеген аңлаган Әлтафи карталарын җыеп тиз генә уенга таю ягын карады.

– Хәлимов, син кая барасың?

– Уенга барам, абый!

– Юк, тукта, урыныңда кал.

– Абый, мин уенга кермәкче идем.

– Юк, сың инде. Хәзер кермисең.

– Абый, керим инде, ә?

– Әйтеп торам: хәзер сың инде.

Әлтафи баскан урынында катып калды. Ни өчен соң? Нәрсәгә соң? Ну, бу укытучыларның сөйләшүе! Каның катарлык итеп сөйләшәләр бит! Һәм, гомумән, нигә «соң» дип әйтми, ә «сың» дип сөйли? Үзәккә үтәрлек булсын дипме?

Кара такта буена барыбыз да тезелеп бастык. Әле ике минут элек кенә барыбыз да геройлар идек. Ә хәзер уенга керергә ялынабыз – кертмиләр. Безнең маңгайлар каршында озын бармак уйный:

– Сез сугыш вакытында теләсә нинди тәртипсезлекләр эшләп өйрәнгәнсез. Бөген аңа нокта куябыз. Мин сезнең, болай булсагыз, каныгызга тоз салырмын! Сез – булачак педагоглар! Сезгә балалар белән уен оештырырга кирәк булачак. Ә сез тәрәзә янына җыелып карта сугасыз! Сезнең каныгызга тоз салырмын мин! Ә хәзер Хәлимов карталарын күтәреп минем янга керә…

...Ул көнне төн бик маҗаралы булды. Гыйззәтуллин төненә ике тапкыр кычкырып уянды. Әллә нәрсәләр әйтеп саташты. Зарифуллин саташып көлде. Мин, йокыга китә алмыйча, юка иске одеялга төренеп күзләремне йомып яттым. Тәрәзә артында буран сызгыра, өй нигезенә терәлеп үскән тигәнәкме, нәрсә, буран белән селкенеп стенаны кытырдата. Караңгы, куркыныч! Йокламаган көе саташам. Имеш, ишек янындагы йомры мич бөтенләй мич түгел икән, аның төсе дә ак түгел, өстендә сары сатин күлмәк икән. Әнә ул мичтән озын бармак үсеп чыга, ул бармак күз арасына таба сузыла һәм мичтән тавыш чыга:

– Тоз салырмын!

– Тоз салырмын! –ди.

...Шулай газаплы төн узды. Иртәгесен һәркем күргән төшен сөйләде. Гыйззәтуллин төшендә Гитлерны күргән икән. Бик зур тегермән буасы, ди. Шунда тегермән арыгына атланып Гитлер утыра икән. Кулында сигездән үргән камчы, ди. Гыйззәтуллин буа астындагы ниндидер бер чокырдан үрмәли-үрмәли чүмеч белән су ташый икән. Чүмечен шул арыкка бушатуга, Гитлер теге камчы белән чыжылдатып аның аркасына суга һәм:

– Нох айн маль! Нох айн маль! – дип, тагын теге чокырга төртеп төшерә икән…

Зарифуллин кичтән юк кына бер әйбер аркасында Әлтафи белән бәргәләшеп алган иде. Төшенә дә Әлтафи кергән. Имеш, Әлтафиның беләген кемдер пәке белән ярган, ди. Шул ярага немец теле укытучысы бик пөхтәләп, әкренләп вак тоз сибә, ди, Әлтафи күзләрен йомып, тешләрен кысып газаплана, ди…

…Немец теленең алдагы дәресендә өч малай бишле алдылар. Болар Зарифуллин, Пермяков һәм Гыйззәтуллин иде.

Сары күлмәкле дә безгә ошый башлады. Хәер, кышка таба ул, сары күлмәген салып, свитер киеп йөри иде инде…

ҮТКӘН БЕЛӘН КҮЗГӘ-КҮЗ – БҮГЕН...

Яз-җәй сезонының кино һәм китап дөньясында вакыйгага әверелгән ике премьерасына игътибар итмичә узсак, дөрес булмас иде. Тәнкыйтьчеләрнең рейтинглары буенча да, укучылар белән тамашачыларның бәясе ягыннан да – алар югары позицияләрдә. Сүз Харуки Муракаминың «Убийство командора» дилогиясе һәм HBO телеканалының «Чернобыль» мини-сериалы турында бара.

Автор:
Луиза Янсуар

ДӨНЬЯ СҮРҮЕ ЕРТЫЛСА...

ХАРУКИ МУРАКАМИ «УБИЙСТВО КОМАНДОРА 1», «УБИЙСТВО КОМАНДОРА 2»

Россия кайчандыр Мураками романнарын яратуы буенча беренче урында тора иде, бездә аның әсәрләрен хәтта махсус «Мураками мания» дигән сериядә дә бастырдылар. Ә аннары бу бум беразбасыла төште. Хәер, Мураками үзе дә темпларын киметте. Аның соңгы романы басылганнан соң берничә ел узып, фанатлар инде бераз тынычлана төшкән иде. Һәм менә – яңа әсәр. Ул дөнья буйлап 2017 елда таралып, без русчага тәрҗемәсен ике елга якын көттек. 2019 елның июнь башында «Эксмо» укучыларын, ниһаять, сөендерде: ике саллы китаптан торган (ә соңгы арада Мураками эпик форматка йөз тотуы белән билгеле) «Убийство командора» – китап киштәләрендә.

Роман турында промо вакытында төрледән-төрле хәбәрләр йөрде: имештер, бу Фицджеральдның «Великий Гэтсби» романына оммаж, шул ук вакытта аңарда Стивен Кингка сылтамалар да ярылып ята, янәсе. Инде китап немец һәм инглиз телләрендә пәйда булгач, аның хакындагы шау-шулар килеп ирешә башлады: романны Гонконгтагы китапханәдән алырга таләп иткәннәр, имеш ул ниндидер шикле антипремиягә лаек булган икән...

Ничек кенә булмасын, бу Муракаминың һаман да популяр булуына һәм кызыксынулар үзәгендә калуына ишарә итә.

Фотолар www.livelib.ru һәм www.kinopoisk.ru сайтыннан алынды.

«Убийство командора» китабының укучыга тәкъдим ителү тарихы үзе дә шуны сөйли. Япониядә ул сатуга 2017 елның 24 февралендә нәкъ төнге 12 дә чыкты. Китапка чират, язуларына ышансак, инде кичтән үк тезелгән иде. Сату стартыннан соң ук әсәрне алучылар саны рекорд дәрәҗәсенә җитте. Моңарчы басылып чыккан һәм зур популярлык казанган «1Q84» өч томлыгы белән «Бесцветный Цкуру Тадзаки и годы его странствий» да бу чикне узмаган иде, дип искәртә рейтингларны билгеләүчеләр.

Ни өчен яңа роман шундый зур шау-шу тудырды соң? Бәлки, реклама урынына антиреклама кулланылганга? Дөресрәге, промоның бөтенләе белән мәгълүматтан мәхрүм булуына бәйле рәвештә? Без әсәрнең эчтәлеге хакында баштан ук берни дә белмәдек диярлек. Бары тик романның нацизм белән бәйле икәнлеген генә. Ә Мураками өчен бу тарихи яссылык инде күптәннән яңалык түгел, асылда. Гитлер Германиясе булсынмы, Хиросима белән Нагасаки ситуациясеме, Нанкин вакыйгаларымы... Җитмәсә, роман махсус каплаулы тышлык һәм кырыс 18+ грифы белән пәйда булды. Һәм, инде югарыда искә алынганча, хәзер ул – кайдадыр тыелган китаплар рәтендә. XXI гасыр укучысы өчен моннан да зуррак ымсындыргыч алым булырга мөмкинме?!

Мин, укучы буларак, баштан ук әйтеп куярга кирәк табам: сагындырган Мураками. Һәм... гел үзе булып калган! Китапларындагы котылгысыз психологик лабиринтлар, флегматик, интроверт, ялгызак, әмма бер үк вакытта башкаларның тәвәккәллеге җитмәстәй адымнарга сәләтле каһарманы белән. Бу ике китапның да битләре аша менә дигән сыйфатлы музыка саркыла, затлы эчемлекләр, кухня, киемнәр, машиналар белән беррәттән гадәти атмосфера бөркелә, песиләр узыштыргалый, сәер персонажлар калкып чыга, ябык пространстволар үзенә йолып ала һәм яңадан кан алыштырырга, хәтта ки туарга мәҗбүр итә.

Сюжет бик гадәти, бу авторга хас булганча, аскетларча яссылык, дисәк тә ярыйдыр. Төп каһарман – акчага чиновникларның портретларын ясау белән көн күрүче гадәти бер рәссам. Көннәрдән бер көнне хатыны аңа: «Мин башка синең белән яши алмыйм», – ди. Аяз көнне яшен суккандай яңгыраган бу хәбәр аны өеннән чыгып китеп, юлларда гизәргә мәҗбүр итә. Аннан, хәле бераз җиңеләйгәч, ул дустының тәкъдименә риза була – таулардагы бер йортка барып урнаша. Бу йорт дустының әтисе гомере буена яшәгән оя булып чыга. Ә ул әти кеше үзе – картлар өчен пансионда үлемен көтеп ятучы бер бәндә, әмма бу бәндә заманында Япониядәге бик атаклы рәссам була.

Картины – вещь странная: они постепенно обретают собственную волю, точку зрения и убедительность голоса. Когда работа закончена, картина сама сообщает пишущему человеку об этом. Сторонний наблюдатель за творческим процессом – если такой окажется рядом – вряд ли отличит, завершена картина или еще нет. А вот самому художнику понятно.

Кеше аяк басмый торган тау битендә урнашкан йортта җай гына яши башлаган каһарманыбыз көннәрдән бер көнне чарлактан яхшылап төреп куелган картина табып алып төшә дә, аны сүтеп карый. Аннан аны төн уртасында сәер тавыш уята – бакчадагы куаклык эченнән кыңгырау тавышы яңгырый. Күршесендә яши торган, каһарманыбыз портретын ясаган сәер бер затлы, бай әфәнде белән барып карасалар: анда борынгы төрбә икән... Каһарманыбыз шул мизгелдән тормышының гадәти чынбарлык кысаларыннан чыкканын аңлый. Ә без, Мураками сурәтләгән сәерлекләрнең асылда кеше психологиясе лабиринтлары икәнлеген яхшы ваемлаган хәлдә, үзебезнең аң катламы аръягына атларга әзерләнәбез. Ә анда, бу язучы әсәрләре йогынтысында атлаганда, хәтәр һәм еш кына үзеңнән үзең үк яшергән тыкрык-чатларга юлыгырга мөмкинсең...

Роман Муракаминың икенче бер әсәренә – «Охота на овец» романына бик аваздаш. Әмма биредә Икенче Бөтендөнья сугышы тематикасы башкарак ракурстан ачыла һәм икенчерәк хәл ителеш ала. Шулай да Мураками өчен актуаль һәм авырткан тема дәвам итә: кылганы өчен кешенең җәзага таруы/кичерелүе мәсьәләсе һаман да кан саркыган яра булып кала бирә.

Мураками Моцарт әсәре аша Дон Жуан сюжетына китереп тоташтыра, Командор образы аша – Гитлерга, Икенче Бөтендөнья сугышы башланыр алдыннан булган, әмма тарихта әллә ни билгеле булмаган вакыйгаларга. Гитлер режимына кадәрге Австрия, беренче концлагерьлар, Нанкин иттарткычы – болар барысы да әллә кайчан булып узган һәм онытылган кебек тоелса да, Мураками әсәрендә, гадәттәгечә, дөнья сүрүе тик торган җиреннән ертыла һәм мондагы – бүгенгедә яшәүче һәркем җавап тотарга чакырыла. Ни хакына без үзебезнең намусыбызны аклый алабыз да, ни бәрабәренә кадерле кешеләребезне сакларга көчебез җитә? Ә дөньяны, илне, планетаны? Безгә кадәр булган ялганнардан чынбарлыкны нинди хакка сатып алырга мөмкин?! Үткән безне килеп эзәрлекләгәндә, аның күзенә туры карап, ничек исән калырга?

Мурками сорауларны гадәти яссылыкта куймый, җавапларны да үзебезгә җәфаланып табарга калдыра – геройлары белән бергә Вакытны һәм Пространствоны кичеп, йөзе урынына төтен генә бөркелеп торган Көймәче белән бергә Ике Дөньяны тоташтыручы елганы кичеп, асылда, Җәһәннәмгә төшеп...

– Все, что здесь есть, – на что-то похоже, – не оглядываясь ответила Донна Анна, будто бы обращаясь к темноте перед собой.
– Выходит, все здесь настоящее?
– Никто не знает, какое оно – настоящее, – ровно произнесла она в ответ. – Все, что мы видим здесь, перед глазами, в конечном свете – производное взаимосвязи...

Романдагы квест-башваткыч элементларын кулланганда, Мураками ачыктан-ачык Фаулзның «Волхв», Кэроллның «Алиса в стране чудес», Достоевскийның «Братья Карамзовы», «Идиот» әсәрләренә сылтама ясый. Квестның азагы аны чынлап та үтәргә кирәк булган икәнлеген янә бер мәртәбә раслый.

КЕШЕ ГОМЕРЕНЕҢ БӘҺАСЕ БАРМЫ?
«ЧЕРНОБЫЛЬ» (МИНИ-СЕРИАЛ)

Америка телеканалы HBO һәм Британия челтәре Sky тәкъдим иткән биш серияле бу мини-сериал сезонның иң шаушу куптарган яңалыгы, иң көтелгән премьерасы булгандыр, мөгаен. Сериалның сценарий авторы һәм идеясен булдыручы – моңарчы популяр фильмнар, сериаллар буенча билгеле Крэйг Мазин, режиссеры моңарчы «Викинги» проекты аша билгеле – Йохан Ренк. Рольләрне башкаручылар – Джаред Харрис, Стеллан Скарсгорд, Эмили Уотсон, Пол Риттер һ.б. Шактый чуар һәм көтелмәгәнчә уңышлы состав. Гәрчә тәнкыйтьчеләр баштарак «винегрет» дип атаса да.

«Чернобыль» үзенең актерлары һәм алар тудырган характерлар буенча рейтингларда иң югары күрсәткечләр белән шаккатыра. Аны инде беренче сериясләре чыгуга ук «Оскарга претензия белдерә ала» дип тамгаладылар.

Премьерасы Америкада – 6 майда, Бөекбританиядә 7 майда булды. HBO каналы аша рус телендә дә Амедиатекада карау мөмкинлеге бар. Әлегә – түләүле. Ул кино тәнкыйтьчеләре рейтингы буенча күпчелек түләүле каналларда 10 баллга лаек дип табылды.

HBO телеканалының бу сериалга заказ бирүе хакында 2017 елның 26 июлендә игълан ителгән иде. Крэйг Мазин, сценарийга керешкәнче, берничә ел дәвамында архивларда утыра, һәлакәт булган җиргә бара, бу темага кагылышлы китаплар белән таныша, хакимиятнең докладларын, рапортларын, утырыш стенограммаларын тикшерә. «Чернобыль»не Литва территориясендәге ташландык Игналин АЭСндә, өлешчә Украинада төшерәләр. Сценарий авторы үзе болай ди:

Я разрабатывал сценарий так, чтобы в мини-сериале авария на Чернобыльской АЭС была лишь фоном, а основной посыл заключался в цене лжи. Я хотел привнести в историю дополнительный слой подлинности и человечности.

Шуңа да ул нигездә вакыйгаларның иң үзәгендә булган гадәти кешеләрне алдынгы планга чыгара. Чернобыль АЭС янында яшәгән, анда эшләгәннәргә мөрәҗәгать итә, фаҗигане бетерүдә катнашучыларны күрсәтә. Документларны күтәрә һәм, шул рәвешле, бу куркыныч тарих хроник төгәллек белән сәнгати тирәнлек ала. Мазин авария булганда Киевта яшәгән берәүне консультант итеп ала, ул сценарийга төгәллекләр кертә, детальләр өсти, чор атмосферасын өрә. Урыны-урыны белән Светлана Алексиевичның «Чернобыльская молитва» китабына мөрәҗәгать ителә.

80 нче еллар атмосферасын бар төгәллегендә тудыру өчен Киев, Мәскәү, Санкт-Петербург базарларыннан реквизитлар җыялар, «Беларусьфильм» фондларын күтәрәләр, Авито һәм Юла аша кешеләрдән шул чор әйберләрен сатып алалар. Визуаль бизәлешне эшләр өчен Россия белгечләре һәм консультантлары туплана.

Төп каһарман – галим Валерий Легасов коточкыч сайлау алдына куела: ялганларгамы, дөресен сөйләргәме? Сценарий авторы белән режиссер аның персонажын психологик яктан шактый тирән итеп гәүдәләндерә: бу совет идеологиясе һәм сәяси системасының бер «шөребе», моңа кадәр аңарга болай зурдан кубып система хакында кискен уйларга, барысының да ялганга корылган булуына инанырга, шикләнергә туры килми. Әмма авариядән соң ул ышанган дөнья баштанаяк какшый…

Фильмны карый башлаганда, Көнбатыш төшергән сериал, быелгының шау-шулы «Нуриев: белый ворон» премьерасындагыча, кабат «СССР – явызлык һәм аңгыралык оясы» дигән рухта булыр инде, дип шикләнгән идем. Шөкер, «Чернобыль» бу шикләрдән арындырды. Әлбәттә, безнең караш шунда ук эләктереп алган һәм «читтән караш» икәнлеген билгеләгән элементлар, моментлар юк түгел, бар, әмма, тулаем алганда, бу сериалда

аны төшерүчеләр глобаль якын килүгә ирешкәннәр. Һәм, булдыра алганча, аутентиканы да сакларга тырышканнар.

Фильмдагы каһарманнар галереясы, психологик чишелешләр шактый зур тәэсирләнү дулкыны тудыра, ышандыра, авырттыра, кыскасы, чын мәгънәсендә җәлеп итә. Голливуд һәм Көнбатыш штампларыннан мөмкин кадәр азат булырга тырышулары да ихтирам уята.

Мы были одержимы аутентичностью – старались сделать подлинными все вплоть до шнурочков, марки часов, очков, шляп и причесок, которые носят главные и вообще все герои.

«Чернобыль» экраннарга чыкканда, сериалның яңа эпизодлары белән беррәттән, You Tube та The Chernobyl подкасты чыгарыла башлады. Биредә сериалны төшерүчеләр бөтен нечкәлекләрдә Чернобыль фаҗигасе, аңа китерүче тарихи факторлар турында фикер алышты, реаль геройлар турында сөйләде, аларның язмышларына тукталды. Документалистика һәм экрандагы сәнгати сюжетны сүтеп, параллель куеп дяирлек күрсәтеләр. You Tube подкасты рейтингны искиткеч күтәрде, премьераның язмышын уңай хәл итте. Мониторинг та шуны билгеләгән булып чыкты: сериалның эчке кухнясына җәлеп итүләре белән тамашачының күңелен икеләтә яулаганнар, кешеләр бу тарихка якынайтканнары өчен сериалны әзерләүчеләргә әле һаман да рәхмәт яудыра. «Бу куркыныч тарихка һәм кешелек дөньясындагы олы фаҗигага җәлеп итеп дөрес эшләдегез: без, тирәюнебездә әле һаман да кан коюны күреп торучы XXI гасыр кешеләре, бәлки кайсыдыр ялгыштан котыла алырбыз», – дигән шәрехләр бар подкаст астында.

«Чернобыль» гади тамашачыда гына түгел, актаклы шәхесләрдә дә зур кызыксыну уятты. Аны шәрехләүчеләрнең берсе – Стивен Кинг. Күренекле фантаст сериалда гәүдәләндерелгән чиновникларның компетенцияле булмавын АКШның бүгенге президенты Дональд Трамп сәясәте белән тиңләштерде. Бу шәрех әле һаман да блогларда, социаль челтәрләрдә «йөри», шәрехләнә. Шуның белән беррәттән, «Чернобыль»гә игътибарны көчәйтә генә. Димәк, промоушен хәстәрен күрүчеләр курсны заманча итеп ялгышмаган, дияргә дә мөмкиндер.

Россия тәнкыйтьчеләренең күпчелеге, билгеле, чорны, аның вазгыятен, «аппарат»ны күрсәтүдә шаблонның барыбер дә сакланган икәнлеген ассызыклый, сериалга Көнбатыш мөһерен бастырып ук куймаса да, тидерми калмый. «Искусство кино» тәнкыйтьчесе Игорь Кириенко язмасында болай ди:

У героизма рядового состава и халатности начальства одна и та же природа. Советский космос формировал людей, которые были готовы пожертвовать всем (в данном случае – ради спасения Центральной Европы), в этой же среде росли те, кто впоследствии будет руководствоваться совсем другими идеалами… Все это не освобождает от ответственности одних и не гарантирует симпатии другим… Есть такой вид радиации, которым заражены все, и неважно, какой была доза. Он называется «прошлое»: архив подлостей и низостей…

«Чернобыль» сериалын төшерүчеләр болай дип кабатларга ярата: «Безнең фильм зур көчкә ия хакимнәрнең дә ялгышырга мөмкин булуы, гадәти көчсез халыкның да каһарманлыкка сәләтле икәнлеге турында».

Менә монысы инде чынлап та Көнбатышча самими да, хисле дә яңгырый. Гәрчә, безнең ватан өчен бу алгоритмның соңгы ике гасыр чигендә әле үзгәргәне юк. Глобальләшү шартларында тәрбияләнгән яңа буын үзгәртсә генә алгоритмнарны… ■

татмедиа

Язылһәм от!

Телевизор, көнкүреш техникасы, башка күп кенә бүләкләр

Бүләкләр 2019 елның 16 августында уйнатылачак

1 ЯЗЫЛ — 30.06.2019 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә өч басмасына языл (акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)

2 ҖИБӘР — язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр (телефон номерыңны күрсәтергә онытма!) Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 ОТ — телевизор, мультиварка, иттарткыч, блендер, йон юрган һәм башка призлар от

Реклама 16+

Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында. Акцияне үткәрү вакыты: 22.04.2019 – 20.09.2019
Заявкалар 2019 елның 20 июленә кадәр кабул ителә. Оештыручы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

МАХСУС ПРОЕКТ

— 43нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

Рөстәм Нигъмәтуллин, ТР Премьер-министрының беренче урынбасары, июньдә үзенең 50 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Татарстан өчен алыштыргысыз кеше

Азат Нигъмәтҗанов,
Казан башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр төзелеше сәясәте буенча беренче урынбасары

– Хөрмәтле Рөстәм Камилевич!

Сезне күркәм юбилеегыз белән тәбрик итәм һәм Сезгә чын күңелдән иң изге теләкләремне юллыйм!

Татарстаннан еракта туып, Сез бирегә икенче йортыгызны һәм яраткан эшегезне таптыгыз. Сезнең бөтен хезмәт юлыгыз – беренче адымнарыгыздан алып бүгенге вазыйфагызга кадәр – өзлексез рәвештә шәһәр хуҗалыгы белән бәйләнгән. Казан мэриясе администрациясендә яшь хезмәткәр булып эшләгән чорда Сез үзегезнең зирәк акылыгызны һәм менә дигән башкару сәләтегезне күрсәтә алдыгыз. Характерыгызга хас югары җаваплылык белән Сез иң беренче Татарстан башкаласының 100 еллыгына әзерләнү бурычын, соңрак дөнья дәрәҗәсендәге спорт чараларын оештыру эшләрен башкарып чыктыгыз. Шуңа күрә республика җитәкчелеге Сезнең тәҗрибәгезнең һәм талантыгызның Казанны һәм Татарстанны нәтиҗәле үстерү юлында никадәр таләп ителүен даими билгеләп тора.

Административ дәрәҗәдә Сез Казанның тарихи үзәген яңарту өчен җаваплы булдыгыз. Беренче этапларда бу эш шактый катлаулы иде, әмма Сез дөрес сәясәт алып бара алдыгыз һәм яраткан шәһәребезнең үзенә лаеклы йөзен булдыра алуына ирештегез.

Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары вазыйфасына керешкәч, Сез янә фикер сөрешегезнең киңлеген, вак-төяк тоелган нәрсәләрне тирәнтен белүегезне һәм еллар дәвамында тупланган һөнәри сиземләвегезнең дөреслеген күрсәтә алдыгыз. Бүген Сез кискен социаль, икътисадый һәм җир мәсьәләләре өчен җаваплы. Үзегезгә хас эзлеклелек һәм көч-куәт белән бүген дә республика иминлеге хакына хезмәт куюыгызны дәвам итәсез.

Форсаттан файдаланып, Сезне чын күңелдән юбилеегыз белән котлыйсым һәм Сезгә һәр эшегездә уңышлар телисем килә. Янәшәгездә һәрвакытта да ышанычлы хезмәттәшләрегез һәм дусларыгыз булсын, йортыгызда иминлек һәм бәрәкәт яшәсен. Актив озын гомер, ныклы сәламәтлек һәм бәхет Сезгә, хөрмәтле Рөстәм Камилевич!

Фото Казан башкарма комитетыннан алынды

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

Реклама бүлеге:

тел: (843) 222-09-76,

8-9272-483-384

e-mail: 89272483384_pr@mail.ru

Реклама 16+

Марат Әхмәтов, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, июньдә үзенең 65 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Марат Әхмәтов ветеринария табибы, колхоз рәисе, КПССның Балтач райкомында башта – икенче, аннан беренче секретарь булып эшли. 1990 –1991 елларда Марат Готыфович – халык депутатларының Балтач район советы рәисе, аннан соң, 1999 елга кадәр, – Балтач администрациясе башлыгы һәм район советы рәисе. 1999 елның маеннан – ТР Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры.

Марат Әхмәтов – авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты, Гуманитар фәннәр академиясенең Шәрәфле әгъзасы, Фән һәм техника өлкәсендә ТР Дәүләт премиясе лауреаты, Дуслык, «Почёт Билгесе» орденнары, «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале, РФ Авыл хуҗалыгы министрлыгының көмеш медале белән бүләкләнә. Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре.

Җир синең язмышың булганда

Вәгыйзь Минһаҗев, «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» Федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы җитәкчесе

Фото «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» ФДБУның ТР буенча филиалыннан алынды

– Хөрмәтле Марат Готыфович! Бөтен коллектив исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән котлыйм. Быел Сез шулай ук республика авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры вазыйфасында эшли башлавыгызның егерме еллыгын билгеләп үтәсез. Бу Татарстан авыл хуҗалыгы өлкәсе өчен дә мөһим вакыйга.

Хезмәт юлыгызның башында ук Сез фермерлык белән бәйле эшне сайладыгыз һәм күңелегез белән һәрвакыт аңа тугры калдыгыз. Сезгә шулай ук административ һәм идарә эше дә яхшы таныш. Әлеге тәҗрибәне Сез Балтач районы башлыгы булып эшләгәндә тупладыгыз. Сездә булган җаваплылык һәм аналитик фикер сөреше белән берлектә әлеге тәҗрибә авыл хуҗалыгы министры вазыйфасын биләү чорында ныклы нигез була алды.

Сез – барлык авыл хуҗалыгы мәсьәләләрендә бәхәссез абруй, чөнки һәрвакытта да авыл хуҗалыгы өлкәсенә караган яңалыклардан һәм инновацияләрдән хәбәрдар. Эшегез фаразлавы авыр булган шартларда планлаштыруга бәйле, бу беркайчан да тик торырга мөмкинлек калдырмый. Ләкин һава торышы нинди генә күңелсезлекләр ясамасын, Сез сабыр булып кала һәм проблемаларны хәл итү юлларын таба аласыз.

Сезнең өчен җир территория генә түгел, ул Сезнең язмышыгыз һәм гомерлек хезмәтегез. Һәр көнне Сез авыл хуҗалыгын үстерү юнәлешендә күп көч куясыз, уңыш, терлек-туар өчен борчыласыз, культуралар һәм туфрак белән эшләүнең прогрессив методларын эзлисез. Сезнең күпьеллык тәҗрибәгезгә таянып, авыл хуҗалыгы кебек гаять зур һәм яңартыла торган ресурс Татарстанга Россиянең башка төбәкләре арасында үзен ышанычлы хис итәргә булыша.

Озак еллар дәвамында без Сезнең кебек профессионал белән иңгә иң куеп хезмәт итәбез һәм әлеге нәтиҗәле хезмәттәшлек белән горурланабыз. Без республика авыл хуҗалыгының алга таба үсешенә ышанабыз һәм Сезгә тормышыгызның барлык өлкәләрендә уңышлар һәм иминлек юлдаш булуын телибез.

Республика авыл хуҗалыгын үстерү юлында

Илшат Ганиев,
«Майский» ТК» ҖЧҖ
генераль директоры

– Хөрмәтле Марат Готыфович! «Майский» ТК» ҖЧҖ коллективы исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән ихлас котлауларны кабул итеп алыгыз! Сез туган айның авыл хезмәтчәннәре өчен матур җәйге чорның башлануын аңлатуы һәм язгы кыр эшләренең беренче нәтиҗәләрен бәяләргә мөмкинлек бирүе күркәм бер фал булып тора.

Язмыш шулай язгандыр, Сезгә министр вазыйфасына авыл хуҗалыгы өчен бигүк имин булмаган елларда керешергә туры килде. Әмма чын игенче, җир кешесе буларак, Сез әлеге хезмәткә җиң сызганып тотындыгыз һәм армый-талмый әлеге өлкәдә җыелган проблемаларны чишә башладыгыз.

Инде 20 ел дәвамында республика авыл хуҗалыгы руле артында булуыгыз республика җитәкчелеге тарафыннан гына түгел, бөтен аграр җәмәгатьчелек ягыннан Сезнең кандидатурага карата булган тирән ышанычны белдерә. Әлеге вакыт эчендә Сез республиканың авыл хуҗалыгы куәтен саклау һәм үстерү курсыннан бер дә тайпылмадыгыз.

Сезнең шиксез абруегыз киң белемегезгә, нәтиҗәле сәясәткә һәм дөрес планлаштыруга нигезләнә. Хезмәтегезнең нәтиҗәләре – Татарстан авыл хезмәтчәннәренә булышу максатында эшләнгән тулы чаралар комплексы, закон проектлары, дотацияләр һәм башка дәүләт ярдәме чаралары. Сез әлеге секторның төрле дәрәҗәләренә караган проблемалар һәм бурычлар турында яхшы хәбәрдар. Сез инновацияләрне хуплап каршы аласыз, күп очракларда вакытны узып эш итәсез.

Сезнең ирешелгәннәрдә туктап калмавыгызга ышанам һәм киләчәктә үзенең матур җимешләрен бирергә тиешле күпләгән файдалы проектларны гамәлгә ашыру юлында торасыз. Сез карарларыгызның җаваплылыгын тоеп эш итәсез, чөнки күп очракларда фермерларның иминлеге әлеге карарларның дөреслегеннән тора. Җирдә эшләүче кешеләр турында кайгыртуыгыз, аларны рухландырырга тырышуыгыз, эш шартларын яхшыртырга омтылуыгыз бигрәк тә кадерле.

Сез шулай ук авылны үстерү мәсьәләләре белән дә шөгыльләнәсез, чөнки бу авыл хуҗалыгы өлкәсен уңышлы үстерү өчен нигез булып тора. Кешеләрнең җиргә һәм аның ресурсларына карата сакчыл карарга тиешлеге турындагы мәгълүматны тарату агросәнәгатьчеләрнең аңбелем дәрәҗәсен үстерергә булыша.

«Майский» теплица комплексы дистә еллар дәвамында Татарстан халкын яшелчә белән тәэмин итә, һәм үсеш юлыбызның күп өлешен Сезнең игътибарлы күзәтчелегегездә узуыбызга шат. Әлеге вакыт аралыгында игътибарлы мөнәсәбәтегез нәтиҗәсендә тармак танымаслык булып үзгәрде һәм үсеш, чәчәк ату юнәлешендә хәрәкәтен дәвам итә.

Сез гомерегез буена фидакарь хезмәт итәсез һәм бу күренми кала алмый. Шуңа күрә барлык котлауларга кушылырга һәм алга куелган максатларыгызга ирешү юлында уңышлар теләргә рөхсәт итегез. Йортыгызда да, Татарстан кырларында да иминлек хөкем сөрсен. Үзегезгә һәм якыннарыгызга иксез-чиксез бәхет, ныклы сәламәтлек һәм озын гомер юлдаш булсын, Марат Готыфович!

Фотолар «Майский» ТК» ҖЧҖнән алынды



Реклама

Фото «Татэнерго» АҖнән алынды

Ирешелгәннәрдә туктап калмыйча

Рәүзил Хаҗиев,
«Татэнерго» АҖ
генераль директоры

– Хөрмәтле Марат Готыфович! 65 яшьлек күркәм юбилеегыз көнендә Сезнең хөрмәткә яңгыраган котлауларга кушылып, «Татэнерго» АҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән иң изге теләкләрне юлларга рөхсәт итегез!

Әти-әниегезнең күркәм үрнәген күз алдында тотып, Сез авыл хуҗалыгы белеме алгансыз, ә аннан соң колхоз рәисе сыйфатында табигать тарафыннан бирелгән талантыгызны ачкансыз. Мондый кешеләрне һәркайда бәяли беләләр, шуңа күрә тиздән Сез районны җитәкләдегез, ә соңрак республикабыз тарихында иң уңышлы авыл хуҗалыгы министрларының берсе булуга ирештегез.

Чын хуҗалыкчы буларак, Сез дөрес анализ ясар өчен саннар белән кәгазьләрнең генә җитмәвен яхшы аңлыйсыз. Тулы картинаны күзаллау өчен, Сез кырларга һәм авылларга чыгасыз. Республикабызның иң ерак почмакларында да Сезне шәхсән беләләр. Дистә еллар эчендә фермерлык җәмгатьчелеге өчен күп нәрсәләр эшләдегез. Ләкин, безнең бәхеткә, Сез алга таба эшләвегезне дәвам итәсез һәм ирешелгәннәрдә туктап калырга җыенмыйсыз.

Сез сайлаган юл җиңелләрдән түгел. Кайчак һава шартлары катлаулы вазгыятьләр тудыра, әмма тупланган тәҗрибә һәм һөнәри сизгерлек стратегик яктан дөрес карарлар кабул итәргә, авырлыкларны җиңәргә булыша.

Сезгә бетмәс-төкәнмәс көч-куәт, уңышлар телим. Киләчәктә Сезне бары тик бәхет, мул тормыш һәм иминлек кенә көтеп торуына ышанам!

Реклама

Фото «Татмелиорация» ТК ҖЧҖнән алынды

Сезгә һәм Татарстанның аграр тармагына иминлек

Рөстәм Сөнгатуллин,
«Татмелиорация» ТК ҖЧҖ
генераль директоры

– Хөрмәтле Марат Готыфович! Юбилеегыз белән котларга рөхсәт итегез! Шәхсән үз исемемнән һәм республика мелиораторлары коллективы исеменнән Сезгә иң матур теләкләремне юллыйм.

Инде 20 елдан артык Сез, тәҗрибәле хуҗалыкчы һәм игътибарлы идарәче тәҗрибәсен уңышлы кулланып, республикабызның аграр тармагын җитәклисез. Инновацияләргә һәм перспективалы планлаштыруга таянып, Сез әлеге хезмәтнең мөһимлеген саклап кала һәм аның нәтиҗәләрен арттыра барасыз.

Янәшәгездә эшләүчеләр Сезнең хезмәт сөючәнлегегез, абруйлы һәм авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре ихтыяҗларына игътибарлы булуыгыз турында сөйлиләр. Сез кырларда һәм фермаларда хезмәт куйган кешеләрнең ихлас рәхмәт сүзләрен бер генә мәртәбә ишетмәдегез. Сезнең көндәлек тырышлыгыгыз нәтиҗәсендә пәйда булган уңай үзгәрешләрне нәкъ менә алар үзләрендә тоялар.

Сезгә катлаулы чорда аграр тармак өчен җаваплылыкны үз өстегезгә алырга туры килде, шуңа да карамастан, авыл хуҗалыгын торгызып, барлык авырлыкларны җиңүгә ирештегез. Бүген Татарстанның әлеге тармагы Россия Федерациясе субъектлары арасында алдынгы урыннарны били.

Безгә, төбәкнең әйдәп баручы мелиораторлары буларак, Сезнең әлеге авыл хуҗалыгы тармагына карата булган игътибарыгыз кадерле. Нәкъ менә Сезнең ярдәмегез һәм хуплавыгыз нәтиҗәсендә эшчәнлекнең әлеге мөһим сферасы сакланып кала.

Сәламәтлек, актив озын гомер, зирәк акыл һәм яңа биеклекләр тулы теләкләребез бүген Сезнең хөрмәткә яңгырый. Сезгә ихлас күңелдән хөрмәтебезне күрсәтеп, эшчәнлегегез еллары өчен рәхмәтебезне белдерәбез. Татарстан бүген шул исәптән Сезнең хезмәтегез нәтиҗәсендә чәчәк ата, шуңа күрә Сезгә мул-имин тормыш, көч-куәт телибез!

Хезмәтегезнең җимешләре Сезне һәрвакыт куандырып торсын, Татарстан Республикасының, якыннарыгызның иминлеге хакына яңадан-яңа эшләргә рухландырсын!

Рөстәм Нуриев, Татарстанның Ютазы районы башлыгы, июньдә үзенең 50 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

НӘТИҖӘЛЕ ИДАРӘ – НӘТИҖӘЛЕ МУНИЦИПАЛИТЕТ

Һәрберебезнең көндәлек тормышына, тормыш дәрәҗәсенә һәм сыйфатына җирле муниципалитетның нәтиҗәле эшчәнлеге, аның үз вазыйфаларына җаваплы карашы йогынты ясый. Муниципаль район җитәкчесенең уңышлы үсешкә юнәлтелгән хезмәте уннарча мең кеше язмышы өчен җаваплылыкны күздә тота. Татарстанның Ютазы муниципаль районы башлыгы Рөстәм Нуриев бу хакта бик яхшы белә.

Рөстәм Мидхәт улы Нуриев

1969 елның 28 июнендә ТАССРның Әлмәт районы Түбән Мактама эшчеләр бистәсендә туган. 2002 елда – И.Н.Ульянов исемендәге Чуваш дәүләт университетын, 2008 елда Казан дәүләт технология университетын тәмамлый. Совет армиясе сафларында хәрби бурычын үтәп кайтканнан соң, Төмән өлкәсенең Лангепас шәһәрендә «Урьевнефть» НГТИндә нефть һәм газ чыгару буенча өченче разрядлы оператор вазыйфасында хезмәт эшчәнлеген башлап җибәрә. Соңыннан Әлмәттә Татарстанның Көньяк-Көнчыгыш сәнәгать палатасы директоры, Әлмәт районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары була.

Аның Әлмәт районында туплаган идарә тәҗрибәсе һәм шәхси сыйфатлары Ютазы төбәгендә яңа башлангычларга һәм проектларга нигез булып тора. Авыл хуҗалыгы... Ул вакытта ук яңа башлык районның бу тармагының потенциалын күрә. Инфраструктура проектлары... Мәгариф һәм сәламәтлек саклау объектлары... Һәрбер дәүләт программасын тормышка ашыруда район җитәкчесе бер үк төрле җаваплы. Рөстәм Нуриев Ютазы районы белән җитәкчелек иткән тугыз ел эчендә күп эшләр башкарылды. Аның эшкә таләпчәнлеге, максатчанлыгы һәм район проблемаларына игътибарлы мөнәсәбәте җимешләрен бирде. Әйтик, бүген Ютазы районы авыл хуҗалыгы тармагы алдынгы сафларда бара. Тармактагы системалы эшчәнлек нәтиҗәсендә туфракның уңдырышлылыгы артты, ташландык җирләр чәчү әйләнешенә кайтарылды, сортлы орлыклар белән селекция эше алып барыла, терлекчелек биналары төзекләндерелә һәм башка күп эшләр... Рөстәм Нуриев һәм аның командасы өчен сөт терлекчелегендә ирешкән күрсәткечләр горурланырлык. Район хуҗалыкларында бүген сөт, 2012 ел белән чагыштырганда, 45% ка күбрәк җитештерелә. Тәүлеклек савым күләме 53 тоннадан артыкны тәшкил итә. Мөгезле эре терлекнең баш саны һәм ит җитештерү шактый арткан. Авыл икътисады, фермерлык хуҗалыклары һәм эшкуарлык үссә, авыл да яшәячәк! Территорияләрне төзекләндерү һәм юллар төзү дә район өчен өстенлекле һәм мөһим юнәлеш булып тора. Районда төзекләндерү буенча предприятие, капиталь төзелеш идарәсе эшли башлангач, «бу тармакларда эшнең нәтиҗәлелеге бермә-бер артты һәм төзекләндерү юнәлешендә күп кенә идеяләрне тормышка ашыру мөмкин булды», дип саный Рөстәм Нуриев. 2012 елда үз вазыйфасына керешкән Рөстәм Мидхәт улының инфраструктура өлкәсендәге беренче проекты райондагы барлык социаль объектларның җылыту системасын һәм түбәсен ремонтлау булды. Барлык мәктәпләр һәм балалар бакчалары капиталь төзекләндерелде.

Ютазы – республиканың көньяк-көнчыгыш капкасы, күрше Башкортостан белән чиктәш район. Ул Татарстанда гамәлгә ашырыла торган барлык социаль-икътисадый программаларда да актив катнаша. Сүз юллар, тротуарлар салу, социаль-мәдәни тармак объектлары һәм торак төзелеше, җирлек территорияләрен төзекләндерү һәм башка бик күп нәрсәләр турында бара. Ютазылылар энергия куллану нәтиҗәлелеге һәм ресурсларны янга калдыру күрсәткечләре буенча Татарстанда ел саен алдынгы урыннарны били. Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе соңгы елларда йөзен тулысынча үзгәртте һәм иң чиста, төзекләндерелгән торак пунктка әверелде. Районда гимназия, балалар бакчасы, универсаль мәйданчыклар һәм ФАПлар, авыл клублары файдалануга тапшырылды. Торак төзелеше актив үсештә. Әйтик, кыска вакыт эчендә бистә читендә яхшы инфраструктуралы «Солнечный» торак микрорайоны калкып чыкты. Хәзерге вакытта бу микрорайонда шәхси йортлар һәм «Яңарыш» паркы төзелеше дәвам итә.

Рөстәм Нуриевның кабатланмас сыйфаты – эшкә сәләтлелек. Туктап тору, тынычлану дигән нәрсәләр аның холкына бөтенләй хас түгел. Алда – зур планнар. Асфальт заводын эшләтеп җибәрү, «Урыссу» сәнәгать паркын уңышлы үстерү, сөт цехының продукция ассортиментын киңәйтү – болары якындагы планнар. Ә киләчәктә

Реклама

Фотолар ТР Ютазы муниципаль районыннан алынды

техникум ачу, «Яшел яр» яңа торак микрорайоны, яңа балалар бакчасы һәм район мәдәният йорты төзү, район музеен булдыру көтә. Ютазыда балаларга, гомумән, аерым мөнәсәбәт. Шуңа күрә мәгариф тармагы һәрвакыт район башлыгының игътибар үзәгендә. Моның ачык мисалы – Урыссу гимназиясе. Аның әйләнә-тирә мохиткә ярашып торган төрле төстәге яңа бинасы, заманча җиһазланышы уку процессын иң алдынгы белем бирү стандартлары нигезендә оештырырга мөмкинлек бирде. Дәресләр челтәрен күрсәтеп торган электрон мониторлар, ике дәүләт телендә юнәлеш билгеләре, интерактив такталар, табигать фәннәреннән лаборатория эшләре өчен өр-яңа җыелмалар, видеоэлемтә функциясе булган аерым конференц-зал, беренче сыйныф укучысы зурлыгындагы шахмат… Гимназия балалар өчен дәрес уку гына түгел, ә иҗатта, спорт һәм хезмәттә, дуслар белән аралашуда үз юлыңны табарга мөмкинлек бирә торган урын да булсын өчен, бирелдә барысы да эшләнгән. Ютазыга заманча яңа мәктәп кирәклегенә үз вакытында республика мәгариф министрлыгын ышандыра алган район башлыгы өчен бу гимназия – аерым горурлык билгесе. Гимназистлардан лаеклы җавап озак көттермәде: соңгы елларда алар БДИ буенча сизелерлек яхшы нәтиҗәләргә иреште. Яшьләрне районда калдыру өчен, «кайда туган, шунда яраган» дигән махсус стипендия программасы булдырылган. Әлеге программа ярдәме белән җирле хастаханә табиблар белән тулыланды, гимназия һәм булачак ресурс үзәге өчен укытучылар да кайтырга тора.

Районда тормыш кайный. Рөстәм Нуриев башлангычы белән, эшкә яраклы яшьтәге кешеләрне өстәмә диспансерлаштыру буенча муниципаль программа уңышлы тормышка ашырыла. Үлүчеләр санын киметү дә, авыруларны иртә ачыклау да – гамәлдәге программаларның һәм карарларның нәтиҗәлелек күрсәткечләре. Районга җаны-тәне белән бирелгән Рөстәм Мидхәт улы бирегә инвестицияләр җәлеп итү эшен туктатмый. Икътисадый шартлар катлаулы булуга карамастан, ул һәрвакыт районның сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләрен саклауга һәм ныгытуга омтыла. Аның тормышы һәм эшчәнлеге туган якка, аның халкына мәхәббәт һәм хөрмәт белән сугарылган. Ныклы муниципалитет – көчле дәүләтнең нигезе. Ә үз эшенә бирелгән, иҗади рухлы кешеләрнең хезмәте һәрчак мактаулы. 2019 елда Рөстәм Нуриев республика конкурсы нәтиҗәләре буенча иң яхшы муниципаль хезмәткәр исеменә лаек булды.

Районны һәрьяклап үстерү курсы

Мәҗит Салихов,
«ТР ДЭБИ» ДАУ башлыгы

– Хөрмәтле Рөстәм Мидхәтович! Бик шатланып, Сезне 50 яшьлек күркәм юбилеегыз белән котлыйм.

Сезне күптәннән беләм һәм профессионал булуыгыз, актив тормыш позициясе биләвегез һәм туган ягыгызга фидакарь хезмәт итүегез өчен хөрмәтлим. Сезгә гади эшче хезмәте дә, административ эшчәнлекнең нечкәлекләре дә яхшы таныш. Күңелегезнең киңлеге, лидерлык һәм хуҗалыкчы талантыгыз, шулай ук кешеләргә игътибарлы мөнәсәбәтегез район иминлеге хакына башкарган эшләрегезне язмышыгызга әверелдерде. Тирән тормыш тәҗрибәсе, зирәк акыл һәм нәтиҗәле планлаштыра белү сәләтенә ия булып, Сез инде озак еллар Ютазы районынының потенциалын ачасыз. Әлеге вакыт аралыгында Сезгә ышанып тапшырылган территория сәнәгый, социаль, икътисадый һәм рухи-мәдәни үсеш өчен сизелерлек этәргеч алды, бу районны күп кенә республика рейтингларында алдынгы урыннарга күтәрде.

Соңгы елларда Ютазы районы шактый үзгәреш кичерде: мәктәпләр, балалар бакчалары салынды, халык өчен кирәкле барлык инфраструктура пәйда булды.Сезнең белән уртак эшчәнлегебез нәтиҗәсендә район халкының хыяллары тормышка ашуын күрү бик куанычлы хәл. Шуңа күрә игелекле эшчәнлегегез нәтиҗәсендә Сез ютазылыларның тирән ихтирамын яуладыгыз, алар өчен лаеклы үрнәк була алдыгыз, дип ышанып әйтә алам.

Форсаттан файдаланып, Сезгә ныклы сәламәтлек, ышанычлы ярдәмчеләр һәм фикердәшләр, гаилә иминлеге һәм барлык күркәм башлангычларыгызда уңышлар телим. Кызыксынуларыгызның киңлеге белән берлектә Сезнең оештыру сәләтегез алга таба да Татарстанның иминлеге хакына уңышлы эшчәнлекнең ныклы нигезе булып калыр, дип уйлыйм. Әлмәт районында бергә эшләгән чордагы кебек һәрвакыт шундый инициативалы һәм энергияле булып калыгыз! Юбилеегыз белән!

Фото «ТР ДЭБИ» ДАУнән алынды

Үз урынындагы кеше

Нурислам Хәбипов,
Ветеринария һәм фитосанитар күзәтчелек Федераль хезмәтенең ТР буенча Идарәсе җитәкчесе

– Район башлыгы вазыйфасында нәтиҗәле эшләү өчен аерым сыйфатлар – лидер, прогрессив кеше сыйфатлары таләп ителә. Әлеге сыйфатлар, Рөстәм Мидхәтович, Сездә һичшиксез бар. Моннан тыш, Ютазы районы халкы арасында ихтирам казанып, ышанычлы, намуслы һәм җаваплы кеше абруен тулысынча аклыйсыз.

Сезнең җитәкчелектә биредә – шәһәрдә һәм авылларда – күп кенә әһәмиятле социаль проектлар гамәлгә ашырылды. Татарстан традицион рәвештә илнең аграр тармагында алдынгы урыннарны били. Шуны аңлап, Сез авыл кешеләренең тормышына җентекле игътибар күрсәтәсез һәм перспективалы аграр проектларны актив хуплыйсыз.

Теләсә кайсы эшенең уңышын, бигрәк тә муниципаль идарәдә, хезмәткәрләр һәм аларның профессиональлеге, куплләгән кешеләр, структуралар һәм ведомстволар белән дөрес итеп эшли белү билгели. Рөстәм Мдхәтович, Сезгә хас хезмәт сөючәнлек, туа барган проблемаларны хәл итүгә стратегик якын килү белү сәләте, принципиальлек һәм намуслылык зур хөрмәт уята.

Максатыгыз – Ютазы районын таныту һәм анда яшәүчеләрдә иртәгәге көнгә ышаныч уяту – киләчәктә дә уңышлы тормышка ашырылыр, дип ышанам. Бу Сезнең башлык буларак үз урыныгызда эшләвегез турында сөйли.

50 яшьлек күркәм юбилеегыз көнендә Ветеринария һәм фитосанитар күзәтчелек Федераль хезмәтенең ТР буенча Идарәсе хезмәткәрләре һәм шәхсән үз исемемнән изге теләкләремне юллыйм! Сезгә киләчәктә дә ныклы сәламәтлек, шатлык-куанычлар юлдаш булсын! Күңел көрлеге һәм күтәренке кәеф беркайчан да ташламасын!

Фото Ветеринария һәм фитосанитар күзәтчелек Федераль хезмәтенең ТР буенча Идарәсеннән алынды

Авыл турында кайгырту – өстенлекле юнәлеш

Аяз Шәфигуллин,
ТР Ютазы муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе

– Хөрмәтле Рөстәм Мидхәтович! 50 яшьлегегезне көчегез һәм дәрт-дәрманыгыз ташып торган мәлдә каршы аласыз. Бу турыда гамәлгә ашырылучы яңа проектлар да, Сезнең өчен элеккегечә үк икенче дәрәҗәдәге мәсьәләләрнең юклыгы, ягъни районда барган бөтен нәрсәнең дә мөһимлеге дә сөйли. Җитәкче була белү таланты һәм предприятие җитәкчеләре белән нәтиҗәле мөнәсәбәтләр кора алу сәләте муниципалитетның барлык бурычларын уңышлы хәл итәргә булыша.

Ютазы районының җитештерү куәте машина төзелеше, төзелеш комплексы, нефть һәм химия сәнәгатенә генә түгел, авыл хуҗалыгына да нигезләнә. Әлбәттә, без, аграрийларны Сезнең авыл хуҗалыгы секторын формалаштыруга зур игътибар бирүегез куандыра. Җирдә эшләүчеләр һәм ютазылыларны азык-төлек тәэмин итүчеләр турында кайгырту Сезнең өчен өстенлекле юнәлешләрнең берсе булып торды һәм тора. Муниципаль мөмкинлекләрне кулланып, шулай ук нефтьчеләр ярдәменә таянып, район авылда шәхси инициативаларга, яңа эшкуарларга һәм фермерларга һәрьяклап ярдәм күрсәтә. Соңгы берничә ел эчендә авыл хуҗалыгы тармагында шактый зур уңышларга ирешелде. Бу нәтиҗәле минераль ашламалар куллану аркасында туфракның уңдырышлылыгын күтәрү, ташландык җирләрне чәчү әйләнәсенә кире кайтару, сортлы орлыклар белән эшләү, терлекчелек биналарын яңарту бәрабәренә мөмкин булды. Ел саен хуҗалыкларның матди-техник базаларын ныгыту максатына 70 млн сумнан артык инвестицияләр юллана.

Сез, Рөстәм Мидхәтович, Ютазы районы һәрвакытта да имин төбәк булсын, анда яшәүчеләргә уңайлы һәм лаеклы тормыш шартлары тудырыр өчен, бөтен көчегезне җигәсез. Актив хезмәттәшлеккә, сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы юнәлешләренә ярдәм итүгә корылган сәясәтегез дә үзенең җимешләрен китерә.

Сезнең максатчан хезмәтегез алга таба да Татарстанның чәчәк атуына, районның абруен үстерүгә һәм халыкның иминлеген арттыруга хезмәт итәр, дип ышанам.

Ютазы районы аграрийлары исеменнән Сезгә ихлас күңелдән яңа, кызыклы планнар, бетмәс-төкәнмәс көч-куәт, рухи ныклык һәм сәламәтлек телим! Янәшәгездә һәрвакытта да Сезгә ярдәм кулы сузарга әзер коллегаларыгыз, фикердәшләрегез булсын!

Фото ТР Ютазы муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсеннән алынды

Яңа җиңүләр һәм казанышлар!

Илсур Шәрипов,
«БАСЭТ» ФҖП директоры

– Хөрмәтле Рөстәм Мидхәтович!

Республикада инвесторлар белән хезмәттәшлек итүгә вертикаль хакимият ягыннан аерым, татарстанча якын килүне без, дөрес чиновник һәм хуҗалыкчы, Ютазы районының социаль-икътисадый үсеше өчен тырышучы буларак, Сезнең эшегез аша ачык күрдек. Сезнең белән мөнәсәбәтләребездә компетентлы булуыгызга, куелган максатларга ирешү юлында искиткеч максатчанлык күрсәтүегезгә сокланабыз.

Юбилеегыз белән! Үзегезгә һәм якыннарыгызга ныклы сәламәтлек һәм күтәренке кәеф телим!

Фото «БАСЭТ» ФҖПнән алынды

Олы юлның этаплары

Мансур Хафизов,
Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының элеккеге җитәкчесе, муниципаль район башлыгының элеккеге урынбасары

– Хөрмәтле Рөстәм Мидхәтович! Сезне бик шатланып 50 яшьлек юбилеегыз белән котлыйм! Безнең күп кенә якташларыбыз – республиканың көньяк-көнчыгышында эшләүче нефтьчеләр кебек Сез дә хезмәт юлыгызны нефть һәм газ табу операторы буларак башлап җибәргәнсез, гәрчә Түбән өлкәсендә булса да. Сезнең иңнәрдә – өч югары уку йортында белем алу, ТР Көньяк-Көнчыгыш сәнәгать палатасы директоры сыйфатында эшләп тупланган бай тәҗрибә. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары вазыйфасында Сез үзегезне муниципаль хезмәтләр белән идарә итүнең яңа формаларын оештыручы һәм аларны гамәлгә кертүнең инициаторы буларак ачык күрсәттегез. Әлеге тирән белем һәм бай тәҗрибә Сезгә һичшиксез муниципаль идарәнең югары профессиональлеккә ия белгече дәрәҗәсенә кадәр үсәргә мөмкинлек бирде. Сез лаеклы нәтиҗәгә ирешерлек итеп эшләргә күнеккән. Һәм бүген, инде башлык буларак, Ютазы районының социаль-икътисадый үсешенә үзегезнең саллы өлешегезне кертәсез. Бу якташларыгыз өчен шатланырга менә дигән сәбәп!

Рөстәм Мидхәтович, Сезнең кебек эшлекле һәм булдыклы кеше тормышында 50 яшь – олы һәм матур юлның башы гына. Шуңа күрә Сезгә иң кыю ниятләрегезнең тормышка ашуын телисем килә! Ныклы сәламәтлек, җылы гаилә учагы һәм ышанычлы дуслар Сезне беркайчан да ташламасын!

Фото ТР Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетыннан алынды

Һәркемгә үрнәк эшчәнлек

Фото «Урыссу төзекләндерү һәм яшелләндерү предприятиесеннән» алынды

Илшат Камалдинов, «Урыссу төзекләндерү һәм яшелләндерү предприятиесе» муниципаль унитар предприятиесе директоры

– Хөрмәтле Рөстәм Мидхәтович! Юбилей – Сезнең Ютазы районы өчен куйган хезмәтегез, андагы кешеләрнең тормышын яхшыртуга юнәлтелгән гамәлләрегез өчен ихлас хөрмәт сүзләрен җиткерү өчен бик яхшы форсат. Сезнең профессиональ җитәкчелек итү стиле – коллегаларыгыз өчен дә, кул астында эшләүчеләр өчен дә, халык өчен дә үрнәк. Районда җәмәгать урыннарын төзекләндерү, яшелләндерү һәм бизәү буенча тормышка ашырыла торган программалар һәм проектлар Ютазы халкының үзе яши торган мохиткә мөнәсәбәтен дә үзгәртте.

Район башлыгы буларак, Сез муниципаль предприятиеләргә нәтиҗәле эшләү өчен реаль стимуллар бирәсез, аларның проблемаларын өйрәнәсез һәм ярдәм кулы сузасыз. Мондый булышлык безнең предприятие өчен дә зур әһәмияткә ия. Без аны даими рәвештә тоеп эшлибез. Сезнең эшлеклелек сыйфатларын яхшы белгәнгә күрә, Сезнең Ютазы районы үсешенә кертәчәк өлешегез киләчәктә дә саллы булыр, дип ышанабыз.

Сезгә, Рөстәм Мидхәтович, һәрвакыт дусларыгыз, коллегаларыгыз һәм якыннарыгызның ярдәмен тоеп яшәү насыйп булсын! Бу таяныч Сезгә яңа максатларга ирешер өчен көч-куәт биреп торсын! Үзегезгә һәм якыннарыгызга тормыш юлында шатлык-куаныч, бәхет, һәрвакыт күтәренке кәеф юлдаш булсын!

Киләчәккә ышаныч белән карап

Фото «Теплосервис» МУП предприятиесеннән алынды

Равил Гарипов, «Теплосервис» МУП директоры

– Хөрмәтле Рөстәм Мидхәтович! Сезне «Теплосервис» муниципаль унитар предприятиесе коллективы һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз белән котларга рөхсәт итегез!

Сез, район башлыгы буларак, көн саен икътисадый һәм социаль-мәдәни тормышны яхшы якка үзгәртү максатында, районның имин киләчәген тәэмин итәчәк күпсанлы җитди мәсьәләләрне хәл итәсез. Алга карап эш итә белү сәләтенә һәм эш сөючәнлеккә ия кеше буларак, Сез фикердәшләр командасын булдырдыгыз һәм бергәләп күп эшләр башкара алдыгыз: ТКХ системасында зур үзгәрешләр кертелде, ә бу тармак коллективы эшенең тотрыклылыгына һәм халыкка сыйфатлы хезмәт күрсәтүгә уңай йогынты ясады. Бүген районда агросәнәгать комплексы яңа баскычка күтәрелә, яңа җитештерүләргә һәм сәнәгать предприятиеләренә ярдәм итүгә аерым игътибар күрсәтелә, сәламәтлек саклау, мәгариф, яшьләр сәясәте, спорт һәм мәдәният өлкәләрендә зур үзгәрешләр бара.

Районда тормышның кайнап баруында, яңа проектлар, программалар тормышка ашырылуында, бер-бер артлы яңа идеяләр һәм инициативалар туып торуында – Сезнең өлешегез дә зур, Рөстәм Мидхәтович. 50 яшегез тулган көндә Сезгә хезмәт җимешләрен саклап калуыгызны, аларны тагын да арттыруыгызны һәм киләчәккә ышаныч белән каравыгызны телисе килә! Сезгә сәламәтлек, бәхет, иминлек һәм район халкы иминлеге хакына нәтиҗәле хезмәт телибез!

Күпьеллык хезмәттәшлек өчен рәхмәт

Марсель Шәйдуллин,
Азнакай муниципаль районы башлыгы

– Хөрмәтле Рөстәм Мидхәтович! 50 яшьлек юбилеегыз көнендә яңгыраган барлык котлауларга кушылырга рөхсәт итегез.

Татарстанда туып, Сез үзегезнең барлык көчегезне һәм талантыгызны туган җиребезне имин итүгә юнәлттегез. Хезмәт юлыгызны сәнәгать тармагында башлап, Сез тиз арада чын идарәче-профессионал булып җитештегез. Әлмәт районында эшләгән елларда Сез үзегезне оста оештыручы һәм хуҗалыкчы итеп күрсәтә алдыгыз. Сез янәшәдәгеләрне үзегезгә җәлеп итәсез һәм аларның борчу-мәшәкатьләрен хәл итәргә булышасыз. Әлеге сыйфатларыгызга карап, Сезне Ютазы муниципаль районы башлыгы итеп сайладылар.

Тулы бер район халкы һәм территориясе өчен җаваплы кеше буларак, Сез үзегезне бары тик яхшы яктан күрсәттегез. «Муниципаль идарә итү өлкәсендәге иң яхшы хезмәткәр» дипломыгыз – шуны раслаучы дәлилләрнең берсе. Шулай ук Ютазы районының икътисадның барлык тармакларында алдынгы позицияләрне яулап баруына да бер генә ел түгел инде.

Сез – башка җитәкчеләр өчен лаеклы үрнәк, үзенә һәм кул астында эшләүчеләргә таләпчән чын профессионал. Ютазы районы җитәкчелектә Сезнең кебек ихлас, эшлекле һәм прогрессив кешегә ия булуы белән унды, Рөстәм Мидхәтович!

Сезгә чын күңелдән ныклы сәламәтлек, уңышлар, куелган максатларыгызга ирешүегезне, якыннарыгызның ярдәмен тоеп яшәвегезне телим!

Фото Азнакай муниципаль районыннан алынды

Ютазы районының потенциалын ачып

– Хөрмәтле Рөстәм Мидхәтович! Сезне күркәм юбилеегыз белән котларга рөхсәт итегез!

Сез гаҗәеп эшлекле һәм максатчан кеше буларак билгеле. Бүген без Сезнең хезмәтләрегезнең аермачык нәтиҗәләрен күрәбез. Бу Ютазы районы чын лидерга, яхшы җитәкчегә һәм нәтиҗәле идарәчегә ия булды, дигән сүз.

Җитәкче өчен кулын пульста тота белү бик мөһим, һәм Сез моны булдырасыз. Сезнең грамоталы җитәкчелек итүегез нәтиҗәсендә район сизелерлек үзгәреш кичерде, аңа инвесторлар һәм эшкуарлар тартыла башлады. Сез республика башкаласыннан еракта урнашкан территорияне яшәү өчен бик тә уңайлы урынга әйләндерә алдыгыз. Киң күңелегез халыкның барлык ихтыяҗын колачларга, районның һәр кешесенә аталарча мөнәсәбәт күрсәтергә омтыла. Районда алып барылган социаль сәясәт Татарстанда иң активлардан берсе, ә инфраструктураны үстерүдәге тырышлыкларыгыз сокланырлык.

Яраткан районыбыз белән оста җитәкчелек итүегез һәм аны алга җибәрүдәге уңышказанышларыгыз өчен Сезгә рәхмәт әйтәсе килә. Сез һәрвакыт әйткән сүзегездә торасыз, инициативаларны хуплыйсыз, харизмагыз белән сокландырасыз. Сезнең белән бер командада без бар эшне дә булдырып чыгабыз.

Форсаттан файдаланып, эшегездә зур уңышлар, иминлектә һәм сәламәтлектә озак яшәвегезне телибез. Сезгә бәхет, күтәренке кәеф һәм мул тормыш насыйп булсын! Туган көнегез белән, Рөстәм Мидхәтович!

Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы Советы һәм Башкарма комитеты ***коллективы***

Зәкуан Ильясов, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең җирлекләр белән эшләү буенча урынбасары, **Фәридә Шакирова**, җирлекләр белән эшләү бүлеге башлыгы, **Анна Фәйзуллина**, җирлекләр белән эшләү бүлегенең баш белгече һәм авыл җирлекләре башлыклары **Рөстәм Әхмәтвафин**, **Ләйсән Синәгатуллина**, **Альбина Әхмәтшина**, **Зөлфия Әһлиева**, **Илгиз Сәләмов**, **Гөлнара Хәмидуллина**, **Рамил Вәлиев**, **Фәния Әминова**, **Гөлнара Сафиуллина**.

Фото ТР Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетыннан алынды

Бәяләп бетерә алмаслык хезмәт

– Хөрмәтле Рөстәм Мидхәтович! Бу тантаналы көндә Сезнең хөрмәткә яңгыраган матур котлауларга без дә кушылабыз һәм Сезгә бары тик яхшы теләкләр генә юллыйбыз.

Холкыгызга хас ныклык, зирәк акыл һәм киң күңеллелек сыйфатлары Сезгә карата тирән ихтирам уята, күркәм эшләрегезгә кушылырга өнди. Сез табигатегез буенча әйдәман, кешеләрне илһамландыра беләсез. Кемнәрдер авырлыклар гына күргән җирдә Сез, киң һәм аналитик фикер сөрешегезгә таянып, районның потенциалын һәм үсеш нокталарын билгели беләсез.

Сезнең Ютазы районына килүегезгә тугыз елдан артык вакыт үтте. Аннан бирле күп нәрсәләр үзгәрде, ләкин бер нәрсә – Сезнең кешене тыңлый белүегез һәм ярдәм итәргә әзер торуыгыз үзгәрешсез кала. Туган районыбыз нык үзгәрде, ул хәзер чиста, уңайлы һәм матур. Сезнең сизгер җитәкчелегегез нәтиҗәсендә авыл җирлекләрен яхшырту буенча күп проектлар тормышка ашырылды. Биредә балалар үстерәсе, эшлисе, ял итәсе һәм прогрессив үсеш өчен яңа мөмкинлекләр булдырасы килә.

Бүгенге күркәм бәйрәмегездә Сезгә ярдәмчеллегегез, халык һәм гомумән район өчен эшләгән барлык эшләрегез өчен ихлас күңелдән рәхмәт әйтергә телибез. Сез кerткән хезмәт өлеше бәяләп бетергесез! Сезгә барлык башлангычларыгызда уңышлар, олы җиңүләр һәм рәхмәтле елмаюлар телибез. Актив озын гомер насыйп булсын Сезгә, гаилә җылысы һәм иртәгәге көнгә ышаныч сүнмәсен!

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА
ТАТАРСТАН
TATARSTAN
facebook.com/protatarstan
twitter.com/protatarstan
БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!
instagram.com/protatarstan
Реклама 16+

ТУКАЙ КЫРЛАЕ

«...Ул авылның, һич онытмыйм, һәрьягы урман иде,
Ул болын, яшел үләннәр хәтфәдән юрган иде.
Зурмы, дисәң, зур түгелдер, бу авыл бик кечкенә;
Халкының эчкән суы бик кечкенә – инеш кенә.
Анда бик салкын вә бик эссе түгел, урта һава;
Җил дә вакытында исеп, яңгыр да вактында ява...»

Тукаебыз Кырлайны шулай дип тасвирлый. Йөз елдан соң үзгәргәнме соң бу данлыклы авыл? Шуны ачыкларга теләп, Тукай эзләреннән йөреп кайттык.

Автор:
Руфия Фазылова

ЗАМАНГА ЯРАКЛАШУ...

Яңа Кырлай Тукай заманыннан бирле бик нык үзгәргән, заманчалашкан булса кирәк. Һәрхәлдә, шагыйрь тасвирлаганнан шактый аерылып тора аның бүгенге килеш-килбәте.

Яңа Кырлай авылы җирлегенә 8 авыл керә. Иң зурысы – Яңа Кырлай, биредә 156 хуҗалык исәпләнә, 584 кеше яши. Совет чоры белән чагыштырганда, халык саны азайса да, әллә ни күпкә түгел икән.

– 1990 нчы елларда авылга Урта Азия илләреннән кешеләр кайтты, – дип сөйләде Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Газинур Сәфәров. – Ул чакта халык саны шактый артып алган иде. Соңгы вакытта, Казандагы фатирларын сатып та, кешеләр туган авылларына кайта башлады. Хәзер бит авылларда яшәү өчен барлык мөмкинлекләр дә бар. Теләгән кешегә эш тә җитәрлек. Табигате турында әйткән дә юк...

Бүген күпләр сәламәт туклануга күчеп бара. Халык натураль ризыклар ашау яклы. Спортка да игътибар зур. Күпләр ялларын саф һавада үткәрергә омтыла. Боларның барысы да Яңа Кырлайда бар. Шуңа да бирегә читтән ял итәргә килүчеләр күп икән. Кыш Бабай резиденциясен күздә тотам. Кышын гына түгел, җәйләрен дә кеше өзелми ди аннан. Кайчандыр колхоз төзегән ике катлы бинаны кунакханә иткәннәр. Янәшәсендә парк эшләп куйганнар. Спортның нинди генә төре юк монда: көймәдә йөрүдән башлап, атта чабуга кадәр. Ризыкка да аерым игътибар: ипи, башка камыр ризыкларын авылда җитештерелгән продукциядән генә пешерәләр. Читтән килүчеләр аларны күз йомганчы алып бетерә икән.

– Әлбәттә, Кыш Бабай резиденциясе – бизнес, – диде Яңа Кырлай авылы җирлеге башлыгы. – Сер түгел, аннан кергән табыш авыл кешесенең кесәсенә керми. Тик моңа икенче яктан да карарга кирәк – дистәләгән кеше өчен эш урыны ул. Нигездә, хезмәт күрсәтү өлкәсендә үзебезнең авыл кешеләре эшли.

Эш дигәннән, биредә җирләр «Кырлай» Агрофирмасы»сы ҖЧҖнә карый. 50 гектар җирдә бәрәңге генә утырталар. (Бу республикада иң күбе санала.) Әлеге эшкә ел әйләнәсендә 30 кеше кирәк икән. Тагын ат, сыер фермалары бар, анда да авыл кешеләре эшли.

– Яшь белгечләргә биш йорт салып ятабыз, – диде Газинур Сәфәров. – Дөресрәге, аны ТР Дәүләт торак фондыннан безнең инвестор сатып ала. Ул йортлар заманча: газы, суы кергән, бәдрәфе, ваннасы белән булачак.

– Йортлар югары белемле белгечләргә биреләчәкме? – дим.

– Юк, югары белеме булмаган белгечләр дә алачак. Иң мөһиме – агрофирмада эшләсен, тәртипле, тырыш кеше булсын. Авылда төпләнеп калган бик акыллы, эшчән яшь егетләр бар. Йортлы булсалар, өйләнеп тә куярлар иде. Хәзер киленнәр төп йорт, кайната-кайнанадан аерым яшәү яклы. Миңа калса, гади эшче – тракторчы, сыер савучы кебек хезмәт ияләре ул йортларга күбрәк тә мохтаҗ. Югары белемле белгеч болай да югалып калмый бит ул...

Фото: Александр Ефремов

НӘСЕЛЛЕ УМАРТАЧЫЛАР

Иң беренче булып авылның иң өлкән кешеләре – Наил абый белән Мәһинур апа янына юнәлдек. Авыл җирлеге башлыгы аларны: «Бик тырыш кешеләр, нәселле умартачылар», – дип таныштырды.

– Элек егермешәр баш корт тота идек, – диде Наил абый Гыйбадуллин. – Хәзер картайдык инде. Мәһинур апагыз да – умартачы, мин юкта кортларны карап торды. Бал аертканда да гел янәшәдә булды. Кортчылык стажыбызга – илле ел, ә гаилә стажыбызга 60 ел тула.

Наил абыйга 87 яшь, ә Мәһинур апага 80 яшь тулган. Җиде бала тәрбияләп үстергәннәр. 17 онык, 9 оныкчыклары бар.

– Мин яшь вакытта Сахалинда шахтада эшләдем, – диде Наил абый. – Мәһинурга 28 яшемдә өйләндем. Сахалиннан кайтып алдым мин аны. Ике балабыз да шунда туды. Сигез ел яшәгәннән соң туган якка кайтырга булдык.

– Ник? – дим.

– Туган як сагындырды. Мәһинур апагыз да: «Кайтыйк», – дип торды. Әле ярый кайтылган дим. Аннан туган нигез янәшәсенә йорт салдык. Ирле-хатынлы икебез дә колхозда эшләдек.

– Бал кортлары кешене яшәртә, диләр. Моның белән килешәсезме?

Сорауга Мәһинур апа җавап бирде:

– Дөрес ул, дөрес. Бал кортлары көч бирә. Әле менә карт әнкәнең көч аерып чыгара торган вакыты. Очып китмәсеннәр, дип, саклап кына торабыз. Картаеп өйдә утырырга җай юк. (Көлә.)

– Ана кортның кайчан көч аерасын алдан белеп була, диләр. Сез дә беләсездер? – дим.

– Әйе, чамалап була, – диде Мәһинур апа. –Гадәттә, ул көннең беренче яртысында аера. Кортлар иртән үк тыз-быз оча башлыйлар. Гел шул тирәдә йөреп торырга кирәк. Яшь көч аерылып чыккач та, башта ояның тышына яки якындагы агач-куакны сара. Менә шул чагында аларны җыеп алып, базга төшерергә кирәк. Берничә сәгать узгач, баздан алып, яңа ояга ябарга була.

Наил абый белән Мәһинур апа гомер буе күп итеп мал тоткан. Хәер, хәзер дә сыерлары бар.

– Сахалиннан Яңа Кырлайга 1968 елда кайттык, – диде Мәһинур апа. – Урам тулы бала-чага, клублар гөрләп эшләп тора иде. Күңелле, матур яшәдек, эшләдек тә. Үзебезнең берничә сыер өстенә колхозга үгезләр дә симертеп бирдек. Җиде баланы җиңел генә үстереп булмый...

– Сеңлем, безне авылның иң өлкән кешеләре дип яз, – диде кисәк кенә Наил абый. – Чынлап та шулай ул. Яңа Кырлайда миннән дә олырак ир кеше юк. Мактама, кирәк түгел.

Әби белән бабайның нәрсәдәндер тартынганы сизелеп торды. Балалары турында да сөйләргә ашкынмадылар бу тыйнак кешеләр. Югыйсә ул-кызлары барысы да башлы күзле, бишесе Арча районында калган. Бер дигән тормыш алып баралар.

Наил абый «мактама» дисә дә, бу сөйкемле әби белән бабайга соклануымны белдерәсем килә. Бик күркәм пар алар. Тигезлек, саулык телим үзләренә.

– Мәһинур апагыз да – умартачы, мин юкта кортларны карап торды, – ди Наил абый Гыйбадуллин.

«ҖИРЕҢ БУЛМАСА, ХАЙВАН ҮСТЕРҮНЕҢ ФАЙДАСЫ ЮК»

Тумышлары белән Яңа Кырлайдан булган ирле-хатынлы тагын бер гаиләгә кердек – Закировлар. Фәнил абый белән Сөмбелә апа 30 ел бергә яши икән. Өч кыз үстергәннәр. Яңа Кырлайда шәхси ярдәмче хуҗалык (ШЯХ) программасы буенча субсидия алган 18 гаилә бар. Закировлар шуларның берсе.

– 2010 елда ШЯХ программасында катнашып, субсидия алган идек, –

Яңа Кырлайда шәхси ярдәмче хуҗалык программасы буенча субсидия алган 18 гаиләнең берсе – Закировлар.

диде Фәнил Закиров. – Шул дәвердән бирле мөгезле эре терлек тотабыз. Бүгенге көндә дүрт сыер, берничә баш үгез бар. Хатын да, мин дә рәсми рәвештә беркайда да эшләмибез. Маллар тормыш алып барырлык акча кертә үзе, зарланмыйм.

Закировларның 15 гектар җирләре бар. Агрофирмадан үзләренең пай җирләрен алганнар. Шуңа өстәп җир эшкәрү өчен техникасын да юнәткәннәр. Кыскасы, үз җирләрен үзләре эшкәртәләр, малларга азыкны үзләре әзерли.

– Әгәр җиреӊ, техникаӊ булмаса, мал асрауның файдасы юк, – диде Фәнил абый. – Игеннең бәясе кыйммәт, ә үгезләр артым бирсен өчен иң беренче эш итеп иген ашатырга кирәк. Хәер, сыер да он ашатмасаң күп сөт бирми.

Закировлар дүрт сыерның да сөтен тапшыра. Май аенда аның бәясе 18 сум 50 тиен булган. Кышын егерме сумнан артып киткән.

Тырыш гаилә бу. Йорт-җирләре төзек, пөхтә. Бакчалары да каралган, анда ни генә үсми.

– Теплицагыз да зур күренә, яшелчә дә үстереп сатмыйсызмы? – дим.

– Юк, – диде хуҗабикә. – Үзебез өчен утыртабыз. Гаилә ишле бит. Әле оныклар да бар.

Закировлар безне капка төбенә кадәр озата чыкты. Фәнил абый каршыларындагы иген җирләренә күрсәтеп:

– Бу безнең пай җирләре, – диде. – Аерым районнарда фермерлар җирләрен ала алмый интегә икән дип ишеткәнем бар. Бездә андый хәл булмады. Хайван асраган кешегә мөмкинлекләр бар. Иренмәскә генә кирәк. Авыл кешесе гомергә мал асрап көн күргән. Бүген дә шулай ул һәм шулай тиеш тә…





ЕЛЫНА КЫРЫК МЕҢ КЕШЕ КИЛӘ

Яңа Кырлайга килеп, Тукай музеена кермәсәк, дөрес булмас иде. Миңа калса, анда күпләр сәяхәт кылган. Шуңа да музейны тасвирлап тормыйм. Без аның бүгенгесе белән кызыксындык. Яңа Кырлайда Кыш Бабай резиденциясе ачылгач, авылга килүчеләр бермә-бер арткан, дип ишеткән идем, хак икән.

– Әйе, хәзер кыш көне дә халык өзелми, – диде музей җитәкчесе Дамир Абдуллин. – Бүген безгә күбрәк гаиләләре белән киләләр. Ә моннан ун еллар элек ешрак мәктәп укучылары йөри иде. Хәер, хәзер дә укучылар күп йөри, аеруча – каникулларда. Республиканың төрле районнарыннан киләләр. Музейга бүген якынча елына кырык мең кеше килә икән. Музей хезмәткәрләре махсус статистика алып бара. Элек бу сан бермә-бер ким булган. Биредә шундый тәртип, шарт – Кыш Бабай резиденциясенә килгән туристлар музейга да керә.

– Кайбер кешеләр Кыш Бабай резиденциясенә ял итәргә елына ике-өч тапкыр килә, – диде Дамир Абдуллин. – Шуны күздә тотып, музей эшчәнлегенә гел яңалыклар кертеп торабыз. Бездә махсус күргәзмә залы бар. Анда төрле рәссамнарның картиналарын, эшләрен куябыз. Алар елга берничә тапкыр алышына. Шулай ук балалар өчен төрле мастер-класслар, башка чаралар үткәрәбез. «Без моны күрдек инде», – диярлек булмасын, әнә шулай эшлибез.

Яңа Кырлайдагы Габдулла Тукай музеена быел кырык ел тула. Әлеге ике катлы бинаны заманында Бакый Урманче эшләгән. Татар сынлы сәнгатенә нигез салган күренекле рәссам, Яңа Кырлайда яшәп, Мари Эл урманнарына үзе барып, бүрәнәләрне сайлап алып кайткан. Бакый Урманчены кырлайлылар хәзер дә сокланып, тирән хөрмәт белән искә ала.

– Бакый ага үз эшенең чын остасы булган. Өлгергән агачларны гына алып кайткан, шуңа күрә бүрәнәләр бүген дә бер дигән итеп тора, хәтта ярылган урыннары да юк, – диделәр.

Яңа Кырлайдагы Габдулла Тукай музеена быел кырык ел тула.

ТУКАЙНЫ БЕЛӘЛӘР...

Халык телендә «Тукай Кырлае» дип аталган бу авылның кешеләре дә, табигате дә әсир итте. Арчаларча, затлы да, милли дә ул. Биредәге кызлар-малайлар Тукайның туган, вафат булган елын, биографиясен (махсус берничә баладан сорадым – авт.) яхшы белә. Музей хезмәткәрләре, мәктәп укытучылары да: «Сез Тукай тормышында булган бөтен истәлекле даталарны белергә тиеш, чөнки сез бөек шагыйрь яшәгән авылдан. Кая барсагыз да, бу турыда матурлап сөйләрлек булсын», – дип өйрәтә икән.

Яңа Кырлайда бөтен нәрсә күңелгә хуш килде: төзек йортлар, тырыш халкы, малай-кызларның матур итеп ана телләрендә сөйләшүе. Бары бер нәрсә генә кәефне кырды: без Яңа Кырлайга барган көнне Кыш Бабай резиденциясендә балалар өчен бәйрәм булды. Шул бәйрәмдә ни Шүрәле, ни Су анасы ник бер татарча җөмлә әйтсен! Тагын да аңлашылмаганы – бәйрәмгә килгән балалар көне буе рус җырлары тыңлады. Ә авыл кешеләре бу хәлгә нишләп аптырамый икән? Дөресрәге, алар аңа күнгән инде, чөнки Кыш Бабай резиденциясендә нигездә барлык чаралар рус телендә уза.

– Анда читтән килгән кешеләр эшли, татарча белмиләр. Ярар инде, без тавыш чыгармыйбыз. Балаларыбыз рус телен дә яхшы белә бит, – диде бер укытучы ханым. Мин исә гаҗәпләндем: шул ук әкият геройларын ике телдә дә сөйләтеп була бит. Нәрсә, бездә татарча, русча белгән аниматорлар юкмы әллә? Бар, әлбәттә!..

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

– Борынгы бабаларыбызның нәсел шәҗәрәсе Биектау районына барып тоташа. Казан ханлыгы җимерелгәннән соң алар яшәгән авылга Хохлов атлы кешене китерәләр. Ул җирле татарларны нык кыса, шуңа күрә халык Арча җиренә күчеп утырырга мәҗбүр була. Шулай итеп Иске Кырлай авылы оеша. Соңрак, чама белән йөз елдан соң, берничә гаилә Ия елгасы буена күченеп китә. Авылга «Яңа Кырлай» дип исем бирәләр. Яңа Кырлайның оешу вакыты XVIII гасыр азагы – XIX гасыр башы дип карала. Авылның атамасын «кыр» сүзе белән бәйлиләр. Яңа җирләргә күченеп утырган халык, киң кырларны күреп шундый исем биргән дип исәпләнә.

Миләүшә Зарипова, Яңа Кырлай урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы.



ЮГАРЫ ВЕНГРИЯ-ТАТАРСТАН СӘНГАТЬ **МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ**

«Казанда Гала белән Сальвадор Галиның туе», «Тычканнан да шыпыртрак. Казан мәчеләренә багышлана», «Казан. Нух көймәсе»… Халыклар дуслыгы йортында Татарстанның күренекле рәссамы Альфрид Шәймәрдәновның күргәзмәсе ачылды. 12 картинадан торган вернисаж Венгрия наив сәнгать классигы Тивадор Чонтварины искә алуның 100 еллыгына багышланган (1853–1919). Исән чагында рәссам танылмаган булган, һәм ул үзенең бер генә эшен дә сата алмаган. Аның талантын узган гасырның 60 нчы елларында гына таныганнар. Бәхеткә, аның Татарстандагы наив сәнгатьтәге тугандашын мондый күңелсез язмыш урап узган.

Күргәзмә залына керү юлы – без гадәтләнгән нарат һәм каен пейзажлары дөньясы белән наив сәнгатьнең фантасмогорик галәме арасындагы чик. Бусагадан атлауга, кеше буендагы Казан мәчесенең ачык сары күзләре гипнозына эләгәсең. Икенче мәче – Альфрид Шәймәрдәнов талантына баш иючеләргә яхшы мәгълүм Манул атлы мәченең могҗизаи күзләре рәссамның футболкасыннан кунакларны күзәтә. Кунаклар кызыксынып киндерләрне өйрәнә: аларда Татарстанның истәлекле урыннары фонында филләр-дөяләр-аюлар катнашындагы күп баскычлы сюжетлар ачылып китә. Рәссамның осталыгына һәм җентекле хезмәтенә сокланып, биниһая зур картиналардагы вак детальләрне сәгатьләр буе тикшерергә мөмкин. Альфрид Шәймәрдәнов нәкъ менә шундый динамик һәм ачык техника белән 1993 елда яза башлый, һәм инде дүрт елдан соң Братиславада Бөтендөнья наив сәнгате күргәзмәсендә катнаша. Бүген аның исәбендә дистәләрчә халыкара күргәзмәләр, һәм ул Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы дигән мактаулы исемгә ия. Аның эшләре бөтен Россия буенча күргәзмә залларында һәм шәхси чит ил коллекцияләрендә бар.

– Мин Венгрия һәм Татарстан арасындагы мөнәсәбәтләрнең төрле формаларга ия булуына ихлас күңелдән шатмын, шул исәптән сәнгать күргәзмәләре кебекләренә дә, – дип сәламләде наив сәнгатьне сөючеләрне Венгриянең Казандагы генераль консулы урынбасары Ласло Дароци. – Мондый чаралар башка халык мәдәниятләренең традицияләре белән танышу өчен искиткеч мөмкинлекләр бирә һәм бер-береңә якынаерга, үзара аңлашуга ярдәм итә.

Фото: Алёна Кутыркина

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА
БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ

Казан, Бауман урамы, 2019 ел

Фото: Александр Ефремов

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ

Казан, Бауман урамы, 1980 нче еллар